

МӨХӘММӘТ МИРЗА

# КИЕК КАЗ ЮЛЫНДА



Шигырьләр, газәлләр, поэмалар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
М 51

Мөхәммәт Мирза

М 51 Киек Каз Юлында: Шигырьләр, газәлләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 303 б.

Мөхәммәт Мирза шигърияткә шактый урау юллар узып килгән, кыска гына вакыт эчендә шигырь сөючеләр күңелендә үз урынын тапкан шагыйрь. Аның укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган бу китабына да күңел түреннән чыккан нечкә, саф хисләрен сөйләүче әсәрләре урын алды.

ISBN 5-298-01262-0 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

# НЕЧКӘ ХИСЛӘР, КӨЧЛЕ ХИСЛӘР!

...Заманча шәп итеп салынган шәһәр йортларының таштан коелган диварлары арасында сезнең дә кышкы озын кичләр буена туган авылыгызны сагынып, хисләнеп утырганыгыз бардыр... Әйе, сагынуын сагынабыз – бик тә, бик тә сагынабыз! Әмма үз эчебездәге әнә шул үзәк өзгеч халәтне, үз йөрәгебездә кайнаган әнә шул үтә нечкә, ләкин көчле хисләрне ничек итеп әйтеп бирергә соң?! Монда бит күңелнең шундый да нык сизгерлеге, көче – чын Илаһият һәм, кем әйткәндәй, сандугач теле кирәк!

Агыйделне боз тоткандыр,
йокыга талгандыр яры...
Тал-курасын сызгырткандыр
кышның беренче бураны...
...Ялгызым калган бу төндә
бәсле тәрәзәгә багып,
уйлап утырам шуларны...

Шагыйрь Мөхәммәт Мирза язган менә шушы бер шигырь миңа, минем күңелгә, тулы бер роман шикелле тәэсир итте! Чыннан да, безнең – авылда туып, авыл җирендә үскән һәм хәзер менә таш калаларда яшәп ятучы замана балаларының – бәгырен телгәләгән иң тирән, иң газиз кичереш әнә шул бит инде! Бик күпләр өчен төп тамыр, үзәк тамыр бит ул!

Әнә шул бөек хисне шагыйрь ничек оста итеп әйтеп бирә алган!

Мөхәммәт Мирзаны мин моңа кадәр якыннан белми идем. Ә менә аның Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителгән бу җыентыгы белән танышып чыккач, чорыбызның катлаулы халәтен күңелләргә үтеп керердәй итеп әйтеп бирә белүче һәм иҗатта үзенең кабатланмас аһәңе, тавышы булган талантлы шагыйрь дөньясына килеп кергәнемне тойдым, аңладым.

Фани дөнья сынар өчен дан, мал бирер,
Әмма чиксез бары вакыт үзе генә.
Югалту һәм табу чиратлашып килер;
Рәхәтенә, хәсрәтенә син түз генә,
Аллана, баллана алма тик көз генә.

Шигырьнең эчтәлеге шундый тирән һәм аеруча безнең заман өчен шундый актуаль ки: аны хәтта яшәү девизы итеп тә алырга мөмкин. Бигрәк тә соңгы ике юлы фәлсәфи көче белән халык мәкальләренә тиң!

Әйе, шагыйрь бүгенге катлаулы дөньяны үтә нечкә күңел белән кичереп яши. Аңа бик күп нәрсә тәэсир итә, күңелен дулкынландыра. Менә, мисал өчен, бер чит ил җырчысын тыңлагач, ул ниләр кичерә:

Телең дә ят, көең дә ят –
Ят түгел әрнүләрең.
Җәберсетә тик хыянәт
Телгәләп бәгырьләрне...

Мондый чын шигъри юлларны замана Моңын нечкә тоючы зат кына яза ала! Чыннан да, Мөхәммәт Мирза шигъриятькә, иҗатка мөкиббән китеп яши:

Бизмә шигырь, ятим итмә колыңны,
Алма җаннан йомшак җылы кулыңны.
Балкыт Илаһыдан килгән нурыңны,
Яктырт мәңгелеккә күчәр юлымны!

Болар дөнья поэзиясенең классик үрнәкләре белән янәшә торырдай һәм татар халкы: «Менә бу энҗеләр – безнең күңел бизәкләре!» – дип, хаклы рәвештә горурлана алырдай чын шигърият үрнәкләре!

Мөхәммәт Мирза – ихлас, садә хисләр шагыйре. Ләкин шул ук вакытта аңа тирән фәлсәфилек, афоризм дәрәҗәсенә җитеп чарланган, канатлы сүзләр биеклегенә күтәрелгән образлылык та хас.

Һәркемнең
Тәнен – Җир,
Җанын Ай
Көтәдер.

Бу китапта менә шушындый онытылмас шигъри юллар күп. Алар укучының күңеленә тиз үтеп керә, анда озакка сакланып кала һәм теге яки бу уңайдан бик еш искә төшеп, аны әле тагынтагын сөендерәчәк.

Озын сүзнең кыскасы шул: шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның менә хәзер сез кулыгызга алган бу китабы чын мәгънәсендә күңел юлдашы булырдай, көчле тәэсиргә ия әсәрләрдән тора. Алар сезне замана юлларында адашмастай көчле рухлы, нечкә күңелле – шигъри җанлы итү максаты белән язылганнар.

Китап эчендәге әнә шундый тылсымлы дөньяга рәхим ит, кадерле укучыбыз!

*Мансур Вәли-Барҗылы*

# ИДЕЛ-ЙОРТ



# ИДЕЛ-ЙОРТ

Идел-Йортта гомер иткән халкым;
Чуен койган, иген иккән ул.
Игелекле, батыр, гадел атын
Тап төшерми, горур йөрткән ул.

Бабайлардан мирас – Идел-Йорт –
Ядкаре һәм намус аклыгы.
Безнең максат, кардәш, истә тот,–
Хак Ватанның чәчәк атуы.

Идел-Йортта шөһрәт тоткан халкым,
Тылмач кирәкмәгән аңарга.
Иле, ирке булса, югалмас ул
Сынау тоткан тарих-заманда.

Бабайлардан мирас – Идел-Йорт –
Ядкаре һәм намус аклыгы.
Безнең максат, кардәш, истә тот,–
Хак Ватанның чәчәк атуы.

## БАТЫРЛАРЫН БАРЛАП ТОРА ХАЛКЫМ

Батырларын барлап тора халкым,
Дәверләргә бүлеп, чорларга.
Дастаннарга кереп калган алар,
Әкиятләргә, бәет, җырларга.

Хәтерләргә мәңге кереп калган,
Йола алмас һичбер ак тап та;
Иблис язган ялган тарих битен
Хаклык җиле барыбер актарта.

Идегәйләр кайтты, мең елга бер
Урап кайткан комета сымак;
Исхакыйлар, җәлилчеләр кайтты,
Оныклардан фатиха сорап...

## КАРЧЫГА БИТ ИКЕ БАШЛЫ

Бүленгән ил
озын куллы,
йонлы куллы бәндәләргә.
Дөреслекне табармын дип,
күпме генә бәргәләнмә,
сиңа калган, миңа калган
бу илдә ярык тагарак.
Кирәк булган безгә туу
бераз соңрак, йә алдарак...

«Тигезлек» дип,
«Хөррият» дип,
гәзитләргә язу яхшы,
аңлыйсыңдыр, сизәсеңдер:
карчыга бит – ике башлы.

# КАРШЫЛЫЙК

Вакыт кына
Төгәл бизмән,–
Хакыйкатьне
Күрә ала.
Тик ул гына
Дөрес бәя
Бирә ала:
Халыкларга,
Патшаларга,
Шагыйрьләргә,
Алыпларга...

Бүген вакыт
Бизмәнендә –
Халкым көне.
Ни күрсәтер,
Кая илтер
Хак хөкеме?
Хак Тәгалә
Күз алдында
Бихисап күп
Таланса да,
Дүрт тарафка
Таралса да,
Канга батып
Кыйналса да,
Нахак яман
Ат алса да,
Кыйбласын –
Хак иманын
Югалтмаган
Халкым бит ул!

Вакыт-бизмән
Көзгесендә
Ачык күрәм:
Шагыйрь-патша,
Патша – Алып
Алып – шагыйрь
Булыр көннәр
Килә безгә.
Каршы алыйк
Киләчәкне
Якты өмет,
Иман белән.

# АК ИЛЕМ

1995 елның көзендә Актанышта
нефть чыгара башладылар

Ак идең, ак калырсыңмы,
Ак Илем – ак өметем?
– Аһ! – дидең, җан канатыңны
Каерып өзде кемдер?!

– Аһ,– дигән аваз таралды,
Калтыранды ак болыт.
– Аһ,– диде, –болыт каралды,
Күк киде кара толып.

Айсыз, йолдызсыз кара төн
Карадан да кара шул...
Илемнең сөттән ак йөзе
Караланып бара шул...

# ТУКАЙ – ИМАН

Маңкортлар аяк астында
Таптады сине, Тукай.
Ялвардым, ләкин яклаучы
Тапмадым сине, Тукай.

Сине яклап аваз салдым:
«Ул,– дип,– безнең атабыз,
Якламасак – безнең хата,
Таптау – сезнең хатагыз!»

Дидем: «Карагыз дүрт якка,
Җыегыз гакылыгыз!
Иманны кайтарыйк җанга,
Тукайны чакырыгыз!..»

Көлделәр миннән: «Кит,– диләр,–
Сиңа монда нәрсә бар?»
Маңкортлар такмак әйтәләр,
Сулкылдап елый җаннар.

# БУЛДЫ, БУЛДЫ...

Кан көндәше шагыйрьләрне
Һәр тиран үзенчә кырган:
Кайсы өзгән чабып башын,
Кайсы данга тончыктырган...

Булды, булды – яшәдек без
Тукайсыз заман.
Аннан соң гомер кичердек
Туфансыз заман.

Җәлилсез дә яшәдек ич –
Хәтерләр исән;
Телне тешләтте замана,
«Исхакый»,– дисәң...

Зурлыйсымы, хурлыйсымы
Бүгенге көнне?
«Сукыр тәкә» уйныйбыз күк,
Бәйләми күзне...

# ГЫЙБРӘТ АЛ, ПАДИШАҺЫМ

Уң кулыңда вәзирең кем,
Сул кулыңда вәзирең кем,
Кыйблаң кай як, падишаһым?
Уңда упкын, сулда упкын,
Тайпылдың— капты да йотты,
Искәрмәсә зиһен-акыл.

Уң кул вәзир уңай нидән?
Сул кул вәзир кулай нидән?
Уйланып бак, падишаһым!
Уңы сузып тора кылыч,
Сулы сузып тора кылыч,
Кыйсын, диеп, кемнең башын?

Уңнан иңеп торыр хәбәр,
Сулдан иңеп торыр хәбәр,
Дүрт якка бак, падишаһым!
Падишаһлар килгән-киткән,—
Вәзирләре арттан типкән,
Гыйбрәт ал, падишаһым!

## АВГУСТ НИ ДӘ, ОКТЯБРЬ НИ...

Бер хуплыйлар, бер хурлыйлар
Һәр тарафта августны.
Август ни дә, октябрь ни...
Тарих үзе ялгышты.

Шыр томана сукырлар да
Санап атлый адымын.
Аяз көндә, тигез юлда
Вакыт үзе абынды...

Август ни дә, октябрь ни...
Таксалар яман ярлык.
Вакыт-тарих каршысында
Рәнҗеп тора хаклык...

# БЕЗ ИСӘН!

Таш күзеннән җандай
чәчрәп чыгып,
әйтү ләззәт икән:
– Без исән!

*Айдар Хәлим*

Кем урлаган,
кемдер яшергәнме,
куркып, әллә яндырганнар укмы? –
Эзлимен мин
халкым шәҗәрәсен,–
табарыма ышанычым ныклы!

Текә ярга
кар ятмаган кебек,
хак тарихны каплый алмас таплар;
яндырылган
шәһәрләрнең көле
ягылып калган җиргә катлам-катлам.

Калмаса да
тузга язганнары,
ташны чокып язганнары исән;
телдән телгә,
илдән илгә күчеп,
югалмаган – дастаннары исән!

Һәр яз белән
ярсып ташып аккан
Иделләре, инешләре исән;
җиде ятка
барып ирешелгән
дисбе, тәңкә, көмешләре исән!

Чулман, Җаек,
Идел ярларында
мәгарәләр әле дә булса исән;

Сарытауны
һәм Уралны ялмап
искән җилләр әле дә булса исә!

Калмаса да
тузга язганнары,
Халкым теле, һушы, коты исән;
кабер ташын
сүтеп нигез салган
илбасарның иман йорты исән...

– Онытмагыз мәңге! –
дигән сыман,
күкне дүрткә бүлгән тәре исән;
гасырларның
ерак аръягыннан
аккан канлы төтен – хәтер исән!

Калмаса да
тузга язганнары,
ташны чокып язган тарих исән;
Халкым исән,
Хак Тәгалә кушып,
шәҗәрәсен язар Шагыйрь исән!

# ТӘҢРЕ НИЧЕК ЙӨРТӘ?

*Урыс патшасы Бориска*
*Чечня халкына каршы канлы сугыш*
*башлау уңаеннан*

Өлкән туган, туганмы син?
Йә иблистән тугансың син,
Дистәләгән милләтләрне
Бугансың һәм суйгансың син.

Коты алынып җан кылганда,
Ләззәтләнү кичерәмсең,
Аракыңны канга бутап,
Эчәмсең һәм исерәмсең?

Өлкән туган, туганмы син,
Миңа түгел – Газраилгә?
Дөньялыкта тәмуг ясап,
Газаплыйсың нигә илдә?

Өлкәнне хөрмәт итәргә
Тәрбияле милләттәнмен;
Өлкән туган, беләсеңме,
Күпме халык имгәткәнең?

Күпме телне күмдең тере?
Кабер ташын сүтә-сүтә,
Иман йортың төзегәнсең,–
Тәңре ничек җирдә йөртә?

Хак Тәгалә күз алдында
Күпме милләт башын чаптың,
Оялмый йөртәсең һаман
«Дөньякүләм палач» атын.

Өлкән туган, туганмы син,
Өлкәнме син, ялкау булгач?
Бар һөнәрең, айнымыйча,
Янау булгач, талау булгач...

Язып сиңа нәфрәтемне
Бетерә алмам, каләм тузар;
Шушы утлы нәфрәтемне
Яшен итеп атам: Мирза!

## И ТУГАН ТЕЛ

И туган тел, тыелган тел,
Шаһгалиләр — зобанилар
Кулы белән буылган тел,
«Бисмилла»сыз суелган тел.

Явыз Иван — явыз патша
Шомпол басып көйдергән тел;
Чукындырган чакларында
Таралышып сибелгән тел.

И милләтем, нишләттеләр,—
Таңнан базда эшләттеләр;
Баш күтәреп багыйм дисәң,
Сугып телең тешләттеләр.

Илсез калып, телсез калып,
Яши алсын нинди халык?!

# БӨЕК КҮКНЕҢ КҮЗ АЛДЫНДА

*1552 елда урыс илбасарларына*
*каршы сугышып шәһид булганнар*
*рухына, Хәтер көне уңаеннан*

Бөек Күкнең күз алдында
Кичә генә булган кебек:
Яныш ауды Шәһри Казан,
Янды хәтта Кабан күле.

Бөек Хәтер күз алдында,–
Күкләр тоташ яшьле төтен,
Боз тотканчы Казан-суда
Кан-яшь акты, җанны тетеп...

Боз тотканчы, боз тоткач та,
Чукындырып яшен-картын,
Ирексезләп, илбасарлар
Богау белән тәре такты.

Гасырларның аръягыннан
Вәхшидән дә вәхши яуны
Белми Хәтер, Бөек Хәтер,–
Биш гасыр кызыл кар яуды...

# ТӘРӘЗӘМӘ КАГЫЛМА, ҖИЛ

## 1

Бу авыл соңгы сугышта
Җитмеш ирен югалтты.
Җитмеш толның җилкапкасын
Бары җил-буран какты.

Язлар килеп, карлар эреп,
Ташу сулары акты;
Басу капкасына чыгып,
Ятимнәр юлга бакты.

Күктә аккан ак болыттай,
Гомер акты да акты,
Акыл әйтте: «Кайтмас»,– диде,
Йөрәк гел кире какты.

Акка төренде шомыртлар,
Аклыгы – өмет иде...
Тәлгәш-тәлгәш кара кайгы –
Кемнәр каргышы тиде?

## 2

Авылым үткән сугышта
Җитмеш ирен югалтты.
Җитмеш толның мин – соңгысы,
Тәрәзәмне җил какты.

Тәрәзәмә кагылма, җил,
Телгәләмә бәгырьләрне;
Кайтмасын белеп торсам да,
Зарыгып көткән хәлемдәмен.

Тәрәзәмә бәрелмә, җил,
Сиңа дала беткәнмени;
Җитмеш җиде яшемдә дә
Беләсең ич көткәнемне!

Җитмеш толның соңгысы мин,
Зарыгып көтәм кайтканын!..
Тәрәзәмә кагылма, җил,
Калтыратма капканы?!

## БУЛАМЫНИ...

Бөркетләр менгән кыяга
Каргалар менәр диме?
Чыпчыклар корган ояга
Сандугач керә диме?

Сабанга җиккән алаша
Узышта ал чыгармы?
Кем килә дисең алмашка,–
Без чыдадык – чыдармы?..

Күлдә тынчыган балыкның
Сатыры буламыни?
Астына иткән халыкның
Батыры буламыни?..

# АЙ ТОТЫЛГАН ТӨНДӘ

*Яңа Ай туып, берничә сәгатьтән тотылган төндә уйланулар. Халкымның яңа яулаган азатлыгы да шул хәлгә калмасын иде, дидем һәм...*

Кем бәхетле,
Кем бәхетсез,
Кем матур да, кем ямьсез.
Кем сау-таза,
Кем гариптер,
Кем җырлы да, кем көйсез.
Кем гашыйк бүгенге төндә,
Кем акыллы, кем юләр,
Кемдер туар бүген төндә,
Кем керер кара гүргә.
Кем уйлар, төн тәрәз багып,
Кем багар нарасыен.
Кемне егар кара кайгы,
Кем йотар татлы сыен.
Кемдер йоклар тигез сулап,
Кемдер ятыр кемне уйлап,
Кемдер көләр шашып-шашып,
Кемдер калыр тын, сагаеп,
Кемнәр тагын әллә нишләр...
Мин көтәмен яңа Айны.
Өметләр белән,
Теләкләр белән,
Үзем өчен дә,
Улым өчен дә...
Нәни Аем, нарасыем;
Яшь тоягым, йөгерек таем,
Кап-кара төндә, буран эчендә
Бу салкын төндә
Шәп-шәрә килеш
Өзгәләнә,

Алыша,
Тартыша
Магнитлар, электроннар
Тирбәлешендә,
Галәмнең үлчәнмәгән,
Үлчәнә дә алмый торган көче белән
Чиксезлегендә...

Кем бәхетле,
Кем бәхетсез?
Кемдә кемнең ни эше бар?..
Кара төндә,
Керфек какмый,
Яңа Ай көткән кеше бар.
Өметләр белән,
Теләкләр белән,
Үзе өчен дә,
Иле өчен дә.

# НИ КҮРЕР КЫЗЛАРЫМ, УЛЛАРЫМ?

Камиллалы бакчаларда йөрдем,
Павлина белән төштем рәсемгә,
Останкино башнясына мендем
Мин беренче булып нәселдән.

Каф тау дигән күккә ашкан тауны
Күреп кайттым, насыйп иткәчтен.
Алтайны да, Байкалны да күрдем,
Уралны бер үтеп киткәчтен.

Тәвәккәлләү генә кирәк икән,
Гомәр Хәйам илен мин күрдем.
Регистанны иңләп-буйлап йөрдем,
Олы бәкнең күрдем йолдызын.

Кайда гына барып чыксам да мин,
Баш күтәрми эшләп йөрүче
Татар кардәшемне очратам да:
– Кем,– дим,– безне шулай итүче?

Донбассыннан алып Сахалинда,
Воркутада, Кузбасс, Аппатитта
Күмер кисеп ташый иңсәсендә,
Шахталарда билен бөгә татар.

Магаданның салкын базларында
Татардан тыш тагын кем эшләр?
Татар диңгезендә тозга батып,
Балык тота безнең кардәшләр.

Башкаланың вокзалында әнә
Арба тартып яһүд йөриме?
Кала урамында кара карны
Татар түгел, урыс көриме?

Хәтәр җирдә татар булсын дипме,
Хәтәр эшкә җигәләр татарны?
Чернобыльгә җыйдылар татарны,
Катса татар, шунда катар дип.

Останкино башнясыннан күрдем,–
Дөнья буйлап татар сибелгән.
Баш күтәрми көн-төн эштә татар
«Тигезлек» һәм «хөрлек» илендә.

Камиллалы бакчага кергәч тә,
Һич таралып китми уйларым.
Чернобыльдәй кара көндә яшәп,
Ниләр күрер халкым, улларым?..

*Март, 1991*

# МӘСКӘҮЛӘРДӘН КАЗАН КҮРЕНӘ, ДИЛӘР...

Мәскәүләрдән Казан шәп күренә:
Казаннарда мунча якканнар.
Түбәтәйле яңа милләтчеләр
Яка астыннан тәре такканнар.

Мәскәүләрдән Казан шәп күренә:
Казаннарда казан асканнар;
Чүп базлары төялеп килүенә
Түрәләре тезелеп басканнар.

Мәскәүләрдән Казан шәп күренә:
Кемнәр йөри кайсы эзләрдән?
Таш атканга аш ашаткан Казан
Терсәкләренә үк тезләнгән.

## КЕМ УЛ?

Берсен-берсе батырмаса,
татар буламы ул?
Бата-бата бакырмаса,
хата буламы ул?
Берсен-берсе баса-баса,
күтәрелә, кем ул?
Күтәрелеп, түрә булгач,
күркә була, кем ул?
Ана телен – әлифбасын
таптап үтә, кем ул?
Туганына бәддогасын
Юмарт укый, кем ул?
Таңнан таңга тузан йотып,
җир актара, кем ул?
Орден тагып, медаль тагып,
чахотка ала, кем ул?
Килмешәкнең кулын үбеп,
мал, дан ала, кем ул?
Алга әйдәүчене сүгеп,
сөрән сала. Кем ул?
Аты арык.
Юл чатында
туктап калган, кем ул?
Ярык тагарак янында
уйга баткан, кем ул?
«Акылы керер төштән соң...»
Ни пычагыма эштән соң?
Шундый-шундый безнең эшләр,
кемнең каргышы төшкән соң?

## КЕШЕГӘ НИ БУЛГАН?

Күрми матурлыгын каеннарның,
Тоймый түмен чишмә суының.
Чәчәкләрнең хуш исләрен сизми,
Йа Ходаем, кешегә ни булган?

Төшләренә керми туган өе,
Сагынмый ул Чияле тавын.
Уйлый белми киселгән урманын,
Йа Ходаем, кешегә ни булган?

Уҗымнар карала, көя-куырыла,
Җир яралы, яна бар дөнья...
Кәрәзләнеп кырлар ярылган.
Эчкән чишмәсенә пес итә –
Йа Ходаем, кешегә ни булган?

# КОММУНИЗМ ФИНИШЫ

Баш күтәрми,
Карамыйча
Уңга, сулга,
Чабылган да
Чабылган бит...
Олы юлдан
Никадәрле
Җир узылган.
Аяк-кием
Туздырылган.
Юл тузанна-
рына батып,
Тын кысылып,
Килеп җиттек
Фи-и-ниш-ка...
Һичкем безне
Каршыламый,
Алкышламый.
Әлбәттә,
Кемгә кирәк
Без
Бу кыяфәттә?

* * *

*1552 елның 2 октябре – татар халкының коллыкка дучар ителгән көне*

Керфек какмый төн уздырам,
Ни күрербез иртәгә?
Кан-яшь түгеп алган Ирек
Алынмасмы киртәләп?

«Татар» дип тә, «Хәтәр», дип тә,
«Князь», дип тә бит безне
Кимсеттеләр... Эшләттеләр
Эшләткәндәй үгезне.

Угланнарың төмән-төмән*
Яу кырында күмелгән...
Дүрт гасырлык коллык – тарих,
Ялган белән төрелгән.

Ниләр көтә, халкым, сине,
Җирем, сине ни көтә?
Кара төндәй билгесезлек
Өркетә дә өшетә...

* *Төмән* – ун мең кешелек гаскәр.

# ҮТКӘН ДӘ КИТКӘН ГОМЕР...

*(«ГУЛАГ архипелагы»н укыгач)*

Үткән дә киткән гомер зинданда.
Башкайлар күрмәде ни тагын?!
Базларга яптылар,
                    аттылар,
                              астылар,
Өеп яктылар бабайлар китабын.

Очты да китте гомер аткан уктай.
Иманасыз, имансыз да булып.
Кайсы көлеп,
Кайсы елап,
Кайсы катып тораташтай,
Оныклар калды –
Без яшәгән подвалларда тулып.

## СОРАМАЧЫ, ЯКТАШ

*Экибастузда яшәүче кардәшемә*

Әллә кайчан белгән танышлар күк,
Кочаклап ук мине күрештең:
– Сездә ниләр бар соң? Ашау-эчү?.. –
Сорашырга шулай керештең.

Җавабымны көтмичә дә хәтта,
Үз хәлеңне сөйли башладың.
Бары әйбәт, барысы талонга –
Табылып тора көнлек ашарың.

Сабын, содасына күптән инде
Талон-фәлән сорап тормыйлар.
Бар да яхшы, шунысы бик яман,
Аяк-куллар бераз сызлыйлар.

И якташым, нигә сорамыйсың:
– Сабантуйлар ничек үтә? – дип.–
Балан бармы, шомырт, мәтрүшкәләр?
Агыйделдә чабак чиртәме?

Нигә сорашмыйсың Урта тауда
Печән өсте ничек үткәнен?
Ир-егетләр нинди эш кырганын,
Кыз-кыркынның буйга җиткәнен?

Сабантуйлар матур үтә, дисәм,
Оятымнан йөзем кызарыр.
Агыйделдә таллар бетте, дисәм,
Кәефеңне генә бозармын.

Сандугачлар зәңгәр күлгә кайта,
Тик күл генә инде күптән юк.

Чишмәләрнең җырлап акканнарын,
Аккошларның канат какканнарын
Ишеткән юк, кордаш, күргән юк...

Үз хәлеңне әйбәт дисең дә син,
Әйбәт түгеллеген сизәм бит.

Кан булса да төкермәскә,
Язмышларга үкенмәскә –
Ана сөте белән
Кергән инде безнең халыкка.
Ни бирсәләр – шуны ашыйбыз,
Ни бирсәләр – шуны киябез.
«Шөкер!» дибез, ямау салып та.

Хәлләр охшаш инде безнең, кордаш,
Туган илдә дә, аннан читтә дә...
Агыйделнең шәрә ярларында
Кыргый этләр йөри иртәдән.
Туган якта тормыш ничек, диеп,
Сорашма, син, якташ, сорама.
Иң беренче чуен койган халык
Шәфкать сорап чатта тора ла...

Сорамачы, якташ, сорама.

* * *

*Андрей Сахаровка*

Бар ул, бар,
Алмаштырмый,
Адаштырмый,
Хисләрне алдаштырмый
Яшәүчеләр,
Горур җаннар бар!

Бу болганчык илдә,
Эмансипация,
Имансызлар,
Исерекбашлар тулган җирдә
Бәхетлеме алар?

Ниләр күрер газиз башлар?
Ай күрер, кояш алыр,
Ил өстенә җәелеп моң калыр.

* * *

*«...А если не шибко грамотные «потомки волжских булгар» требуют вернуть им исконные земли...»*

*Бер маңкортның мәкаләсеннән*

1

Маңкорттыр без икебез дә,
әкәм-төкәм кебек тә...
Син сатылып көн итәсең,
мин алданып көн итәм.
Халык гомерен биш гасырга
ничек сыйдыра алдың?
Иван Дүртнең җаныдыр син,
имансыз икән җаның!
«Акылга таман» булганга,
гафу итә күр мине.
Һәм теләсә ни дип ата,
җен дип атыйм мин сине...
«Акылга таман» кешегә
ни әйтсә дә килешә:
– Хак боерса, бер аралар
җеннәрдән үзен кеше!

2

Бүген җенле мәгарәләрдән,
хәрабәләрдән,
чардуганнарны сытып үтелгән каберлекләрдән,
ГУЛАГлардан,
җеназасыз, каберсез күмелгән сазлыклардан
бихисап скелет-кешеләр күтәрелде,
күз ачып, дүрт тарафын карады,
алар аңлады.
Аңлады!

3

Моңарчы танылган,
табынылган,
горурландырган,
батырлыкларга өндәгән
триумфлы ялган тарихны –
җен язган тарихны
кешеләр аңлады,
аңлады!

4

Таланган,
алданган,
ваклыклардан,
юклыклардан,
чиратлардан алҗыган,
биш гасыр коллыкта
баш күтәрми эш сөргән татар
Тукайның ялваруын ишетте,
күзен ачып, дүрт тарафын карады.
Син «акылга таман» дисәң дә,
алар үз хәлен аңлады.
Аңлады!

5

Бүген урамнарда,
мәйданнарда,
парламентларда
уйлар, хисләр, теләкләр алыша.
Дөреслек, калышма!
Калышма!

6

Иман кайта халыкка.

## 7

Халык уртасында тырпаеп,
имансыз булып,
маңкорт бүреген киеп,
син, Жан, басып торасың.
Сиңа берни кирәкми.

Халыкка – азатлык, азатлык! –
Аңа азатлык бик тә кирәк!

## ЗАМАНА

Сандалына салып таптап,
Сытты гына замана.
Мыскалын да сатып ваклап,
Мыскыл итте замана.

Бөгеп куйды, йә сындырды,
Тез чүктерде замана.
Шәрә иманың өстенә
Печ иттерде замана.

Маңкорт бүреген кигертеп,
Тилерттерде замана.
Имансыз һәм иманасыз
Көн иттерде замана.

...Җавап тотар заман җитте
Бүген сиңа, замана.

# ӨЛКӘННӘР СҮЗЕ

Капчык-капчык кузгалак,
Капчык-капчык балтырган,
Капчык-капчык кычыткан –
Ташыдык та ашадык,
Ташыдык та ашадык.
Үлмәс өчен ачлыктан.

Ачлык белән алышып,
Үтте китте балачак.
Кузгалаклы балачак,
Тузганаклы балачак,
Буразналы балачак,
Әткәйләрсез балачак.

Үткәннәрне хәтерләү
Тырный-тырный йөрәкне
Кемгә кирәк, дисезме?
Сез төшкән мескенлеккә
Күрәдән-күрә торып
Төшәсе юк, дисезме?

Алай димә, дөнья бу!
Җиде йөз өйле авыл
Бушап калды ул елда...
Урамнары сарутлы,
Бакчалары – балтырган,
Басу тулы кычыткан...

Ярылган кыр кылганлы,
Алдагы юл томанлы,
Томан арты ни тагы?
Беркем дә белми аны,
Беркем дә белми аны –
Бүгенге көн дөньяны...

# БҮГЕН

Дөньяның буталган чагы,
Уйларның буталган чагы.
Иртәгә көн ни көтә? – дип,
Төнозыны тотып башын,
Кемнеңдер уйланган чагы.

Дөньяның чуалган чагы,
Кулларның буялган чагы.
Тәрәзәгә җил бәрелгәч,
Төн уртасында кемнеңдер
Сискәнеп уянган чагы.

Дөньяны ут алган чагы,
Күңелен шом алган чагы.
Өметсезлеккә бирелеп,
Ал җанымны, и Ходам! – дип,
Кемнеңдер ялварган чагы.

* * *

Ил карагы – кушавыз,
өзгән нәфсе тышавын.
Әллә соң гел булмаган,
әллә иблис урлаган –
һич туя белми явыз?..

Ил карагы – кыргаяк,
куллары да шул санда,
тарта да ала барын,
бирмим, диеп торсаң да...
Һичкемне тормый аяп...

Ил карагы – кем дисез,–
белә торып белмисез –
ике башлы каракош
каршыбызда – торараш...
Ишелерме – билгесез?..

# ТУГАНЫҢНАН ТАРСЫНМА

Тартса тартыр түбәнгә
татарны – татарлыгы.
Тиң табылмас тиңнәргә
туганына тарлыгы.

Тартай тапкан теленнән,
татар телсез торганда.
Тамбов, Тубыл, Төмәндә,
Тимертауда, Тулада...

Теләнеп тел тапмыйлар,
телне телгә такмыйлар.
Телдән татлы – тел татлы:
тиң торырын тапмыйлар...

Тупса төбе – түр түгел,
түбәнсетмә теләген...
Туганыңнан тарсынма,
туган – тотка, терәгең...

# ТАРИХ ТОРА

Тарих тора патшаларның
сугыш уеныннан.
Уеннан уймак чыгасы –
уеп куелынган.

Тарих тора патшаларның
туймас нәфесеннән.
Азгынлыкта чикне үткән
дөнья фәхешеннән.

Патшаларын узып азган
патшабикәләре.
Кыямәт көне җиткәчтен
алар нишләр әле?..

Тарих тора варисларның
тәхет бүлүеннән.
Кол халыкның соң чиккәчә
кибеп бөлүеннән.

Кабатланып тора тарих –
әйләнә дә баса...
Патшаны үтереп карыйк
мәллә, соң булмаса?!

## АЛЫПСЫЗ ХАЛЫКЛАР БАР ИКӘН

Алыпсыз халыклар бар икән,
Көннәре тоташтан зар икән.
Таулары тәбәнәк, күле сай,
Урманы-болыны тар икән.

Алыпсыз халыклар – вак икән,
Ваклыгы ап-ачык – хак икән.
Чебен тигәнгә дә: «Чер»,– итеп,
Куркудан йөзләре ак икән.

Алыпсыз халык куркак икән,
Тапканы ятка уртак икән.
Капканы, чәйнәгән, йотканы
Тарыга тарган турта икән.

Алыпсыз халык сукыр икән,
Бер-берсен күрми чукыр икән.
Чукылгач, йолкынгач, табыры –
Тик үләксә чокыры икән...

## КЕМ ИЛЕ?

Читәнгә сөялгән
исерек шикелле
айкала-чайкала
кем иле,
кем иле?

И Илем, Илкәем,
Илкәем, гөлкәем.
Шушы көн килер, дип
юрады кемкәең?

Сырхаудан талчыккан
корчаңгы бу елкы
күтәртеп кыш чыккан
кем иле,
кем иле?

И Илем, Илкәем,
Илкәем, гөлкәем.
Кыйнаудан, талаудан
коткарыр кемкәең?

Салкынга сырт куеп
елаган бүреле
кап-кара төн иле –
кем иле,
кем иле?

И Илем, Илкәем
Илкәем, гөлкәем.
Җәһәннәм төбеннән
коткарыр кемкәең?

# ҖИЛ – АВАЗ ЕЛЛАР БАГЫННАН

*Казан ханлыгының җимерелүенә*
*450 ел тулу уңаеннан*

Җил йөри уятып таңнан
Оныкларның хәтерен...
– Борылып бак, үткәнеңә
Йоклап йөрер чакмыни?..
Күтәр, бастырган ташларын,
Ю тарихың тапларын.
Бел бабаңнар сукмагының
Аерылган чакларын...
Кем арбасына утырып
Кемнәр җырын җырлавың,
Бүген барыннан да мөһим
Хәтереңне җуймавың?!

...Дәште Кыпчак, Хаҗитархан.
Кырым торган кырда.
Явыз Иван басып кереп,
Идел-Йортны кырган.
Янып ауган Шәһре Казан,
Янган Кабан күле.
Янмаган берни калмаган,
Күзне кискән көле...

Кырым, Кыпчак кырда торган...
Явыз Иван тагын
Хаҗитарханны яндырган
Талап бөтен малын.
Янып ауган Хаҗитархан,
Идел янган, яры...
Янмаган берни калмаган,
алган каргыш зары.

Кырым-кырда, Кыпчак Йортны
Ермак кергән ерып.

Ауган Казан, Хаҗитархан...
Йә, кем алсын йолып?
...Янган Тубыл, Җаек, Саян,
Байкүл, Урал, Иртыш...
Янмаган берни калмаган.
Калган әче каргыш...

Кырым кырда. Урда-Йортны
Яккан кара корым...
Ут эчендә Бакчасарай...
Йә, кем килеп йолыр?
...Янган Кырым... хөрмәләре...
Хәрабәдә нигез...
Янмаган берни калмаган –
Янган Кара диңгез.

Янган Урда... Күкләр шаһит:
Берсе торган кырда.
Явыз дошман берәм-берәм
Туганнарны кырган.
Дәүләтләрен яндырган да
Җыеп нигез ташын,
Бүленмәс дәүләт төзегән –
Тугра – козгын башы...

Гасырларның аръягыннан
Исә дә исә җилләр,
Тырнап хәтер яраларын
Кисә дә кисә җилләр.
Җил-аваз еллар багыннан,
Дөньяның дүрт ягыннан
Хәбәр бирә оныкларга:
– Аерылма иманыңнан!..
Үткәнне булмый кайтарып,
Килерең сакла уттан!..
Аерылма туганнарыңнан,
Аерылма Идел-Йорттан!

# КИЕК КАЗ ЮЛЫНДА



* * *

Ук алмаслык арада
зәңгәр күк ник карала?
– Кыйгак-кыйгак тавышлары
бар дөньяга тарала.

Йөрәгемне телеп-телеп,
уеп-уеп ала ла,
Күкне дерелдәткән тавыш
бар Галәмгә тарала.

– Килүләр бар – кыйгак, кыйгак,
китүләр бар – кыйгак, кыйгак.
Калулар юк, калулар юк...
Дөньяда – кыйгак, кыйгак, кыйгак.

# ИР-АТ ИСЕМЕ АЛАСЫМ БАР

Җырларымда һәркайсыгыз өчен ат бар...

*Х.Әюпов*

Иргә, атка сан беткәндә,
Болганчык шушы көннәрдә,
Җырларыңны бер тыңларга
Бик кирәк булган икән лә.

Чабып узды аргамаклар,
Җырың тугайларың иңләп,
– Иярлә дә атлан,– диден,–
Өлешеңә кайсы тигән.

Җырыңдагы тулпарларның
Чыңлап тора тояклары;
Су анасы кызларыдай
Җилферди ефәк яллары.

Яна балкып: йолдыз кашка,
Шомырт туры, алмачуар...
Кешнәп-кешнәп үрә баскан:
– Мине сайлап ал,– ди сыман.

Өлешемә көмеш кайсы:
Шомырт туры, җирәнеме?
«Тугаенда утлап йөргән
Тышаулысы!» – димә генә.

Йөгән кимәде хыялым,
Һәм тышаусыз ихтыярым.
Кирәк фәкать «Канатлы Ат»,
Мин зур юлга җыенамын.

Соң булса да эзлисем бар,
Толпарымны табасым бар.
Күтәрелеп Парнасыма,
Ир-ат исемен аласым бар.

# КУРКАМЫН КАЛУДАН КАРАЛЫП

Җыела-җыела, кушылып,
каралып өелде болытлар.
Каплады тәрәзәм-күзгемне...
Калтырыйм, туңамын, суык ла...

Болытлар, ачулы болытлар
куалар артымнан таралып.
Йөгерәм,
мин чабам, мин качам,—
куркамын калудан каралып...

# АГЫМСУ ШИКЕЛЛЕ

Агымсу — чишмә дә,
Агымсу — инеш тә.
Агымсу — дәрья да,
Агымсудай Кеше.
Кечкенә килеш тә,
Алыптай хәлдә дә.

Чишмә-су шикелле,
Бәрелеп ташларга,
Тиеш син, и Кеше,
Үз юлың башларга.

Инеш-су шикелле,
Баш ими ярларга,
Тиеш син, и Кеше,
Ташырга язларда.

Дәрья-су шикелле,
Мең чакрым җир гизеп,
Эзлә, тап, и Кешем,
Бәхетең диңгезен!

# ҮЗЕМӘ

Сандугачлар сайравын да
ишетә белү кирәк.
Чәчәкләрнең ачылуын
иртәдән күрү кирәк.

Авылдашны очратканда,
сәламли белү кирәк.
Сиңа төбәлгән күзләрнең
серләрен сизү кирәк.

Гаиләнең татулыгын
саклый да белү кирәк.
Үзеңә тугры булганны
хаклый да белү кирәк.

Киләчәкнең матурлыгын
күзаллый белү кирәк.
Кайгыны да җиңеп була,
бәхеткә түзү кирәк.

Имәннәрне юкәләрдән
аера белү кирәк.
Зирәкләрне юләрләрдән
аралый белү кирәк.

Кемгәдер кирәклегеңне
һәрвакыт тою кирәк.
Өлешеңә көмеш тигән,
нәфесне тыю кирәк.

Ваклыклардан, юклыклардан
талчыкма әле, йөрәк.
Гел кайгыдан тормый дөнья,
Шатлана белү кирәк.

# КӨЗЛӘРГӘ КЕРДИСӘМ

Төсләр дә бихисап,
хисләр дә ташкын гел.
Көзләргә кердисәм,
язлардай ташыйм бер.

Көзләргә кердисәм,
ялкынга уралам.
Сап-сары кыңгырау
сап-сары дугада.

Каеннар, таллар да
бизәнгән кызлардай.
Кай якка карама,
алар җыр сузгандай.

Талларда сарылык,
сагышлы моң гына.
Талларга сарылып
тыңлыймын тын гына.

Сап-сары төс алып,
көзләрдә җыр яна.
Җыр-утка уралып,
кем янмый түзала?!

Йөрәгем ут кына,
җаным – ут йомгагы.
Утырып янамын,
кем килеп коткарыр?

Көзләргә кердисәм,
җыр-моңга уралам.
Сап-сары кыңгырау
сап-сары дугада!..

Күңелем – җиз кыңгырау,
көзләрдә чың ала.
Кайтаваз булып бер
чыңлармын дөньяда.

## ИЛҺАМИЯТ, РӘХМӘТ СИҢА

Төннәр озын,
Көннәр кыска,
Кар-буранлы,
Салкын чакта,
Җан җылыга,
Күңел назга
Сусап, язны
Көткән чакта,
Берьялгызым
Карап айга
Сагынганда,
Юксынганда,
Шул сылу кыз
Сыйфатында
Килеп керден
Хыялыма.
И сихри көч,
Илһамият,
Рәхмәт сиңа,
Рәхмәт сиңа!

## САБЫЙЛЫК ГӨНАҺЫ

Чабаталы бабай,
Утыз өч ел узгач,
Искә төште килеп
Үчекләвем сине:
«Хәерче!»– дип көлеп...

Агач таяк таккан
Гарип агай-эне,
Нәкъ синеңчә атлап,
Уңга-сулга түнеп,
Йөрим мин дә бүген.

Юләрләнгән апа,
Яшьтәшләр без бүген,
Утыз өч ел элек
Үчекләдем сине:
– Тиле, тиле, тиле...

Кичә генә кебек –
Ә бит күптән булган.
Мәгънәсез гомергә
Хәйран гыйбрәт тулган.

Кадерсез башкайны
Кайларга куясы,
Гөнаһлы җанкайны
Ничекләр юасы?

## И АВЫЛДАШЛАР!

Сагынып кайтам да
үпкәләп китәм.
Кабат кайтмам, дип,
антлар да итәм.

Булмый икән лә,
сагынылa икән.
Сабантуй җиткәч,
кайтыла икән...
И авылдашлар!..

## И ҖАНЫМ!

Туу-үлү арасында –
Мең төрле төс, мең төрле көч.
Тик Ак белән Кара гына
Үлемсез төс, мәңгелек көч...

Гел Ак булып булмый икән,
Йота икән Акны Кара.
Ак үзе дә Кап-Караны
Кайвакытта агартала.

Яшәү-үлү арасында
Язган Адәм баласына –
Бертуктаусыз ярашырга
Агына һәм карасына.

Күпләр мәҗбүр шуңа, и җаным
Диген: Акны – ак, Караны – кара...

# 1995 ЕЛ ЧЕЛЛӘСЕ

«Иртә килгән – тиз киткән»,
«Җете кызыл – тиз уңа»,
«Ашыккан – ашка пешкән»,
«Кем җитезрәк – шул уза...»

Яшәүнең үз фәлсәфәсе
Салынса да әйтемнәргә,
Ашыгып килгән быелгы җәй,
Ашыкмый һич тә китәргә.

Сентябрьдә – җәйге чиллә,
Чәчкәләрдә күбәләкләр,
Җәй гомере юкса күптән
Куелса да түгәрәкләп...

Тыңладем быелгы җәйне
Йөзьяшәр карт гомеренә.
Озын җәйләр, җылы көзләр
Насыйптыр миңа бер генә!

# ТАНЫШЫМА

Нигә тала йөрәгем?
*Татар халык җыры*

– Йөрәксезләр,– диләр
Куркакларга,
Таш бәгырьлеләргә,
Әнкәсен онытканнарга.
Ишетмәдем һичбер
Шулай дигәнне,
Йөрәге авыртканнарга.

Йөрәклеләр
Аямый үзләрен,
Бәреп керә ут эченә...

Дөмбәсләп ташлансалар да,
Аралыйлар көчсезләрне,
Телен тешләтсәләр дә,
Әйтәләр үз сүзләрен.

Йөрәклеләр,
Яшермичә күз яшьләрен,
Сабыйлар күк елый беләл...
Ачы итеп көлә
Ахмак түрәләрдән
Йөрәклеләр генә...

«Йөрәгем тала»,– дисең...
Димәк,
Бар ул, энем, синдә,
Миһербанлы җаның
Саклый күрсен,
Куәт бирсен йөрәгеңә...

# ЭШТӘН ЧЫККАН ТАТАР КЫЗЫНА

Елар өчен яратылдыңмы?
Көләр өчен яратылдыңмы?
Гомереңдә тик бер мәртәбә
Янып-көеп ярата алдыңмы?

«Кирәк»,– диеп, шулай чаптыңмы?
Бар эзләгәнеңне таптыңмы?
Иблис сузган хәрам калҗаны
«Бисмилла»сыз гына каптыңмы?

...Сөялмәгән чатта баганага,
Шыр ялангач ята софада.
Үгет, оят бүген ни аңа?
Шагыйрь йөрәгеннән кан тама...

# ҖАННЫ ЮУ КИРӘК

Җир йөзендә тәнгә – мунча,
Җанга юк...

*Г. Тукай*

Җанның чисталыгы өчен
Чиста туу кирәк...
Андыйлар бар,
Әмма сирәк...
Ышанма, һәркем дөньяга
Чиста туа дигәнгә...
...Сабый – нарасый?
Канында
Буыннан буынга күчеп йөрүче
Күзәнәкләр...
Явызлык та,
Бозыклык та бар анда.
Шулай булмаганда,
Коръән кушмас,
Шагыйрь язмас иде:
«Җанны бертуктаусыз
Юу кирәк, юу кирәк...»

## КАРАП ТОРА ТУЛГАН АЙ

Тынычлан, тынгысыз күңел,
телгәләнмә бу хистән.
Тешең кыс та дәшмә бүген,
иртә шәбрәк бу кичтән.

Кабаланма, ашыкмачы,
инде юк юл чыгасы.
Язганына азаккача
калды бары чыдасы.

Горур күңелем, өзгәләнмә,–
сынатырга ярамый...
Кояш батты. Тәрәзәмнән
тулганадыр Тулган ай.

* * *

Уйлар,
Тулгансыз да кереп башыма,
Кайнашасыз,
        сүгенәсез,
                сугышасыз.
Ә мин юллар, чатлар каршында...

Күңел,
Хыялларым синдә җанлана.
Очам,
        йөзәм,
                йолдызларга кучәм –
Кырык яшьлек бу үксез балаң.

Мәхәббәт,
Синдәй көчнең бармы булганы?
Болыт,
        янгын,
                кан.
Мин ул сөюемнең корбаны.

Киләчәк,
Күренеп тә торгач күңелдә
Кояш,
        җир,
                һава,
Ник илтергә инде үлемгә?

Бер Аллам,
Насыйп иттең Коръән колыңа –
Тоям,
        таныйм,
                иман җыям –
Үлемсезлек язып куелган.

# ЧОРЫНДА БЕРДӘНБЕР БУЛА...

Родился я в соломе в час рассвета, –
Так хорошо на свете быть никем!..

*Пьер Жан Беранже*

Ялгышларны язмышларга
сылтау да ансат түгел.
Кемдер алдында аклану
әлегә максат түгел.

Заманасын хурларга да
ашкынып тормыйм юкса.
Мактарлыгын да тапмыймын,
түре гел булды тупса...

Ата-ананы сайлап булмый...
туган җир дә бер генә.
Кемдер олтан, кемдер солтан
язмышының иркендә.

Заманны да сайлап булмый,
үзе безне сайлый ул.
Калыбына-кысасына
кирәгенчә җайлый ул.

Аннан бакыр тиен сыман
сугып тора бер көйгә.
Җайлый заман, ямый заман,
калдырмыйча бер җөй дә.

Меңнән бере сайланмый да,
җайланмый да калыпка.
Чорына бердәнбер була,
беркем булмый калып та.

* * *

Күкнең төбе тишелгәнме,
бертуктаусыз коеп тора.
Салават күперләрен дә
бер корып, бер җыеп тора.

Ак яулыклы бүз күбекләр
бихисап күп туып тора.
Гөрләвекләр гөрелдәшеп,
берсен-берсе куып тора.

Гөлләр, үләннәр тын гына
йокымсырап оеп тора.
Җирдәге бу манзараның
Күкләр барсын тоеп тора.

## ...КАЗАН. СВЕРДЛОВ УРАМЫ...

Үзгәреп тора дөньясы –
гаҗәпләнмим хәзер.
Иртә булып, кич югына
әзер күңел, әзер...

Югалттык күпме затларның
асылдан асылын...
Юксынабыз, хисләр кала
хәтергә басылып...

Шөһрәтләре кала кебек...
Хакыйкатьтә исә
пот булып баскан сыннарын
бары җилләр кисә.

Урам, мәйданда атлары –
буяулары купкан.
Иске урам, иске йортны
җир бөтенләй йоткан.

Тиеп тора ярлык-аты
шайтан таягына,
Качып китәр иде чабып,
басса аягына...

...Шөһрәтләре калмый икән
затлар киткәч, китә.
Аксыргактай ачы вакыт
көйдерепләр үтә...

# ЯЛГАН СҮЗ

...Яман сүзнең күңелдән һич
заты китмәс...

*Акмулла*

Ялган сүз – арттан атылган
агулы уктыр.
Зәһәрен йолкып алырлык
дәвасы юктыр.

Ялган сүз – җанга кадалган
тутыккан кадак:
тартып алсаң алмасаң да,
эш үткән – харап...

Ялган сүз – оныкларыңа
күчеп барачак.
Яманат булып, ыруда
мәңге калачак.

# ТАЛКЫНДЫ ҖИР

Көньякта көчле җир тетрәүләр
ай буе дәвам итте.

*Газета битләреннән*

Калтыранды, талкынды җир –
тартылды тамырлары.
Хәбәрләрдә – хәрабәләр:
кыелган меңнәр җаны.

Хәбәрләрдә – хәрабәләр:
сытылган, басылганнар.
Әләмнәр – матәм хәлендә
йөзтүбән асылганнар.

...Талкынды җир... Ыргытылып
очарга теләдеме,
фәхешлектән, вәхшилектән
качарга теләдеме?

Талкынды җир, тамырлары
кылдай калды тартылып.
Мәңгелекнең кочагында
чыңы калды калтырап...

# АХЫРГЫ КӨН

Кемгә хаҗәт гаеплесен табу
гомер иткән җаһил заманның?
Кубарылып Хак каршына бару –
катгый әмер! Тәүбә саналмый.

Мөлкәт – чүп-чар,
тәүбә – сукыр тиен.
Сәҗдә, дога – бары бәддога;
сорап җыйган дөнья фатихасы
чебен тырнагына хак тора.

Ихтыяры хакның – әмер катгый...
Игътибарсыз калмас бер савап...
Иманыңа сыеналырмы җан,
мең сорауга биреп мең җавап?..

# ЕГЫЛДЫК ТА ТОРДЫК...

Егылсак, күргән белгәннәр
Яхшыга юрасыннар.

*Р. Фәйзуллин*

Егылдык та тордык, егылдык та
яра-эзләр ятты йөзләргә...
Заманасы килде... аты корсын...
без җәйләрдә кердек көзләргә.

Егылдык та тордык, гел үзебез
Ванька-встанька торган шикелле...
Нинди заман килә төйнәп йодрык,
Сукса торырбызмы, икеле?!

Заманадамыни, тәкъдирләргә
язылганы шулдыр чынлыкта.
Егыл да тор, егыл да тор, кеше:
торалмасаң, сиңа бер нокта...

# ТӨН

*(«Төнге уйлар» циклыннан)*

Төн.
Кара болыт каплаган күген.
Ник бер адашкан йолдыз күренсен.
Күзе йомык күкнең...

Тын...
Кабер тынлыгына чумып йоклый ил:
кай якка карама – төпсезлек...
Ачсаң да, йомсаң да күзең –
берни күренми...

Тирән базда
ертык бишмәтенә төренеп,
юештән гаҗизләнеп,
йөткерә-йөткерә,
саташа-саташа,
нәзек аякларын сузып
(шәрә тез капкачында канлы яра),
авыр сулап,
куркып, сискәнеп –
үзен балта тотып кууларын
төшендә күреп,
шул базда
йоклый минем дә милләтем...
Күзен ачса,
караңгылык угы
күз алмасын
тишеп үтмәсме?..

# КӨН БЕЛӘН ТӨН

*(«Төнге уйлар» циклыннан)*

Көн белән Төн,
үткәне һәм
киләчәге
янәшәдә –
тиеп тора
бер-берсенә.
– Көн үтте,– дип,
– Төн үтте,– дип,
кем шатлана,
кем көрсенә?..

Көн белән Төн –
ике ягы
бер дөньяның.
Кайсы алды,
кайсы яны –
кемнәр ничек
белсен аны?..

Көннән генә
торган дөнья
булган, диләр;
Төннән генә
торган дөнья
булган, диләр.
Көнле дөнья
гөл-чәчәккә
тулган, диләр;
Төнле дөнья
кар-буранга
чумган, диләр.

Көнле дөнья –
әле дә бар, ди.
Җиде кукнең
түрендә, ди.
Төнле дөнья
күккә тиеп,
кар-буранга
күмелгән, ди,
салкын кулы
төпсез Төннең
иңнәренә
урелгән, ди...

Көн белән Төн –
ике ягы
бер күңелнең;
янәшәдә
тиеп тора
бер-берсенә:
бер шатлана,
бер көрсенә;
бер ашкынып,
җиде күкнең
түренә ук
очмак була,
бер салкыны
сөңге бозлы
озын кулын
сузып, җанны
кочмак була...

Көнем – Төнем
янәшәдә,
тиеп тора
бер-берсенә,
Көнем – Төнгә
Төнем – Көнгә,
охшаш булса –
гаҗәпләнмә:
камиллектән
ерак торган
фанилыкта
мин дә бер зат –
Кеше ләса!

Көнне – Төнгә,
Төнне – Көнгә
гомер озын
ялгасым бар.
Бу дөньяда
яшәдем дип,
Хак алдына
басасым бар!..

## ...ДИДЕ АКЫЛ

...Сизәм: эт елы,
мин, укчыга,
миһербанлы түгел син.
Юкса
капкадан чыгуга,
ырылдап ябырылмас иде
йолкыш көчекләрең...

Сизәм:
күптәнге хыялыгыз –
тубыгымнан тешләү
быел насыйп булыр кебек.
Сез, этләргә –
моңарчы:
– Чәбә,– дип тә,
калҗа биреп тә
кача идем дә...

Сизәм: быел
сез, ач күзләрдән,
булмастыр котылып,
инде
кайбер көчекләрегез,
күзе ачылмас борын,
ырылдады котырып.

Сизәм:
морадына җитәр
кайбер бурзайларың...
Ярый ла
тешләп кенә китсәләр,
ботарлап сөякләремне,
чүплектән чүплеккә

өстерәп йөртсәләр
урам этләре
бик тә кирәкле
эш эшләгән кебек –
нишләрмен?..

...Бозлы су койгандай
куырылып җыелды җаным,
киерелде акыл һәм:
– И, Укчы, онытма
дәһшәтле һәм зирәк
Аждаһа икәнең!!! –
диде.

# ЗАМАНДАШКА

Арын арык уйларыңнан, алга бак,
Күргән – үткән, күрәчәгең алдарак.

Тәһарәтсез шайтан кочып күп яттың,
Барлы-юклы иманыңны югалттың;

Күкләр зәңгәр, таңнар алсу булмас гел,
Сулар сибеп торсаң гына сулмас гөл,

Теләгәнең телем-телем теленеп,
Калмас димә, буй җитмәслек эленеп.

Эзләгән кемдә, мәгънәсен тапмаган,
Җиһанны шайтан мәңгегә таплаган.

Хис, акылы тәрәзәсен япмага
Нур үтмәслек итеп шулай каплаган;

Шуңар шайтан сүзен сөйли телебез,
Көне-төне шайтан көен көйлибез...

## ҖАВАП

Бозлы кулын сузды кемдер
күңел көзгемә,
салкыны калды ягылып –
түзсәң түз генә...

Тәрәзәмә дә таш атып
киткән иде ул.
Гөлләрем йөзе телөнеп
беткән иде гел.

Зәңгәр чуклы мәет кулы
икән ләбаса.
Әрсезләнеп тәрәзәмә
килә дә баса.

Авызымны каерып ул
йотылмак була.
Җиһанда бар гөнаһыннан
котылмак була.

Юхаланып күңелгә үк
үтеп кермәкче.
Зәхмәтеңдә гөлләремне
гел үтермәкче.

Уй булып та, буй булып та
сузыла кулы.
Чүплек эзләп, җил булып та
тузына кулы.

Юк,
бу кул җәнҗалчы шайтан –
йөри эш табып:
җаным суында юмакчы
шакшы ыштанын...

Мең яктылык елыннан ук
килеп җитеп тә,
җанкаема тидертмәмен
кулын ничек тә.

Җырларымны мин җанымның
җанынннан алам.
Янып бетү – бу җиһанда
бердәнбер чарам.

Зәңгәр чуклы мәет кулы
чүплектә калыр.
Җаным таңнарда яктырып,
җырга уралыр!..

# ...ДИМӘГЕЗ!..

Еламсык шигырьләр язып,
тутыргансың китабыңны.
Якты ягын бу дөньяның
күргәнең гел булмадымы?..

Еламсык шигырьләр язып,
туймаган бу, димәгез.
Дөньяның бер якты ягын
тоймаган бу, димәгез.

Кайгы базларыннан бер дә
чыкмаган бу, димәгез.
Гомере буе җырламаган,
сыктаган бу, димәгез.

Сандугачның сайрауларын
тыңламаган, димәгез.
Чишмә җырына кушылып
чыңламаган, димәгез.

Сөю гөленә уралып
үрмәгән бу, димәгез.
Хыянәттән ары берни
күрмәгән бу, димәгез...

Утларына кереп яндым,
балкыды күңел күгем.
Күпләр елап хатлар язды:
– Булсаңчы бердәнберем!

Ташыганда Агыйделнең
бозында учак яктым.
Тулганайга юлдаш булып,
диңгезгә кадәр актым.

Алтын чыкның керфегендә
нурлар кисешкән чакта,
ак күбәләкләр дуамал
ташлаганда учакка,

ак болытларга бактым мин,
ак болытта актым мин...
Айга менеп Зөһрә кызның
кочагында яттым мин...

...Еламсык шигырьләр яза,
тагын сыктый, димәгез...
Яралы җаным сулкылдый,
ялгыш та бер тимәгез!..

# КӨЗДӘ БЕР МӘЛ

*(«Ел фасыллары» циклыннан)*

Бөтен тирә хәрәкәтсез,
Дөнья тынып калган сыман.
Күл өстендә каз мамыгы –
Йокысына талган сыман.

Мәрткә киткән тал, ярлары,
Сызгырмый бер курасы да.
Ак болытлар туктап калган
Җитеп күлнең уртасына.

Гаҗәп тынлык.
Сихри тынлык...
Шунда кинәт сизеп калдым;
Камышлыклар арасыннан
Йөз күз нурын тотып алдым.

Таллар, ярлар, камышлары,
Куралары җырлап тора.
Әрәмәдә алтын көзнең
Мең бер кылы чыңлап тора!..

Кыр казлары китеп бара,
Язлар җиткәч, кайтырлар бер...
Алтын көзнең илаһи вә
Күңелләрдә калыр мәле!..

# КЫРЛАЧНЫҢ СОҢГЫ КӨНЕНДӘ

Кырлачның соңгы көнендә
котырды давыл.
Кара буранга күмелде
мең йортлы авыл.

Абзар-кура өсләрендә
дулады шашып.
Инеш-елга ярларын да
тутырды ташып.

Урам, кырны, бакчаларны
тыгызлап өйде.
Кар өстендә батмый басып
торырлык иде.

Көн-төнен котырган буран
таңда басылды...
Күк гөмбәзенә миллион
йолдыз асылды...

Кырлач төне — бүрәнәләр
шартлап ярыла.
Шунда да сабан туйларын
күңел сагына...

# ЯЗНЫҢ ТӘҮГЕ КӨННӘРЕ

Тып-тып, тып-тып тамчы тама,
Тамып тора бер җайга.
Чыңлап тора, җырлап тора,
Сихри тамчы бугай ла.

Тамчы тама, тамчы тама,
Ул – шатлык тамчылары.
Тама-тама табигатьнең,
Шәт, язны каршылавы.

Көлешеп тама тамчылар,
Рәхәт шатлыкка тулып.
Күр, ничек бөре ачыла –
Кояшка йөзен борып.

Тоеп кал, и сизеп кал, син,
Бөреләрнең шул хәлен.
Җирне күкләргә бәйләгән
Мәңгелекнең бер мәлен!..

# ЯЗДАН ҖӘЙГӘ КҮЧКӘНДӘ

Мөтә ташып ярларына
чигеп утырды,
балан, шомырт чәчкәләре
балланып тулды.

Талларында сандугачлар
бер дә тынмады.
Тургайлар да болытларга
җитеп җырлады.

Бал кортлары үзләренә
тынгы бирмичә,
чакрымнарны урап кайтты
ничәмә-ничә.

Монда гына күбәләкләр
яңгыры бугай.
Мең төрле төс, мең бер аваз
яңгырый бугай.

Бар да җырлый, җырлап һичкем
арымый бугай.
Монда кояш бер чыга да,
баемый бугай.

Мөтә-инеш яры текә,
чакма таш комлы.
Мөтә суы алтын тәңкә,
көмеш чулпылы.

Сикереп биеп, бөтерелеп,
ташларны үбеп,
күбекләнеп ага инеш
кеткелдәп көлеп!..

Табигатьнең күңелләргә
хуштан хуш чагы.
Чакырып ала үзенә
җәеп кочагын...

## БАРЫБЕР ЯКТЫ БУ ДӨНЬЯ

Кемгә ни хаҗәт уфтаныл
төн чыгуың утырып.
Кырып ат инде куптарып
күңелеңнең тутыгын.

Һәр үткәнгә салаватны
әйтеп кыл, кешем, тәүбә.
Барыбер якты бу дөнья,
тиң бәхет юк яшәүгә!

Өлешең бар, көмешең бар,
той җылысын, мул чагын,
сүндермәсен тозлы яшең
өметеңнең учагын!..

Күктә – кояш, ай, йолдыз бар.
Җирдә – сөю, мәхәббәт...
Барыбер якты бу дөнья,
яшәүгә тиң юк ләззәт...

# САГЫШ КИТАБЫ



# САГЫШ

Урынсызга рәнҗетелгән
Ничәмә-ничә җаннар,
Көз җиттисә, сагыш булып
Кайталар безнең янга.

Тәрәзәдә яңгыр түгел,
Күз яшьләре аларның.
Оныкларын эзли җаннар,
Өметләнеп табарын.

Кайсы калгандыр карында,
Кайсы түшәк чылатып.
Оныкларын эзли җаннар
Бөтен дөнья буйлатып.

Оныкларын эзли җаннар,
Йөзләреннән төсмерләп.
Табыла да бит оныклар,–
Йөзләренә көз кергән.

## САГЫШ КИТАБЫ

Минем дә бар
сагыш китабым,
күңелемдә йөртсәм дә,
кәгазьгә күчермәдем аны...
Йокысыз төннәрдә
актарам — укыйм китабымны:
сагышлы, бик тә сагышлы шул...

Күз алдыма,
күреп белгән,
        гүргә кергән
танышларым килеп баса:
кайсы — җәяү,
кайсы — атта,
кайсы — уйчан,
кайсы — елмая...

— Таныйсыңмы? — дигән сыман,
дәшми генә
        карап тора
                сөйгән ярлар.
— Таныймын,— дип,
— Сагынам! — дип
җавап бирәм дә...
Күзләрем яшьләнә...

Китабым —
        йомгак-йомгак
                эрләгән җеп:
ул
чорнап барган уйларымны,
кайчан да бер
кирәге чыгар,
        дигән сыман...

Бар: уйландыра торган уйлар,
вакыт саргайтмаган һич тә –
уйланырмын иркенләп бер
ялгызым калган кичтә.
Бар: уйларның йончыганы,
зәгыйфьләре,
беркатлысы,
тозсызлары.
Бар: сискәндерә торганы,
төссезе,
салкыннары...

Китабым сагышлы, сагышлы шул...
Сагышларны таратырлык
ниләр соң кылыйм икән?
Урманыма кереп,
әллә
кычкырып җырлыйм микән?
Сагышларны таратырлык
җырын кайдан табасы?
Бу сагышлы замананың
без – сагышлы баласы...

## БУ ЯШӘҮ КӨЕДЕР

Агыйдел ярлары
гөлҗимеш, миләшлек.
Дулкыннар ярларга
торалар гел дәшеп.

Дулкыннар нәниләр,
тын гына җил булса;
давылда, давылда
дулкыннар бик усал!..

Нәзек җил таң белән
Иделгә сер дәшсә,
дулкыннар, пышылдап,
ярларга күчерә;
аннан соң яфраклар
берсеннән-берсенә.

Бу – яшәү көедер!

Дулкыннар кебек үк
безнең дә бу җиргә
килүләр-китүләр,
гомерләр итүләр...

Дулкыннар тагы да
кагыла ярына.
Яр – елъязмачы;
 эзләре языла...

# КАУРЫЙ БОЛЫТТА ТИБРӘЛӘ БЕР ТӨЙМӘ

...Ничек шулай
сайрый Тургай,
нокта гына кебек лә?!

*Р. Мингалим*

Кызу җәй
уртасы –
каурый
болытлар
читендә
бер төймә:
– Нишли ул...
– Нишли ул?

Шул төймә
туктаусыз
тибрәлә,
талпына,–
әйтмәкче
буламы
бер сүз Җир
катына?

Әллә соң
ул төймә
Киек Каз
Юлына
очарга
ашкынып
талпынган
Бөркетме?

Кемнәрдер
күрә дә,
кемнәрдер
күрми шул;
кемнәрдер
сизә дә,
кемнәрдер
тоемсыз...

Әлегә,
белмиләр,
әлегә
сизмиләр;
Ул – Тургай,–
бу чиксез
галәмнән
өр-яңа
җыр эзли!

Яңа җыр
Җиһанга
бик кирәк,
шулчаклы,–
бәйләп үк
торыр ул
галәмгә
Җир шарын!

Кызу җәй
уртасы,–
яна Җир,
Җир көя...
Галәмдә
Җыр эзләп,
тибрәлә
бер төймә!..

# ТЫҢЛЫЙК ӘЛЕ ТЫН ГЫНА

*(Җырга мәдхия)*

Ачыла сәхнә пәрдәсе,
уйнап тора оркестр.
Түгел лә...
«Япон әрҗәсе»
бигрәк инде талымсыз.
Ни кушсаң, шуны уйната –
торба, курай, думбыра...
Робот җырчы да ясарлар,–
алар барын булдыра.
Тик ул чакта сәхнә нигә,
тамашасы ник кирәк?
Рәнҗемә, «япон әрҗәсе»,
җанга тере җыр кирәк.

Күңелнең мең дә бер кылы
тартылып чыңлавыннан
яралган көй генә җанда
сүнмәс ялкын кабызган.

Чишмәләрнең чуерташка
бәрелеп агуларын,
күктә атылган йолдызның
балкып бер януларын...
Тулып өзелгән тамчының
нур чәчеп тамуларын,
пар атларда кыңгырауның
чың-чыңлап калуларын,
чәчкәләрнең керфегенә
көмеш чык кунуларын,
җиләкләрнең, бөрлегәннең
балланып тулуларын,
Агыйделдә камышларның
серле итеп шаулавын,

аккошларның канат кагып,
берсен-берсе аңлавын,
талларында сандугачның
өздереп алуларын,
яшь сылуның, оялудан,
кызарып януларын,
җиһанда галиҗәнап өн –
Сөю-сәгадәт барын,
Мәхәббәт – йөрәк зарын
кем әйтеп бирер тагын?!

Җанда туган җыр гына!
Җанда туган моң гына!

Сызган Ай да, тулган Ай
җырлый-җырлый тулгана.
Җырлый – җырламый димәгез,
Җырлый хәтта Җир-Ана!

Тыңлыйк әле тын гына,
Җанда туган җыр гына!

Җирне, Күкне бар иткән,
һәрнәрсәне пар иткән.
Шуңа яшәү бар икән,
җырлап яшәү хак икән!

Тыңлыйк әле тын гына,
бар җиһанда моң гына!

Ачыла сәхнә пәрдәсе –
күңелләр дә ачыла.
Күңелнең мең дә бер кылы
тартыла да җыр чыга!

Тыңлыйк әле тын гына.
Җанда туган Җыр гына!

## ИЗГЕ СУКМАК

Үлән баскан иске сукмак таныш,
Беләм аның кая илтәсен.
Урман уртасында умарталык:
Умартасы юк та, киртәсе.

Алан уртасында куш нарат юк,
Кисеп алган икән кайсысы?
Питрау көнне кортлык аланына
Авылның бар бала-чагасы
Җыела идек карга боткасына,
Сабантуйга җыелган сыман.
Кушучларда имән яфрагы,
Аңа нәкъ бер кашык бал сыя...

Умартачы Гаязетдин агай,
Бабасыннан калган һөнәре.
Югалтса да яуда аягын,
Югалтмаган олы йөрәген!

Агач табак, агач кашык кулда,
Дистәләгән күзләр төбәлгән.
Ак башлыгы ап-ак күлмәк кигән,
Агач аяк аерып терәлгән.

Ул бал сала имән яфрагына,
Һәр кушучка тулы бер кашык.
Безнең генәмени, үзенең дә
Бәхеткәе түгелә ташып!

Сабыр иткән – морадына җиткән,–
Иң ахырдан басып торганга,
Гаяз абый баллы шул калагын
Миңа бирде ялап куярга!..

Имән яфрагында юкә балы:
Тәме, төсе, исе хәтердә.
Телем йотып, онытмадым микән
Шулчагында рәхмәт әйтергә?..

Тузганаклы шушы иске сукмак
Изге сукмак булган лабаса.
Авылым урманына кайткан саен,
Күңелемне татлы моң баса...
Күңелемне баллы моң баса!

## ДИМӘК...

Все исчезает – остается
пространство, звезды и певец.

*О.Мандельштам*

Эфирда җыр...
Балачактан таныш,
күңелгә ятыш моң агыла...
Биектә, биектә,
ак болытларга терәлеп,
бер нокта талпына,–
телиме аерылырга җирдән?
Димәк, җырдан да...
Талпына, талпына...
Ул үзенә җырны чакыра...
Димәк: ул – җаны
вафат җырчының.
Сусаган үз җырын тыңларга...

# ШАГЫЙРЬ ЯНГАН

Шәмдәлләрдә утлар янган,
Таңга кадәр Шагыйрь язган,
Халкын телсез диюләре
Чеп-чи ялган,
Чеп-чи ялган!

Җырда җаны дөрләп янган,
Йолып ил-йорты карасын,
Ач-ялангач үксез бала
Каян көч-куәт алган соң?!

Янып беткән, тик сүнмәгән,
Әверелеп ут шарына.
Шагыйрь рухы балкып тора
Мәңгелекнең кочагында.

Шәмдәлләрдә утлар янган,
Халкым, диеп, Шагыйрь янган!
Үлемсезлеккә юл ярган
Йөз ел алдан,
Йөз ел алдан!

# КИЕК КАЗ ЮЛЫ

Киек Каз Юлы – ак дәрья,
ага да ага микән?
Йолдызлар, тезелеп ярга,
учагын яга микән?..
Яланаяк яланында
малайлар чаба микән?

Киек Каз Юлы – ак мамык,
язылган канатлары.
Кайларда икән
казларның
кайтып китәр яклары?..
Малайлар килә узышып,
ак күбектә атлары!..

# СИСКӘНЕП ТАРТЫЛДЫ ХӘТЕР

Аяз Гыйләҗевнең «Мостафа»
әсәрен укыгач

Һәр төбәкнең Муллины
утызынчы елларда
ярлы-гидай һәр мужик:
– Мин җирле, –дип торганда,
өмет сабын сындырып,
кылыч бирде кулларга:
– Туганыңны чак,– диде,
– Туганыңны чап,– диде...
Төгәл-кырыс кулланма...

Һәр төбәкнең Мостафасы
утызынчы елларда
халкының каш-күз арасын
ядрә белән ерганда,
юылды уелган җаннар,
чи ит белән буталып
сузылды, утлы еландай,
оешкан кан тутыгы,
Черек күлне тутырып...

Мостафаның, Муллинның
оныклары туганда,
бабалары кулланмасын
өлге итеп куйганда,
оешкан кан тутыгына
күбәләкләр кунганда,
Черек күлнең аръягында
кызарып Ай тулганда,
сискәнеп тартылды хәтер...

# ХӘТЕР

Яздан көзгә – кардан карга
Барыбыз да яланаяк...
Ат та шул ук, йөгән дә шул –
Карамадан кәкре таяк.
Песи борчак, карга күзе,
Җитен-орлык, кәҗә сакал...
Ник аларны бер сәбәпсез
Хәтеремдә мин яңартам?
Карга, саескан, тәкәрлек...
Тагын, тагын
Күпме кошның
Ояларын туздырдык та
Йонсыз, шыксыз, сукыр
Сабыйларын җиргә бәрдек!
Йа Ходам...
...Кемнән шулай
вәхшиләрчә үч алдык
Без –
Сугыштан аяксыз кайткан
Әткәйләрнең
малайлары?..

# БЕР СҮЗ ҖИТӘ

Гомер – агач, диләр иде,
Куак кына булдыкмыни?
Тумак булган бу дөньяга
Кунак кына булдыкмыни?

Гомер – дәрья, диләр иде,
Басып торам тездән суда.
Килә кинәт ярдан чыгып,
Кубарылып ташысылар.

Гомер – бакча, диләр иде...
Ак бәс сарган чияләрем! –
Җәйләр җитәр, җимешләрен
Кемнәр килеп җыяр әле?..

Гомер – Китап, диләр иде.
Язылган ул – басылмаган.
Кош теледәй шул китабым
(Мирас итеп оныкларга
Насыйп итә күр, Бер Аллам).

Гомер нигә диңгез түгел?
Юкса күңел шуңа тиң лә!
Бик ямансу бүген төнен,
Түгелергә
Бер сүз җитә,
Бер сүз җитә...

## ЙӨЗЛӘРЕМДӘ КӨЗ ТӨСЕ

Өметсез шайтан, диләрме?
Шайтандыр мин, шайтандыр,
Шайтаннарның вәгъдәсенә,
Төшенмичә хәйләсенә,
Нык алдандык кайчандыр.

Хәрәкәттә бәрәкәттер,
Йөрегән таш шомадыр.
Асылташлар таш астында,
Җилкәләргә таш асылган,
Алып булмый шуңадыр.

Сабырлар сары алтындыр.
И җаным, син «түз» дисең.
Сабырлар итеп саргайдым,
Сарылып ягылды кайгым,
Йөзләремдә көз төсе.

## БЕЛМИ УЛ, АЛДЫЙ...

Кәккүк тавышын санадым,
Төрлечә юрап карадым:
«Ни өчен алты?..»
Күптән язып куелган бит,
Кәккүк кисәтә бары тик –
Күпмесе калды...
Баласын җуйган күке кош
Язмыш хәбәрчесе, имеш...
Белми ул, алдый...

## УЙЛАРЫМ

Уйларым бәйләнгән таш сыман,
Таш-уйдан башкаем талчыга.
Моңсу уй түгәмдер күзләрдән,
Узышта ал биргән ат сыман.

Уйларым – җиде кат күк минем,
Күкләрдә уй-йолдыз атыла.
Диңгездә уй-җилкән адашкан.
Дулкыннар өстендә атына.

Уйларга уйларым урала,
Уелам, уелам – шул гына.
Уйлардан кем мине аралар?
Ул гына, ул гына, ул гына...

# БЕРКЕМ ДӘ ДӘШМӘДЕ...

Когда распрощавшийся задерживается,
все молчат...

*Геннадий Айги*

Кеше гомерен
Исәплиләр еллар белән,
Айлар бик кирәктә генә өстәлә.

Бүген исә
Айлар, еллар түгел,
Ә минутлар җитми өстәргә.
«Аңа егерме биш»,– дип,
Күмдек аны.
Беркем дә дәшмәде...
Бары куллар гына эшләде.
«Миңа килмәс»,– димә,
Булмый белеп дөньялыкның
Иртәгәсен ниләр эшләрен.
Кеше күңеле ерак.
Барып җитәр өчен,
Еллар, юллар кирәк үтәргә.
Кеше үлә,
Күңелен аңламыйча,
Туры килә шулай күмәргә...
Ә соңыннан
Үз-үзеңә
Ачы сагыш белән түләргә.

...Беркем дә дәшмәде,
Бары куллар гына эшләде...

# КӨЗ – КӨТЕП АЛГАНЫМ

Көз – көтеп алганым:
өзелгән ялганып
бәйләнер төенгә –
беленмәс җөе дә.

Көз – көтеп алганым:
алтынсу таңнарым,
тулыр ла күңелем
алмадай балланып.

Көз – көтеп алганым:
уйларым – көмеш су,
күңелем юылып
илһамга туенсын!..

Көзләрдә янганым,
күмергә калганым,
язларда ташыйм, дип,
йөргәнмен алданып;

Көз – көтеп алганым:
өметләнеп, теләп,
йолдызлар атканын.
Төнозын бакканым –
Киек Каз Юлында
канатым какканын.

## ТӘРӘЗӘМДӘ АВГУСТ ТӨНЕ

Бүлмәмдә ялгыз берүзем,
ялгызларга бир түзем.
Нигә юрыйм, иртәдән үк
тарта һаман сул күзем.

Үпкә дә юк, үкенү дә,
салкын битарафлыкка
салынган күңел,
                                        әзер ул,—
сал суга, йә сал утка.

Фани дөнья;
аңа һичбер
ышанычым калмады:
бирәм, диде — бирмәде ул,
алам, диде — алмады...

Фани дөнья;
баш югалтып,
йөрер чаклар үттеме;
кәҗәсе дә, мәзәге дә,
безнең өчен беттеме?

Күрәселәр күргәненнән
бихисап күп югыйсә...
Тәрәзәмдә август төне,
җил исә дә җил кисә...

...Язам, язам — язар сүзем
юк та кебек, нишләтим?!
Тәрәзәмдә август төне —
керфек какмыйм ничә төн...

Тәрәзәмнән басып керә
төн уе — әй, өйбасар,

тимә, тимә, сузма кулың,
туйдым сездән – мин качам.

Төн уе– Иблис уемы,–
барыбер кебек юкса;
уйдан уй яман, диләрме,–
ни эшләрмен уй сукса?..

Кеше китә – уе кала,
диләр шушы дөньяда.
Ябышып каламы уйлар,
әллә адашып кала?

Уйлар тулды башкаема,
башкаем – уй чүлмәге;
сугып кына ватар идең –
катлы-катлы күлмәге.

Уйлар уядыр Җанымны,
сораулар туа тора;
көн җитмәсә, озын төн бар –
җавап көтеп Ай тора.

Тагы җавап сорыймы Ай,
тагы сорау куямы?..
Күк каршында бер чарасыз
Кеше басып торадыр.

Бер чарасыз – мин чанасыз,
атлар җигәләммени,
синсез калып, чит җирләрдә
рәхәт чигәләммени?

Тулпарымда чабып кына,
очып китәсем килә,
җан җылыткан җылы якка
барып җитәсем килә.

Җаным тарткан ул җылы җир –
Җан яратылган җирдер.
Яралы җаным сулкылдый,
Җан яраткaным – синдер!..

...Җаным тарткан, каным тарткан
җирләргә кайтыйм дисәм,
килмешәк уйлар, ашыгып,
хыялым юлын кисә.

Шуңа язам, язамдыр мин–
чарасыздан язамдыр,
языйм әле, язмый торсам,
йә акылдан язармын!..

# СИНЕ ЭЗЛӘП КИЛДЕ ҖАНЫМ



# УЙЛАНЫП ЙӨРГӘН ИДЕМ

Урманнарга кергән идем,
Уйланып йөргән идем.
Агыйделнең уртасында
Агымга йөзгән идем.

Ялгызым калган бу төндә,
Йолдызга менгән идем.
Йолдыздагы зәңгәр күлдә
Йөзеңне күргән идем.

Таң алдыннан чишмә-судан
Ятып су эчкән идем.
Сызган кашлы туган Айга
Серемне чишкән идем.

Ай аша да күзләремә
Син карыйсың елмаеп,
Чакырасың сузып кулың,
Насыйптыр син, мөгаен.

## ЮЛГА ЧЫКСАМ

Калалар,
Өметләнеп
Күтәрелгән куллар,
Ялварулы күзләр,
Янган машиналар...
Баганалар
Чакрымнарны
Санап бара...
Калалар,
Юл тузанына буталып,
Адашкан уйлар,
Күзаллаулар...
Әйләнә дөнья...
Калмыйча,
Узып барысын,
Иң алдан
Йөзеп бара
Синең рәсемең.
Ул кисеп үтә
Урманнарны,
Елга-сулыкларны,
Төтен, томаннарны.
Миңа төбәлгән
Зур күзләрең
Үтеп чыга
Күперләрне,
Туннельләрне...
Ап-ачык күрәм:
Изүе ачык
Ак күлмәгеңнән
Күкрәкләрең
Түгелеп чыккан.
Офык читеннән

Кемдер үреләә –
Сиңа кул суза.
Юлга чыксам,
Гел шулай була.
Ә гомерем юлда уза.

## СЕРЛЕЛЕК

Мендәренә чумган
Нарасый бик серле.
Яшь бер сылукайның
Карашы бик серле...

Сызып үтте яшен,–
Гөрелдәве серле.
Алсу иреннәрнең
Дерелдәве серле.

Ап-ачык димәгез,
Ап-анык димәгез,
Безнең яшәү серле,
Безнең сөю серле!

## СӨЮ КАЛЫР

Бик серле төн бүген,
Нидер булыр кебек.
Тәрәзәдән бүлмәгә
Нидер тулыр кебек.

Яндырып, нур чәчеп,
Күктән төшәр нидер.
Ачылыр күк бүген
Гаҗәеп олы сер.

Үзгәрер бу төндә
Кешеләр үзләре.
Үзгәрер көлү дә,
Елау да үзгәрер.

Үзгәрер һәммәсе,
Таркалыр, яңарыр.
Үзгәртми мәгънәсен
Җирдә сөю калыр...

* * *

...Көзге кояш кебек,
кинәт
сүрелгән идең.
Көтмәгәндә ятлар белән
күренгән идең.
Бәгырьләрне телде яра,–
кагылма берүк,
ятлар да ят иткәч кенә,
сарылма берүк.
Кояш батты, ай да чыкмас
болытлы төндә,
калсын кыйналган хисләрем
хәтер төбендә...

## КҮККӘ УТ ЯГЫП ТӨНОЗЫН

Тулган Ай,
аһ дигәнче,
болытларны юып алды –
каурый-каурый
канатлары
язылып калды.
...Керфегеннән
өзелеп төште
тәлгәш-тәлгәш тамчылары.
Күккә ут ягып,
төнозын
язмыш ялгызны камчылады...

# КАДЕР ТАУЛАРЫНДА КАР-БУРАН

(*Җыр*)

Кадер тауларына кар төшкән,
Безнең эзләр калган күмелеп.
Кычкырасым килә бар көчкә:
– Аерылышмагыз, түзегез!..

Кабат мәңге язлар килмәсме?
Кадер тауларында кар-буран...
Тешләп булмый икән терсәкне,
Йөрәк итен тырнап җылый җан.

Кадер тауларында кар-буран,
Безнең эзләр калган күмелеп:
Язмышлардан узмыш юк, беләм,
Зинһар, гафу итә күр мине.

## ЯШӘР ӨЧЕН

Кинәттән атылган йолдыз
Йөрәгемә кадалса,
Чыккан җанымны озатып,
Җиде адым баралсам,
Кайтарырга җанны тәнгә
Шунда куәт табармын:
Яшәр өчен синең белән
Мин яңадан яралып.

## ӨН БУ, ӨН

Йөземә
ягыла
исе һәм
җылысы
йөзеңнең...
Исердем,
йолдыздан
йолдызга
очамын;
Җидегән,
Чулпанны
кочамын –
төшме бу?..

Керфегең
керфеккә
үрелде,
иреннәр
бөтенләй
күмелде –
төшме бу?
Өн бу, өн!
Төн бу, төн.
Күктә Ай –
табадай –
бербөтен!..

# КИЛ ӘЛЕ

(*Җыр*)

Килеп кер дә, ягыл әле,
сөйгәнем толымыдай.
Иңлә җаным тугайларын,
күңелем колыныдай.

К у ш ы м т а:

Дөрләт әле, балкыт әле,
йөрәк талмасын көзен.
Бүләк итим сөйгәнемә,
бәхет алмасын өзеп.

Нурлар чәчеп, күк йөзендә
очарга тели җаным.
Чулпан белән Җидегәнне
кочарга тели җаным.

К у ш ы м т а.

Кил әле, кил, ягыл әле,—
җылы җыр тели җаным.
Җырга сусаган ярларга
түгелим таңга чаклы.

К у ш ы м т а.

# ТАПТЫМ ДА ЮГАЛТТЫМ

Таптым да югалттым аны,
Әйтегез, нишләргә соң?
Бәргәләнеп елый җаным,
Терсәкне тешләргә соң...

Үрә басты алмачуар,
Кулда калды нуктасы.
Ары чаптым, бире чаптым,
Ничек куып тотасы?

Җәяүләп тә җитәр идем
Җирнең җиде читенә;
Алма чагым — алмачуар
Шунда китә, диюгә...

Таптым да югалттым аны,—
Кулда калды нуктасы;
Әйтегезче, ниләр эшлим,—
Юлның бары уртасы?..

# НИШЛӘРМЕН?..

Карашларны
очраштырган мизгел
яшен тизлегеннән дә
булды тиз;
шартлавыннан куркып,
йомдым күзләрем...
Түм-түгәрәк экранда
янып калды ике күзең:
Аһ, алар ничек
чирканып карыйлар?..
Кайчандыр яшьләре тамган,
ялварулы сөю хатлары язган
затның карашы – корым...
Керфекләрем күтәрелми
катып калды...
Нишләрмен,
күзләрем ачып
берни күрмәсәм?..
Экрандагы
түм-түгәрәк күзләреңнән
канлы яшь саркып чыкты,
ул, сөңге боздай,
эленеп калды...

Еракта – урман, тау артында
төнозын
аҗаган уйнады...

* * *

Телим: йөргән
сукмагыңа
яфрак булып
ягылырга;
керфегеңә
таң чыгыдай
сарылырга;
әверелеп
юрганыңа,
күкрәгеңә
ябылырга;
югалырга
җилдә тузган
толымыңда;
суырылып
иренеңә
йотылырга,—
яшерен сөю
коллыгыннан
котылырга...

# УМЫРЗАЯ

(*Җыр*)

Синең хакта языласы җырым
Тынгы бирми бимазалый гел.
Кар суында япа-яланаяк
Басып тора умырзая-гөл.

К у ш ы м т а:

Умырзая, умырзая,
Иртәләгән яз иде;
Учларыңда умырзая,
Күзләреңдә наз иде.

Синең хакта языласы җырым,
Умырзаям – күз алдымда гел.
Актарылып аккан ташу суда
Кочак-кочак умырзая-гөл.

К у ш ы м т а.

Синең хакта языласы җырны
Язармын да кемнәр җырлар соң?
Умырзая – тәүге мәхәббәтем,
Җырым һәрчак сәлам юлласын.

К у ш ы м т а.

# СИН ТУГАН БУ ТӨНДӘ

Син туган бу төндә
Иделне боз тотты:
таллардан аерып,
ярлардан аерып,
капты да ул йотты,—
кем шулай котыртты?..

Агыйдел — алкын су,
җаныма ялкын су,
шул төндә югалды;
таллары, ярлары
ак бәскә уралды —
көн күрде — төн алды.

Табигать көчендә:
Агыйдел өчен дә,
тал-ярлар өчен дә.
Күмерләнә-көя
яшен-ут җанкаем
суык тән эчендә...
Син туган бу төндә...

# ОЧЫП КЫНА КАЙТЫР ИДЕМ

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
кире кайта торган юл булса.

*Ә.Ерикәй*

Уй-хыялда, кулсузымда
и тиле яшь чакларым.
Утрау-утрау булып яна
хәтерем учаклары.

Яна учак – тәүге кабат
учыңны алып учка,
таңгача серләр серләштек
утырып утыргычта.

Очкыны – синең караш ла,
ялкыны – минем теләк;
яна учак, җырлый учак:
– Юк сездән бәхетлерәк!

Яна учак, дөрли учак,
янмыйча калалмый шул;
учыңның тоям җылысын,
үзеңне табалмыйм шул...

Яна учак, дөрли учак.
«Ризамын»,– ди карашың.
Чынбарлыкта – юк янымда,
кайда калдың адашып?

Өйрәтелмәгән тай кебек
алып чабар чакларым,
очып кына кайтыр идем,
юк шул инде чаптарым,
качып киткән чаптарым...

## СИН МИНЕКЕ ДӘ, ТҮГЕЛ ДӘ

Син минеке дә, түгел дә...
Елыйммы, йә көлимме,–
беркетергә үреләм бит
инде телгән телемне.

Син минеке дә, түгел дә.
Янып бетеп, күмергә
әверелгән күңеленә
телимме тын өрергә?

Син минеке дә, түгел дә.
Күңел тулып түгелгән
төпсез төнем тәрәзенә
пәрәвезләр үрелгән...

## «БЕРЕК»,– ДИДЕ КАЕНАНАМ

Пар бөркелде кыңгыраулы шук атлардан,
Мамык мендәр – басып кердем бусагадан,
Тел очымда бер кашык бал тәме һаман,–
Саклый күрсен зат күрмәгән усаллардан.–

Кыз баланың иле-көне читтә, балам,
Никахны да йола гына итте заман,
Затыбызның дәвамына биргән Ходам,
Хуш киләсең, берек! – диде каенанам.

Чишмә суын күрсәткәндә, күбәләкләр
Бер алдыма, бер яныма төшеп очты.
Тәңкә салдым, учлап җыеп ак таш салдым,
Чишмә судай ургып торды куанычым.

## КОШЛАР КИТКӘНДӘ

Китәр кошлар,
Вакытлары җиткәч,
Парлашалар, диләр, дөрестер.
Аларга да
Озын-озак юлны
Пар-пар булып узу тиештер.
Китәр кошлар
Китәр еракларга.
Алар калдырган буш ояга
Вакытлыча гына,
Язга хәтле,
Калган кошлар кереп оялар...
Ә бер «кошчык» –
Минем тәрәзәмнең
Каршысында үскән матур кыз.
...Ул да китә,
Ул китәчәк инде,
Калдырачак мине ул ялгыз.

## ЫШАНЫРСЫҢ МИКӘН

Качып кына
Турыгызга
Ничә тапкыр килгәнемне,
Тәрәзәңнән
Гөлләреңә
Сулар сибеп йөргәнеңне
Күзәтсәм дә,
Сизмәвеңне
Әйтсәм, ышанырсың микән?

Сабантуйда
Йолдыз кашка
Ал бирмичә узып килгәч,

Аңа сөлге бәйләвеңне,
Маңгаеннан үпкәнеңне күргәч,
Шул кашкадан
Ничек көнләшүемне
Әйтсәм, ышанырсың микән?

Унсигездә
Хис ташкыны
Шигырь булып үрелгәндә,
Җырларымнан тәкыя үреп,
Күңелеңә кидергәндә,
Күрше авыл
Егетенә
Вәгъдәң барлыгын белгәндә,
Яшәүдән
Ваз кичүемне
Әйтсәм, ышанырсың микән?

Күктән йолдыз
Атылганда
Күк капусы ачыла, дип
Өметләнеп
Йөргәнемне,
Насыйп итә күр аны, дип,
Хәзергәчә теләвемне
Әйтсәм әгәр,
Көләрсеңме:
– Юләр син,– дип...
Әллә ышанырсың микән?

# АГЫЙДЕЛ СЫЛУЫНА

(*Җыр*)

Агыйделдә талларның
Балга төренгән чагы.
Актанышта бер сылуның
Буйга үрелгән чагы.

К у ш ы м т а:

Елмаеп, һай, сылукай,
Йөрәгемә ут салдың.
Януларын басармы
Агыйделнең сулары?

Агыйделдә аккошларның
Канат кагынган чагы.
Актанышта бер сылуны
Өзелеп сагынган чагым.

К у ш ы м т а.

Агыйделдә таң алдыннан
Алтын чык төшкән чагы.
Актанышта бер сылуның
Алмадай пешкән чагы.

К у ш ы м т а.

## ЯЗГЫ МИЗГЕЛЛӘР

Тәүге адымын атлый яз,
Урман-кырлар карда әле,
Гөрләвекләр алда әле.

Агыйделдә актарылып,
Ташып-ташып акты бозлар,
Учак агыздылар кызлар.

Сихерлеме язгы җилләр?
Шигырь язды бер сылукай
Гөрләвекле айлы кичтә.

Иң әүвәл бөреләнде тал,
Мамыкка төргән сыман,
Бизәнгән кызлар сыман.

Каен суы эчкәндә,
Мәхәббәт җыры сузды
Сипкелле бер сандугач.

Умырзая өзгәндә
Муеннан гашыйк сылу
Серен чиште дустына.

Күңелләрнең серле чагы:
Кабатланмас назлар бу,
Кабатланмас язлар бу.

# БЕЗДӘН БИРНӘ – ТУРАЙГЫР

(*Чәчәннәргә ияреп*)

Ерак Казакъ даласын
күрермен дип белдеңме?
Ике баз тоз* каласы
Яр бирер дип килдеңме?

Иртыш яры тал гына,
таллары гел бал гына.
Бирәм диеп торганда,
икеләнмә, ал гына.

И гүзәл Яр – Назлыгөл,
күңелеңдә язмы гел?
Ямансуга бирешмә,
елмай, сиңа килешә.

Иңләп казакъ даласын,
чабып үтте бер колын.
– Фатихаң бир, Анасы,
кушылсыннар уң кылып.

Иртыш суы шәп ага,
талда эзләре кала.
Сеңлең җитте артыңнан,
сандыгыңны ач, бала.

Бүләкләреңне барла,
урыныңдамы бар да?
Мендәрләр, чаршаулыклар,
сөлгеләр, ашъяулыклар...

Бианаңа – күлмәклек,
кәләпүш – биатаңа,
каенсеңелга – яулык,–
һәрчак шуларга таян.

---

* *Ике баз тоз* – Экибастуз шәһәре.

Күршеләрне калдырма
бүләксез һичберсен дә.
Тәүге көннән күрсеннәр,
юмарт, уңган, дисеннәр.

Биананңнан иртә тор,
җырлатып куй самавыр,
сөеп сау сыерларын,
макта чишмә суларын.

Еракны якын итеп
килгәнсең икән, егет,
бишбармактан, кымыздан
рәхәтләнеп авыз ит.

Иртыш буе тугайлык,
дөнья малы – бер айлык.
Бердәнбер киявемә
бездән бирнә – Турайгыр!

Базарларда сатмадык,
кияүгә дип сакладык.
Кызымны бик мактарлык,–
йөземне кызартмады.

Тулган Айга карадым,
һай, йөзең шунда күрдем.
Тулып пешкән баламны
сорап килерең белдем.

Далага тиң күңел киң,
балама тиң хуҗа бул!
Юлдаш булсын Турайгыр,
үзең бул чын Хуҗагол!

# ГОРУРЛЫК

Туйлар көттек, туйлар булмый калды,
Язмыш мине синнән тартып алды.
Шәрабына салып агу бирде:
– Минеке, йә һичкемнеке,– диде.

Исердемме, әллә тилердемме?
Ихтыярым бетеп чигендемме?
Тезем төшеп, үксеп ялварсам да,
Хыянәтең кичермимен,– дидең.

Туйлар көттек, туйлар булмый калды,
Гомер буе җаннар газапланды...
– Хыянәтең кичермимен,– дидең...
Син шул үзеңнән дә горур идең...

# СЕЗ

Ишетерсез,
каты төер
тын алырга
киртә булып
торыр бераз:
– Нигә шулай?
– Нигә шулай?..

Килерсез –
күрерсез:
– Элегрәк
килмәдем,
күрмәдем шул, –
диеп
үкенерсез...

Җилләр
елар
дулап,
тузып;
күзне
кисәр
тозы...

Сез
сүз-
сез:
– Кем
эше?
– Кем
эше?..
Сез
мин-
сез
ө-
шер-
сез...
С
е
з...

* * *

Арын арык уйларыңнан
йом да күзләрең.
Онытылып кал беразга,
мендәр тезләрем.

Арын тутыккан хисләрдән,
искенең исе
исертмәсен, йөз суыңны
бирмә Иблискә...

Тик бер төндә онытылчы
дөнья гаменнән,
исертәсем килә сине
хис шәрабымнан.

Сулышымның бәлзәменә
саласым килә.
Йөрәгеңә ут кабызып,
үзем дә шунда уралып,
янасым килә!..

## СИҢА КАЙТЫР ЮЛЫМ

Сиңа кайтыр юлым ерак –
тауларны бар кичәсе...
Бүген айның ничәсе?

Сиңа кайтыр юлым озак –
үткелләрне үтәсе,
үткәннәрне сүтәсе.

Сиңа кайтыр юлым урау –
карурманнар урасы:
кыры, кылган, курасы.

Сиңа кайтыр юлым диңгез –
яр белә яр арасын
дулкыннардай ярасым...

Сиңа кайтыр юлым – күктә,
хыялым уйларымда –
Киек Каз Юлларында.

# ЯТ ТҮГЕЛ ӘРНҮЛӘРЕМ

(*«Төнге уйлар» циклыннан*)

Төн...
ялгызым
эфирдан эзлим ни дә булса...
Шунда
адашкан дулкыннарда
җыр тотам...

Теле дә ят, көе дә ят,
Тыңлап ятам – ни чара:
Өзгәләнеп бер кыз җырлый,
Әллә елый, бичара.

Кемнең газиз баласы син,
Нидән шулай әрнисең.
Кемгә шулай рәнҗисең дә,
Кемне шулай әрлисең?..

Телең дә ят, көең дә ят,
Ят түгел әрнүләрең.
Җәберсетә тик хыянәт,
Телгәләп бәгырьләрне...

Оят түгел, оят түгел,
Ят түгел әрнүләрем...

#ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ КӨЕ

Һәркемнең дә була тик үз көе,
үземнеке генә дигәне.
Көе китеп тора дигәндә дә,
күңеленнән көйләп йөргәне.

К у ш ы м т а:

Күңелкәем тулы моң гына,
тыңла әле, тыңла тын гына.

Һәркемнең дә була тик үз көе,
Әнкә сөте белән кучкәне.
Бишегеннән кояшка үрелеп,
үрмә гөлләредәй үскәне.

К у ш ы м т а.

Һәркемнең дә була тик үз көе,
чишмә, инешеннән күчкәне.
Гомер дулкыннарында тибрәлеп,
дәрья-диңгезләрне кичкәне.

К у ш ы м т а.

# АГЫЙДЕЛДӘ АЛ ТАҢ АТА

Агыйделдә ал таң ата,
Балкып яңа көн туа.
Агыйдел, Җир, бөтен җиһан
Алтын нурга коена.

К у ш ы м т а:

Актанышым – Син таң илем,
Агыйдел – тал бишегем.
Синдә туды бәхет гөлем,
Илһамланып яшимен.

Агыйделдә ал таң ата,
Тургайларны уята.
Мәңгелектән килгән бу өн
Курайларны уйната.

К у ш ы м т а.

Ташларны да елмайта ул,
Чишмәләрне биетә.
Кырларында тук башаклар,
Гөл сузыла биеккә.

К у ш ы м т а.

Агыйделдә ал таң ата –
Моң сузыла нурында.
Илаһи нур – мәңгелек җыр
Сөю, яшәү турында.

К у ш ы м т а.

# ГОМЕР ЙӨЗЕП ЧЫГЫЛГАН

(*Җыр*)

Без туфрактан яралганбыз –
үләннәр, гөлләр кебек.
Гомерләр үрмә гөл кебек,
димәк, яшәү – мәңгелек!

К у ш ы м т а:

Тәннең җиргә кайтасы бар,
Җанның күккә китәсе.
Җир белән күк арасында
гомеркәйләр итәсе.

Без тамчыдан яралганбыз –
таңның алтын чыгыннан.
Тамчыдан күл, дәрья, диңгез –
гомер йөзеп чыгылган.

К у ш ы м т а.

Без кояштан яралганбыз,
Илаһының нурыннан.
Нур очында мәңгелек сер:
без мәңгелек юлында...

К у ш ы м т а.

# КӨНЛӘМӘ

(*Шаян җыр*)

– Бердәнберем генә бул,– дип
тәкрарлыйсың кич-иртән.
Елмаеп үткән һәркемнән
нигә көнлисең, иркәм?

К у ш ы м т а:

Көнләмә, зинһар, көнләмә,
кагылып үткән җилдән.
Көнләшер сәбәп эзләмә,
миңа син дә бик җиткән.

Көнлисең күрше-күләннән,
күз күреп белмәгәннән.
Бердәнбер сәбәп юкта да
ник җанны телгәләргә?

К у ш ы м т а.

Көнләү – ярату билгесе,
уйламый әйткән берсе.
Көнчене көйләп көн үтә,
Тәңрем, ярдәмең бирче?!

К у ш ы м т а.

# ЯРЫМАЙ ТИРӘК ОЧЫНДА...

...Ай да ялгыз
Мин дә ялгыз...

Төн уртасы... Тәрәзәсен
кемдер куйды кагып...
Җилме, җенме – кемнәр белсен,
яткан иде арып...

Юкса күтәреп пәрдәсен
аласы тик багып...
Ояты ни: күзләренә
күзләр торса багып...

Ярымай тирәк очында...
Кунаклаган оеп...
Әллә соң уйга чумганмы,
толның хәлен тоеп?..

Пәрдәсен күтәреп юкса
тик багып аласы...
Җил икәненә инанса...
Аллаһым сакласын?!

Гөнаһына кермә җилнең,
ул да бер ялгызы...
Тәлгәш-тәлгәш тамчыларын
пәрдәгә тамызды...

Төне көннән пәрдәләнгән,
акылы – хисеннән...
Ай булып айның да әнә
яртысы киселгән...

# БАГЫШЛАУЛАР



# ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ЙӨЗ ЕЛЛЫГЫНА

Туфанга – йөз:
уналтысы
зинданда үткән.
Кемгә нәрсә – милләтенә
барыбер күптән.

Туфанга – йөз, берүзенә
тулы бер гасыр.
Титаннар юк, милләт йөген
кем иңгә асыр?

Җырың ни дә, шигырең ни –
китсен кадалып.
Казанында – ахырзаман
кайный базары.

Кемдер сата, кем сатыла –
барсы алдана...
Төсе, исе укшытырлык –
сыткан кандала...

# ДУЛКЫННАР ЙӨГЕРӘ КАРШЫМА

*Триолен. Лена Шагыйрьҗанга*

Күзем алмыйм үзем һаман
Кыргый дулкын туйларыннан

*Л.Шагыйрьҗан.*

Дулкыннар йөгерә каршыма,
Күр, ничек алар ярсыган.
Ак күбеккә баткан ат сыман
Дулкыннар йөгерә каршыма.
Үзләренә мине чакыра:
– Әйдә, иреккә, Шагыйрьҗан?!
Дулкыннар йөгерә каршыма
Күр, ничек алар ярсыган...

## УЛ КИТТЕ, КИТЕП БАРЫШЫ...

*Татар халкының бөек җырчысы*
*Хәйдәр Бигичевның вафатына*

Ул китте,
кемнәр калды соң
милләт йөген күтәреп?
Болай да вак затлар идек,
инде тәмам бетәсен
күпме калды көтәсе?..

Ул китте – китеп барышы...
милләттә кем каргышы?
Болытларны дерелдәтә
матәмнең бу тавышы...

Болай да вак затлар идек,
Ходай барыбер яклар, дидек...
Шайтан туй иткән дөньяны
кара болыт каплар инде...
Безне тары ярмасыдай,
килесендә төеп-төеп
ваклар инде...

Ул китте – китеп барышы.
Милләттә кем каргышы?..

# ТЕТКӘЛӘНГӘН ЙӨРӘК БЕЛӘН...

*Рабит Батуллага 60 яшь тулу уңаеннан*

Бу ел икегезнеке:
аңа йөз егерме,
синә — яртысы.
. . . . . . . . . . . . . .
Бүтән беркайчан да
шулай булалмас...

Син бирелә — шөкер.
Аңа күпме гомер
илгә кайтасы,
Ничекләр шул көнне
якынайтасы...

Бу ел икегезнеке...
Бусагада — яңа гасыр!..
Кешелек сусаганда
намус, ният, пакьлегенә,
яңа гасырга
үтәрме ил — ансыз?..

Син — бирелә, димәк:
кайтып җитә алмаса
Исхакый,
кискәләнгән, теткәләнгән
йөрәк белән,
милләт йөген салып иңгә,
синә һәм тагын
кемнәргә алып чыгасы?!

# АК ӘБИ

*Шагыйрә Тәгъзимә Мөхәммәтдинованың иҗат кичәсенә*

Сүзләмәкдә йөзләремни ак кыл,
Сүзләремни ил күңилгә йомшак кыл.

*Мөхәммәдьяр*

Иске авыздан яңа сүз көтәләр,
Әйтсәң мәгәр, тетмәңне үк тетәләр.
Телең тешләп, әйтми калсаң әйтерең,
Сәбәп итеп үзең читкә этәләр.

Сүз заманы килде, итә тантана,
Сүз куарлар, сүз җыярлар ат ала.
Әләк, ялган, яла сүзе астында
Асылы ак, пакь булганнар таптала.

Астыртыннар астан якты учагын,
Нәселемнән, тамырымнан үч алып:
– Әйт, күрдеңме кайчан булса, Ак әби,
Күңелемнең рәнҗегән бу чагын?

Ташка таш бәрүдән бары ут чыга,
Тартылган җәядән ярсып ук чыга.
Юатасың, сизеп торам, Ак әби:
– Мирза улым, яна-яна син чыда.

Без күргәнне җирдә кем дә күрмәгән:
Бер чагу сүз илтеп кертте төрмәгә.
Авыз пешкәч, хаҗәте юк – өрмә дә,
Дөньясы кырын килде шул безгә дә.

Юатасың, сизеп торам, Ак әби,
Кулың җылы, күңелең ак, Ак әби.
Канга батып кыйналган җир үзе дә
Шагыйрәгә биләүдәге бер бәби.

Юат әйдә, тирбәт әле иркәләп,
Әнкәйләр шул китте бездән иртәрәк.
Вакланган һәм бүлгәләнгән дөнья бу,
Беркем белми ни күрәсен иртәгә...

## КАРУРМАНГА КЕРГӘН ИДЕК

*Остазым Рөстәм Мингалимгә*

Карурманнарга кердек без,
карамалык кисмәккә.
Карурманда кара шом бар –
кубарып җил исмәккә.

Карамасын, кара талын
каердык, дуга бөктек...
Илдән, өйдән кара көннең
китүен зарыгып көттек.

Карурманнардан чыктык без,
карамалык кискәч тә.
Таралмады кара болыт,
кубарып җил искәч тә...

Карамасын, кара талын
каердык, дуга бөктек...
Илгә, өйгә, күңелләргә
хөрлек килүен көттек!..

Карурманга керим дисәң –
карурман да калмаган...
Каерылган, бөгелгән Ил,
җиле кага аркадан...

Карамасын, кара талын
килә тагын бөгәсе.
Илгә, өйгә, күңелләргә
иңәрме Иман Догасы?

...Дуга бөктек, атлар җиктек,
Кемнәрдә дилбегәсе?!

## ҖЫРЛА, САЛАВАТ!

Кайгы екса да,
ачлык кырса да,
ятим-ялангач
туңса да багыр,
ачы язмышы,
карурман кичеп,
изге чишмәдәй,
саф һәм пакь калып,
үзенең җырын,
үзенең моңын
саклаган Халкым!

Әйдүк, уз, Егет,
диңгездәй тирән
кайгыны тарат;
«көйсезләр» дигән
һәр йөзе кара
күрсен кемлекне,–
телсез түгел без,
көйсез түгел без,
сагышны тарат,
кайгыны тарат –
Җырла, Салават!

«Агыйделнең сулары ла,
ягымлы сылулары...»
Җырның ертыгы
юк, дисәләр дә,
ертылып беткән
җырлар җырлама!..
Меңьеллык сынау
үткән җырлар бар;
мәңгелек сорау:
– Кемнәр чыгарган?
– Кемнәр җырлаган?

Таш-тимер сыннар
вакыт сынавын
күтәрми һәрчак,
ә җырлар үзгә,
алар – калачак!
Җилләр дә алмый,
утта да янмый;
вакыт һәм киңлек
чиксезлегендә
сөю кебек үк
мәңгелек – Җыр да!

Җан җылысына
тиң моңы булса,
серле сөюдәй
канатлы булса,
сабыйлардай саф,
самими булса,
алыпларга хас
тиң көче булса,
шагыйрьләргә хас
чын хисле булса,
Мәңгелек – Җыр да!

Ачы язмышы –
карурман кичеп,
саф һәм пакь калып,
үз җырын, моңын
саклаган халкым
шатлана бүген
синдәй ул барга,
диңгездәй тирән
сагышны тарат,–
мәрхәбә, әйдүк:
– Җырла, Салават,
– Җырла, Салават!

# ҖЫРЫҢ ИҢГӘН ШУШЫ ТӨНДӘ...

*Җырчы Зәйнәп Фәрхетдиновага*

...Дөньяның бер гаме-яме күзгә
күренмәслек булган көнендә,
шәрабы да, шәрә гөл дә шунда –
һич исертә алмас төнендә;
онытылып, кайларда булса бер
каласым бик килгән хәлемдә,
фанилыктан мәңгегә ваз кичеп,
югаласым килгән мәлендә,
ташкын булып җырың иңде шулчак –
җанкаема балдай агылды,
дөрләп китте сүнәр-сүнмәс учак –
йөрәгемне учыңа алдыңмы?..

Таң – шәмәхә,
чык – чын алсу икән,
күк – зәп-зәңгәр, чынлап карасаң,
баскан эз дә гаҗәп чыңлы икән,
Җир – тере җыр, тыңлап багалсаң!

Дөньяның мең төсе чакырып дәшә,
төсләр булып җирдә җыр яна.
Җырың иңгән шушы серле төндә
мин яңадан тудым дөньяга.

# УЛ ГАҖӘЕП БҮГЕН

*Композитор Вәсим Әхмәтшинның иҗат кичәсенә*

Ул гаҗәеп бүген Маэстро!
Чәчәкләргә шулай күмелеп,
үз биеклегендә басып тора,
нурын тоеп иҗат күгенең.

Ул гаҗәеп һәрчак Маэстро!
Җанын салып һәрбер авазга,
нур очында оча яңа чорга,–
туар чор сусаган җыр, назга!

Ул гаҗәеп бүген Маэстро!
Чәчәкләргә шулай күмелеп,
үз бөеклегеннән качып тора,
ак күбеккә батып, үр менеп!..

# САРДЫ САРЫ САГЫШ

*Дәфкил дустым истәлегенә*

Күз тидеме ялгыш,
Каһәрлеме язмыш?
Өметләнеп көтәм –
Кәккүк бирми тавыш.

Өмет мәңге үлми.
Аһ, минутлар озын!
Балкыды да сүнде,
Атылып, бер йолдыз.

Мәрхәмәтсез язмыш –
Хет саламга ябыш...
Сарды сары сагыш,
Күлдә ялгыз аккош...

# ГЕЛ ЕЛМАЕП ТОРМАСА ДА ДӨНЬЯ...

*Энем Рәшиткә*

Гел елмаеп тормаса да дөнья,
Өшетсә дә көзге салкыннары,
Изүләрне ачып сулыйк әле,
Яшик әле бераз, и туганым.

Гел эш белән үтсә дә бу гомер,
Тәкъдирләргә бирешмик тиз генә,
Авыруны, кайгыларны җиңеп,
Кайтыйк әле Әткәй нигезенә.

Яланаяк чирәменә басып,
Чыкларыннан чабып үтик әле,
Качып киткән малай чакны табып,
Колагына җырлар әйтик әле:

«Малай чагың – тайдай чагың,
Ата чагың – аттай чагың,
Бабай чагың-малай чагың
Әйләнеп кайткан чагы.

Онықларың уңында ла,
Онықларың сулыңда шул,
Онықларыңның уллары
Булыр әле кулыңда...»

Гел елмаеп тормаса да дөнья,
Сынаса да салкыннары ялмап,
Малай чакка, әйдә, барыйк әле,
Чык өстеннән бергә яланаяк!..

# УЛЫМ ГАДЕЛГӘ

Йолдыз атылганны икәү
күзәтеп яткан бу төнне
гомерең буе онытмассың,
беләм;
үз җаныңның Бөек Күккә
бәйсез бәйләнгәнен тәү кат
зиһенеңә салып куйдың –
сиздем;
әгәр
шул бәйләм чишелсә,
бәйсез бәй өзелсә,
бүтән беркайчан да
йолдызларны
күрә алмассың,
Улым.

## ҖИДЕ

*Улым Гаделгә*

Буленми һәм булгәләнми,
Бөтен дә соң Җиде.
Чиксез галәм үлчәвендә
Серле дә соң Җиде...
Бөеклектә һәм зурлыкта
Тиңе юк сан – Җиде.
Юкка гына күкнең чиге
Түгел инде Җиде.
Гомер ит син Җиде кебек,
Җиденең серен бел.
Җиде буын горурлансын,
Яшәгән, дип, Гадел!

## КЫЗЫМА

Гөл күрке – чәчкәдә, бел генә,
Өзәләр аны тик көз генә.
Ландышка, лаләгә хас чагың,
Нәркиздәй ягымлы саф чагың,
Алмалы көзләргә җитсен лә,
Зәр алтыным минем, Гөлназым!

# МИН ҖЫРЛЫЙМ

*Табиб Иркен Галиевкә*

Больница...
Күрше палатада
каты авыру ята.
Бронхлар... Тыны буыла...
Көннәре, төннәре буталып
тоташтан,
ята ул ютәлләп, саташа.

«Хәле авыр,– диделәр, –
Бичара тарталмас озакка».
Авыру авыруны аңлый да,
тик ярдәм итәлми
чыгарга бу тозактан.

Ничә төн үткәндер,
бер таңда
ютәлләү калды тынып.
Бик озак тоелды
бу тынлык,
шомлы бу тынлык...
Тып-тын палата,
больница,
бар дөнья.
Мин сак кына
акылым белән үземне барлыйм,
өнемдә, мин исән –
күзләрем ачыла, ябыла.
Тоямын күкрәгем тибешен,
ишетәм сулышым
һәм тагын...
Мин нәрсә ишетәм ерактан –
акылым җыр тота:
«Яннарыңа барыр идем,
ял итә, итә-итә...»

Ишетәм,
акылым ап-ачык бу таңда,
уяумын, саташмыйм –
җырлый!
Шул абзый!
Таш диварлар аша җыры
йөрәгемә үтте,
яшәү уты төртте.
Мин кабындым,
авыру миннән кача, кача,
чыдый алмый яшәү утыма:
менә, менә ул чыгып китте.

Арабызда таш дивар булса да,
бу таңда
яшәү көче
җыр аша
миңа күчте,
савыктым!

Ул да савыккан лабаса!

Хәзер мин дә җырлыйм,
минем җырым –
яшәү турында,
сафлык турында,
саулык турында,
бәхет турында.
...Бу җырымның азагы юк
һәм
булмасын да!

# СЕЗ ҺӘМ АЛАР

Ишетмисез дә күрмисез
Күзсезләрнең
Ялварулы карашларын,
Чулакларның кул изәвен,
Чукракларның авазларын.
Басып кала аяксызлар,
Сез чабасыз лимузинда.
Эспандер тартасыз көн дә,
Ә кувалда – көчсезләрдә.
Алар гел сөяк кимерә,
Сез җилеген чөмергәндә.
Алар исә
Һәммәсен дә
Ишетеп һәм күреп тора.
Әлегә
...түзеп тора!

## КУРКАКЛАРДАН КУРКАМ

Күргәнем бар
үтә куркак
кешеләрне –
бикләнәләр,
караңгылык
төшүгә үк.
Күргәнем бар
калтыранып
төшүләрне,
хатыныннан
кача-поса
эчүләрне...
Күргәнем бар:
үтә куркак
бер бәндәләр
тәм табалар
көчсезләрне
бәргәләүдән.
Юлыктым мин
әллә нинди
куркакларга.
Тик ышанмыйм
синнән дә нык
куркак барга.
Әләк-чәләк
белән күпме
дөнья көттең.
Бик тырышкач,
эш башына
менеп җиттең.
Куркаклыгың
һич бетмәде,
артты гына –
син әйләндең

куркакларның
актыгына:
кеше саттың,
илне саттың
курка-курка.
Бу дөньяның
куркагыннан
мин дә куркам.
«Куркак мин», – дип,
базда гына
ятмый алар.
«Урра!» – диеп,
гел уртадан
атлый алар.
Гел җылыда,
урталыкта
куркак җаны:
шуңа күрә
аны бик тиз
булмый танып.

* * *

Тантана артыннан тантана,
белгәннәр, аптырап, таң кала:
– Юкса бит урында таптана,
күзен дә йоммый гел мактана,
дөреслек изелә, таптала...
Эчтә шом, ә тышта – тантана.

– Заманасы шундый,– диярләр,
тәвәккәлләр аны иярләр.–
Әдәп, әхлак, иман-сафсата,
намазлыкта ярый,– диярләр...
Дөньясынмы
тегеп киярләр?
Туя белмәс кыргый этләрнең
нәфесләрен кемнәр йөгәнләр?
Кемнәр?

# НИГӘ БЕР УЙНАМАСКА?

Я всей душой к жене привязан;
Я в люди вышел... Да чего!
Я дружбой графа ей обязан!
Легко ли? Графа самого!

*П.Ж.Беранже*

Хатын түрә булып алды:
юк бәхетем биш итте.
Кем идем мин, кем итте –
түрәләргә иш итте!

Үтә җилләр искәндә гел
итәгенә яшерде.
Авыр сүзләр әйт, дисәләр,
үзе атты яшенне.

Ни теләсәм шуны ашыйм,
машинада җилдерәм.
Эш башына утырттылар:
урам, сугам, җилгәрәм...

Үземнән бик курыкмыйлар,
хатыннан шул шүрлиләр.
Хатын түрә, ә түрәсе
ул дигәнне хуп күрә...

Хатын сүзеннән гел чыкмый
түрәләрнең түрәсе.
Өрмәгән җиргә утыртмый
хатын лаек, күрәсең.

Хатын белән мине хәтта
мәҗлесләргә чакыра.
Заграничный шешәләрдән
үзе коя чокырга.

Элек бер сәрхуш идем мин,
инде беләм чамасын:
башта үбеп утырасың,
соңрак тутырып саласың.

Түрәләрнең түрәседәй
киенәмен ыспайдан.
Элек суган сатып кидем
гел очсызлысын сайлап.

Көнләшүләр, көнләүчеләр
инде буа буарлык...
Елга ике-өч мәртәбә
курортына без бардык.

Хатын таба, хатын чаба,
көне-төне юлда ул.
Түрәсеннән калыш калмый –
юлда кирәк була ул, –
диеп, үзе янына гел
ала микән тегесе?..
Озын юлда ниләр булмас –
әйдә, исән йөресен.

Исән булсын хатын-түрә,
һәм дә аның түрәсе...
Алар исән, мин исәргә
җирдә оҗмах күрәсе.

Ихатаны, йорт-кураны
яңасын җиткерәсе.
Иномарка-«лимузин»да
юлларда җилдерәсе...

Улны, кызны, туганнарны
бар башка чыгарасы.

Хатын-түрә – алдан күрә,
юк башка бер чарасы...

«Дөнья матур, дөнья киң лә»,
яши белгән кемнәргә.
Хатыным белән түрәсе
юлга киткән көннәрдә,
мин үзем дә «уҗым исен»
иснәргә бик һәвәсмен.
Хатын юкта – мин походта:
урманын, әрәмәсен
биләп кайтам, юлдаш итеп
алам түрә бичәсен,
Ул да дөнья бичарасы,
берьялгызы нишләсен?..

Мең рәхмәт укыйм хатынга
түрәсенә иш итте.
Суган сатып йөри идем,
юк бәхетем биш итте.

Уеннан тора дөньясы,
нигә бер уйнамаска.
Түрәләр ашаган майны
мыекка буямаска?..

# ГАЗӘЛЛӘР



* * *

Кышның китәсе килмиме һич кенә,
өеп-өеп яуды кары кич белән.

Салкын тынын өрде бөтен җиһанга,
салып тунын, күлмәген кигәч кенә.

Ак мамыкка төрде каен, талларны,
бөреләре ачылам дигәч кенә.

Тәрәзәмә элде томан пәрдәсен,
Тулган айга карыйм бер, дигәч кенә.

Керфегеннән тамды тозлы бер тамчы,
иреннәре иренемә тигәч кенә...

Тыныч бул, өзгәләнмә, и Мирза,
бу кар – сыерчык бураны ич кенә!..

* * *

Уйчан йөзем борчулы күренмәсен,
әйтеп булмый һәрчакта күңелдәсен.

Асылташтан кыйммәтрәк, кадерлерәк
бергә булган шушы төн өермәсе.

Мәртәбәле шөһрәт, дәрәҗәдән Сиңа–
тәхетемә тик ятлар үрелмәсен.

Язны көтеп тилмергән бәхет бөрем
еремәслек бозларга төренмәсен.

Синең хакта актан-ак уйларымның
йөзенә былчырак сүз түгелмәсен...

Талчыктырмасын уйларың, и Мирза,
син бәхетеңнең җиде күгендәсең!..

* * *

Һәр ташуда ун адым читенде яр,
ни хәл итим, түгел минем ихтыяр.

Узган елда агып китте ун тирәк,
бу ташуда ничәсе җанын кыяр?..

Катлам-катлам бозлар килеп орынды:
ярылды боз – тотты тамыр – торды яр.

Йөзенче кат оруында, йа Ходам,
ун тирәкне кочаклап убылды яр.

Агыйделдән агып китте ун тирәк:
сулкылдап калды өзек тамырлы яр...

Ташкын судай гомерләр дә, и Мирза,
узып бара, егълап калыр кайсы яр?

* * *

Тулган айда күрдем йөзең төсләрен,
уяндылар мәрткә киткән хисләрем.

Ничек ялгыз дип әйталам үземне,
кабат кайтты, гел минеке кичләрең.

Бергә чакның күпме сере аларда –
серләремне һичкемгә дә чишмәдем.

Хәтер – диңгез, бәхтем булган шуңа тиң,
син – корабы, ап-ак иде җилкәнең!..

Татлыдан да татлырак ни җиһанда–
учларыңнан чишмә суы эчкәнем!..

Ак корабың йөзеп бара, и Мирза,
тулган айга бакчы – ап-ак җилкәне!..

* * *

Дөнья гел алыш-бирештә, аңла син,
бирсәләр – ал, алсаң – бирми калма син.

Алганчы тик, лязем бирү үзеңә,
бирәм дигәч, кире тартып алма син.

Гел алырга күнеккән куллар булыр,
эзләренә эзләрең һич ятмасын.

Хәрам җыйган, таптым дигәч, талигын,
калыр тотып җимерелгән арбасын.

Үлчәвеңдә калдырма һич шик-шөбһә:
кирәксә – бүл дүрткә тары ярмасын!..

Дөнья кала, малы кала, и Мирза,
Җаныңа нур җыярга соңарма Син!..

* * *

Кызлы йортның капкасында ат торыр,
тояк чыңы пәрдә читен тарттырыр.

Әдәп-сафлык бөркеп торган күңеле,
«Бисмилла»лы тәне һәрчак пакь торыр.

Сафлыгына тиң тәңгәл сылулыгы
сан җитмәслек кыйммәтләргә хак торыр.

Хак Тәгалә нурландырган җанына
Фәрештәләр һәрчак уяу сак торыр.

Гаден* йортның бакчасында хур кызы,
җирдә тиңен күреп чиксез шат торыр!

Рухы, җисме самим-садә Кыз бала
ике дөньяны бергә тоташтырыр!

---

* *Гаден* – оҗмах.

* * *

Күзгә-күз багып бирәмсең сәламең,
– Туганым,– дип, өзеләме камәлең?

Нәсел-ыру, ил-йорт йөге иңеңдә,
Нык будыңмы билеңдәге камәрең?

Дога, бәддогамы вәгазь-таләбең,
Вәгъдәңә тәңгәл ятышмы гамәлең?

Яктыртмакчы күңлең күген күпләрнең,
Кояш, Ай, йолдызлымы үз галәмең?

Искәндә дулап, җаһиллек җилләре
Имангамы чакыра бу әләмең?

Уңмас, җуелмас Илаһың нурына,
И Мирза, манып язамсың каләмең?

* * *

Көн уртасы, туктап калды сәгатем,
Юк иде лә кинәт туктау гадәте.

Соңга калдым килер-барыр юлымда
Шул сәгатем туктап калу сәбәпле.

Сәгатькә ни, аның һичкем каршында
Юк бирәсе, йә аласы әҗәте.

Без генә ул, баш күтәрми көн-төнен
Гомер буе үтибез кем хаҗәтен?

Вакытны кертермен димә тәртәгә,
Җитсә дә күпкә акылың, сәләтең.

Кабат йөреп китте дивар сәгатем.
...Туктап калыр беркөн гомер сәгатем.

* * *

Әйтче, кардәш, һаман түзеп торыйкмы,
Суын сыккан каен кебек корыйкмы?

Җаһил җилләр җелекләрне өткәндә
Бөкерәеп арка куеп торыйкмы?

Күзгә карап килереңне кискәндә
Карачкы күк, күрми-дәшми торыйкмы?

Әллә акылга килеп бер төштән соң:
– Тор, күтәрел, милләт! – дип лаф орыйкмы?

Аяк-куллар, аң-зиһенгә салынган
Мең дә бер богауны өзеп орыйкмы?

Бусагада яңа гасыр, и кардәш,
Асылына тәңгәл тормыш корыйкмы?

* * *

Тыңла, ничек сыктый көз кышны тоеп,
Дерелди күз яшьләрен көчкә тыеп.

Сарыга сарылып утларда яна,
Яшел яшьлеген ул тәгаен кыеп.

Талгый җилләр даланың бар курасын,
Мең авазлы көй чыгарганчы җыеп.

Сүрән кояшның йончыган нурлары
Таралып бетеп, йоклыйлар оеп.

Күк кинәт ябынды кара пәрдәсен:
Яварсы җепшек кар, йә яңгыр коеп?!

Гомерләрнең бер мәле бу, и Мирза,
Тамгалап куй хәтереңә нык уеп.

* * *

> Малай булсаң, малай бул, тик куркак булма,
> ике төрле фәлсәфәгә уртак булма.
>
> *Р.Мингалим*

Бәләкәй булсаң бул, тик син вак булма,
Мантымас малга куелыр хак булма.

Биеклектә, бөеклектә бел чамаң:
Үзең дә буй җитмәслеккә мотлак булма.

Һәр терек парлы яралмыш җиһанга,
Бердәнбер үзең аерым так булма.

Сыналмыш кеше, дан-дәрәҗә алып,
Җете кызыл тиз уңа — онытмак булма.

Ялтыраган бар да түгел лә алтын,
Ятлар бәхетенә кызыкмак булма.

Анык бул, Мирза, иңеңдә кем йөге?
Ахмак балтасы чабар ботак булма!

* * *

Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына:
– Шөкер,– димен, Хак биргәннең барына.

Хөрлегемә, саулыгыма мең разый,
Тулып агам гомер-дәрьям ярына.

Ил-йортым киң, ризыгым мул, рухым шат,
Юлым ачык – хилафсыз иманыма.

Ким итмәгән – ургып тора хисләрем,
Былбыл оя кора күңлем талына.

Күгем зәңгәр, таңым алсу, гөлләрем
Һәрчак шифа, илһам коя җаныма.

Җиде бабам күтеп алган бәхет бу:
Насыйп әйлә, Раббым, оныкларыма!

# КОШ ТЕЛЕ



## КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Иман ерагайган саен,
Якынайган җаһиллек...

* * *

Кояшта да таплар бар, ди,
Кемнәр калдырган икән?..

* * *

Мин бөтен барлыгым белән
Сиңа бирелгән...

* * *

Күкләргә багам нидән,
Китәр юлым карыйммы?..

* * *

Бөреләрнең бер-берсеннән
Көнләшеп ачылыр чагы...

* * *

Кем белми шул хакыйкатьне:
Туар көн – төн артында...

* * *

Арыдылар, талчыктылар еллар
Ил арбасын баткак юлдан тартып.

* * *

Кисекбашлар болай гына,
Эч пошканнан язылмаган...

* * *

Ташлап чыккан иске йорт шикелле,
Тәмам бушап калган күңелем...

* * *

...Очсыз гына бәягә
Айны сатып ята кем?

* * *

...Айны, Марсны бүләләр
Җиргә туймаслар...

* * *

Тормыш – гел алыштыр:
Син, яки язмышың
Аркага салыштыр...

* * *

Эш – татар милләтенә
мәңгелеккә бүләк ителгән
иксез-чиксез сазлы карурман.

* * *

Гөл-чәчәкләр арасыннан
Эзлим сиңа охшаганын...
– Охшаган,– дип ышанамын...

* * *

...Мин бар кыйммәтләрне
Шигырь бизмәненә
Салып үлчим хәзер...

* * *

...Иртәсе, иртәсе!..
Энҗегә төрелгән
Җир-күкләр иркәсе!..

* * *

Ычкынды гомер йомгагым,
белмим кая тәгәрәсен:
– Бармы юрар мәгънәсе?!

* * *

Пошаманда дөньясы:
елаган юк, көлгән юк –
нишләргә дә белгән юк?!

* * *

– Күк капусы ачылса,
теләр иден ни теләк?
– Милләткә бер ир кирәк!..

* * *

Күңелемнең ябагасын
кырып аласым килә.
Биләүдәге нарасыйдай
Саф-пакь каласым килә.

* * *

Көтмәгәндә күкләр күкри,
Көтмәгәндә җир тетри.
Көтеп-көтеп син килмәсәң,
Җаным күкри дә тетри.

* * *

*(Мәсәл)*

Кибән астында бер тычкан әйткән үртәлеп:
– Түрәләр күрми, бәяләми хезмәтемне.
Озын кыш буе иңсәмдә йөртәм күтәреп,
Адәм баласы күтәралмас шушы йөкне!..

* * *

Заман җилләре исә лә,
маңгайга эзләр кисә...
Җанкаеңны кем җылытыр
челләдә кырау тисә?..

* * *

Мөнбәрдә исәп-хисапчы:
– Без әйбәт,– ди,– гел алда!
Шулай күренәсең килсә,
Күз дә йомма, гел алда!..

* * *

Йөксез поезд кебек шакылдап тик,
үтеп китеп барды шигырьсез көн.
Кызарып каралды офык чите,
әллә болыт купты, әллә төтен?..

* * *

Йөрәгемә дәштем: « Түз! – дидем, –
газапларың бер көн чигенер.
Ак сөлгедәй ап-ак көн килер:
Илһам нуры белән чигелер».

* * *

– Еракларга китеп кара,– диләр,–
Үз хәлеңне анык белергә.
Китмичә дә беләм, хәйран калам:
– Ничек мөмкин шулай бөлергә?!

* * *

Күрмәгәнне күрәсең килә бик,
Оҗмахларга керәсең килә бик.
Гөлләр булып үрәсең килә бик,
Дуңгыз булып сөрәсең нигә, ник?..

* * *

Атылды йолдыз –
янды кем җаны?
Сөреме якты
ярты дөньяны...

* * *

– Ниләр күрербез тагын? – дип,
аптырамагыз.
Күрәчәкне күрсәткән бит
Нострадамус.

* * *

...Ташулар, ташулар...
Ярларга язылып
кала да сүзләре:
югала үзләре...

* * *

Йолдызлар
сабантуй
үткәрә
августта...

* * *

Кояшта да таплар бар, диләр,
бәндә ничек булсын тамгасыз.
Уң битемдәге бу нокта — миң —
күңелем күзенең алмасы.

* * *

Тарих тамырыннан
төртеп чыкты курпы.
Куркып калды дөнья:
— Тартар, татар, ургы...

## АХЫРЗАМАН

Ана сөте белән керә, диләр,
бала күңеленә иман нуры...
Соңгы чиккә илтеп терәделәр:
ата кызны белми, ана — улны...

* * *

«Бисмилла иррахман иррахим» –
фатихасын сорау Ходаның.
Оныттырыр өчен шул җөмләне
иблис һәрчак уяу торадыр...

* * *

Кышның да
үзенә күрә
сайрар кошы
бар...

* * *

Үз хәлемне үзем генә беләм,
Сорамагыз нигә, нилектән...
Шигырьсез үткәргән көннәремне
Җәһәннәмдәгедәй хис итәм...

* * *

Талгын җил йөземә ягылды,
пышылдап: «Боекмачы»,– диде.
Җил түгел, син икән, син икән
юатмакчы буласың мине...

* * *

Үтеп китте егерменче гасыр
Кешелекне канга батырып.
Үтмәс шомга салып, янап китте:
– Бер кайтырмын! – диеп, акырып.

* * *

*(...килмәс димә...)*

...Картайды – бетте егәре
йөреп гел тузып, азып...
Йоклап үткәрә гомерен
төшендә шигырь язып...

* * *

– Дусларың шәпләрме? – дисең.
Дуслар шундый төстәрәк:
Берсе суга тез астына,
Берсе үрелә өскәрәк...

* * *

Тышта кырлач – бүрәнәләр
шартлап ярыла...
Шунда да сабантуйларны
күңел сагына...

* * *

Сорыйм шигем калмасынга:
– Кайсы ялганың, чының?
Утырдың кем арбасына,
Җырлыйсың кемнең җырын?..

* * *

Шүрәле бармагы сыман
кысылды көн Күк белән Җир арасына:
Җирдә мәңге чарасызлык
Адәм-Һава баласына.

* * *

Фани дөнья сынар өчен дан, мал бирер,
Әмма чиксез бары вакыт үзе генә.
Югалту һәм табу чиратлашып килер;
Рәхәтенә, хәсрәтенә син түз генә,
Аллана, баллана алма тик көз генә.

* * *

Ялкыныңа ураласым килде,
Ташкыныңда килде агасым.
Уралыплар актым – бәхетемне таптым,
Инде
Күз алмаңда килә каласым!..

* * *

Мине хәзер никтер күкләр тарта,
Күктә әллә күңеллерәкме?

*Ф.Яруллин*

Фәрештәләр хозуры бит ул күк,
Ничек анда булсын күңелсез.
Изгеләрне чакырып тора Гарше,
Шунда
Менәлмәслек шәхес түгел Сез...

* * *

Шөгыльсез үтмәде көнем –
сугардым гөлләремне.
Шигырьсез үтмәде төнем –
җаныма елышып гөлләр
күкләргә үрләделәр!

* * *

Бер дә болай түгел идең,
Нишләтте сине урын?
Гел шунда булырмын, диеп,
Эх ялгышасың, зурым,
Ләгеткә[1] калыр турың[2].

* * *

Кем чигеп үргән читән бу,
Кем йөреп салган сукмак?
Яр ярылып аерылган –
Ишелми калган туктап.
Өзелмәгән бер тамырдан
Тал курпы килә сутлап...

* * *

Үргә аккан чишмә суын
күреп хәйран калганым бар,
үргә аккан инеш-суга
карап күзем талганы бар...
...Табигатьнең без белмәгән
Илаһи бер ялганы бар...

* * *

Куначаңа җеннәр оялаган,
Асып куйган купшы пәрдәсен.
Дәрәҗәңдә күпме күтәрелмә,
Рухың белән бары кәрлә син.
Инде килер көнең нинди дисәң,
Ярда яткан балык хәлдә син...

---

[1] *Ләгет* – көлкегә калган кәҗә хәле.
[2] *Турың* – тур атың, аргамагың.

* * *

*Бер түрәчеккә*

Эткә ыргыткан бер сөяк –
бүген тоткан тәхетең.
Тәхетләнең артын сөртү
булды бөтен бәхетең...
...Түмгәк булып та калмассың
ишелгәчтен ләхетең...

* * *

Нидер язмак булып утырам да...
Исемеңне язып куямын...
Ак бит тула синең исем белән,
Бүлмәм тула синең исең белән,
Үзеңне дә янда тоямын...
Син берүзең – шигъри дөньяммы?

* * *

Сынды җәй –
Сарылды
Сарылык...
Сулды гөл:
Сабырлык,
Сабырлык...

## БОЛЬНИЦАДА

Палата – буш;
Таракан мыж;
Күршеләр – чуж;
Барсы да – гыж;
Урамда – кыш;
Бүлмәдә – тыш...
Бу, әйт, кай төш?..

* * *

...Халыклар,
дәүләтләр
хакында
күзаллап,
гөманлап
яза ала
тик татар
әдибе...

* * *

Әткәң-әнкәң фатихасы
Имин итәр ил-көнеңне,
Рухлары нурга коенсын!..
Үткелләрне үткәндә дә,
Зилзиләләр искәндә дә
Куллары җылысын тоярсың...
Әткәң-әнкәң фатихасы –
Һәрчак шуларга сыен Син!..

## И БӘГЫРЬ

*Фәүзия Бәйрәмовга*

Ап-ак шәлең – ак йөзең
Күз алдымда тора гел.
– Халкым,– дисең,– и бәгырь,
Халкың йоклый шул әле...
Халкым йоклый шул әле...
Сабыр итик, и бәгырь,
Уяныр ул, уяныр!
И бәгырь!

* * *

Ак болыт кичте Иделне
Табанын да чылатмый.
Йомшак җил үтте йөгереп,
Бер дулкын да чыгартмый.
Торналар очып үттеләр,
Аккошлар, кыр казлары.
Хәтеренә чорный Идел
Төсләрен, авазларын...

* * *

Шым булды ил:
тынды шау-шу;
сискәндерә
ара-тирә
күләгәләр
пышылдавы;
...Тынгысызлар
пошынмавы
шомландырып
сискәндерә...
Алтмыш өч ел
узып киткән:
оныкларга
күчкән мәллә
шомы шавы?..

* * *

Бер ананың
ике улы
телен бүлеп,
денен бүлеп,
көнен бүлеп,
бара бөлеп,
бара үлеп.
Әйтә дөнья:
– Адәм хуры!..
Үзләре бит
бер ананың,
бер ананың
ике улы...

* * *

Кичерегез мине, зинһар өчен,
Язылмыйча калган җырларым,
Мин адашып читтә озак йөрдем,
Инде кайтып гафу сорадым:
– Кичерегез, зинһар, газәлләрем,
Хәнкәләрем, дүртьюллыкларым,
Китмәскә дип кайттым, гүзәлләрем?!
Тик сез генә чит-ят итмәгез,
Язылмыйча калган җырларым...

* * *

...Почмаклар:
текә маңгайлы,
кылыч борынлы,
пычактай үткен,
сөңгедәй очлы;
теләсәң сыенырга,
йә калырга качып,
никадәрле
үзгәрергә кирәк
шуларга яраклашып?..

* * *

– Шигырь шөгыленме? – дисең,
Шөгыль бит ул – кул эше.
Шигырь, дустым, Илаһының
Җанга өргән сулышы!
Чиксезлекнең аһәңе ул,
Мәңгелекнең агышы!
– Шигырь шөгыленме? – дисең,
Бу – гөнаһсыз ялгышың...

* * *

Күк – күп булыр кемгә дә...

* * *

Бизмә шигырь, ятим итмә колыңны,
Алма җаннан йомшак җылы кулыңны,
Балкыт Илаһыдан килгән нурыңны,
Яктырт мәңгелеккә күчәр юлымны!

* * *

Мәңгелек – акыл җитмәслек еракта,
Сере җитмеш җиде мең бер йозакта...
Киек Каз Юлында казлар тавышы...
Кемнәр китә... Кемнәр кемне озата?..

* * *

...Гомер атым туарылды,
арбасында җәсәдем...
Кайсы төше бу дөньяның,
шуны куып
җитәм, диеп яшәдем...

## ИБЛИС

Бисмилла әйттерер хәтта
үзенә бик кирәксә...

## ТӘКЪДИР

Тәпи атлап киткән көннән
Һәркем – мосафир...
Юллары төрле булса да,
барыр җире – бер...

* * *

Үзенә дәште кыйблам – Казаным,
Чакырды гел шигъри азаны...
Тик Нөркәмдә калып язармын
Гомер китабымның азагын...

* * *

Кайда да бер Кояш,
Кайда да бер үк Ай,
Кайларда торсак та,
Иманлы ит, Ходай!..

* * *

Сиңа килдем, утлар-сулар кичеп,
Өметемне кысып учларыма...
Ялкыныңа сулар сибим ничек,
Ут тергезим ничек учагыма?!

* * *

Көннең кашын сызган кара күмер,
Сөрмәсен дә тарткан карадан.
Көн белән төн арасында – гомер.
Йә, кем чыгалган шул арадан?..

* * *

Дөньяда Адәм баласын
күрәчәге җилкетә...
Күреп бетергәч күрәсен,
ике аршын җир көтә...

* * *

...Әүвәл телен кистеләр,
Аннан тотып печтеләр...
Ни әйтсен, кая барып,
Кече тел белән калып...

* * *

– Аһ-зарсыз яшәп кара да,
аһ-зарсыз язып кара...
– Юләрләр йортында сине
зарыгып көтә бабаң...

* * *

Тәүбә ит, бәндә, бер Ходаң каршында.
Туар көн,– җавап тотарсың каршында...
Кылган бар гамәлең, хәтта уйларың
Сурәттә күренер үз күз каршыңда...

* * *

Тәкъдиренә тәңгәлдер
Җирдә кемнең кемлеге.
Кем сөйри, кем сөйрәлә,
Кемдер дөнья кендеге...

* * *

...Юлыңа
кар аттым, –
барыбер
караттым.

* * *

Илләр гизеп кайткан, имеш,—
дөнья күргән...
Чабатасын элеп куйган
чөйгә түрдән...

* * *

Бөек булып була биеп тә...

* * *

Көлгән йөзгә көл ятмый...

* * *

...Комганыннан көлә сәхнәдә
тәһарәтсез татар баласы...

* * *

Хәленә кермәс кеченең
кимлекне кичермәгән...

* * *

Болыт куерып каралды.
Томан куерып агарды... —
Болытлы, томанлы иртә...
Каеннар тора караеп.
Күңелем калды сагаеп, —
Күк адаштырып кояшны
Кайларда йөртә?..

* * *

Агыйделне боз тоткандыр,
йокыга талгандыр яры...
Тал-курасын сызгырткандыр
кышның беренче бураны...
...Ялгызым калган бу төндә
бәсле тәрәзәмә багып.
Уйлап утырам шуларны...

* * *

...Көл, күңел, дөньяның моңы
бер безгә генәмени?

*Р. Фәйзуллин*

Көл инде, күңел, көл инде
дөнья ямьсез түгел лә!
...Бер чеметем куаныч та,
шөкер итсәң, җитәр иде
мең тулып түгелергә...

* * *

*Г. Афзалга ияреп*

Рәсәй һәрчак супер булды,
Тик халкына сукыр булды.
Талап алды бар җирен,
Тиенләп бирде әҗерен...

* * *

Иске елның соңгы көне...
Көтмәгәндә, нигәдер,
бастырылып, бөтен тәнне
ямансулык биләде...

* * *

Урам тутырып үттеләр,
үр ягына киттеләр...
Артларыннан үкси-үкси
өреп барды бер көчек...
Гүргә илтеп керттеләр...
Китә дә бара кеше
үр-гомерләрен кичеп...
Озатып калыр кем, ничек?..

## ТАШ, БОЗ ЯВЫП ТОРСА ДА...

Бәйрәм көне дә аңа гел кырын:
кышын – дулап буран котырыр;
яз, көз – сыктап явар җепшек кар;
җәен – яңгыр яшенләп кояр...
Таш, боз явып торса да торыр,
Сабан туен татар уздырыр!..

* * *

Җилләрдә җилләт кереңне
Юл өйрәт юлаучыга...
Яттан йозакла сереңне,
Ерак тор юраучыдан...
Сәвабы булыр, йә булмас...
Хәер бир сораучыга...

* * *

Күз карасы кебек дусларым бар
Күз карашымнан ук аңлаучы!..

* * *

Мәңгелек боз таулар эреп, кибә
күзең ачып йомган бер мәлдә...
Мәңгелеккә килгән кебек, нигә
нәфсең котыртасың, и бәндә?!

* * *

Тыелган татлы җимешем.
Татымаган тәгамем...
Ничекләр итим көмешем?
Үзең тап бер әмәлен...

* * *

– Кагылма,– дидең,– күңелгә,
уалыр пыяласы...
Түгелеп китсә, тамчылап
кем диңгез җыяла соң?!

* * *

Көнем өчен – Син бар,
Төнем өчен – Син бар...
Көннән, төннән торган
Дөньям
Синең өчен ник тар?..

* * *

Бөекләрнең биеклеге
Кызыктырмады һич тә.
Кояш булып кояш сүнә
Сүрелеп бетеп кичтә...

* * *

Алып барыр юлы бер генә –
Тәгәрәпләр китте йомгагым...
Дөнья – фани... гомер дигәне –
Бер ачып, бер күзең йомганың.

* * *

Никадәрле кирәк – шулай чыда,
тик таштай катмасын күңелең...
Таш күзеннән дә яшь бәреп чыга,
төпсез күле тулса түгелеп...

* * *

Җилләр исә, тарый еллар толымын,
Буразналы йөздә язмыш корымы...
Алын – ал, гөлен – гөл иткән чак булды:
Һәр мизгеле бер гомергә торырлык!..

* * *

Янып бетеп бара гомер – тоямын,
Сүрелгән көлләрен җаннан коямын...
...Фатихасын алырмын, шәт, дөньяның,
Дүрт ягын да тигез күрдем мин аның.

* * *

И кара малай,
Карама алай?!

* * *

Хәдискә тиң мәгънәле
Шигырьләре Әгъләмнең.

* * *

Йөзләгән күз багып торсын әле
Сулыш алмый тынып калуларын...
Чайкалмасын, тоныкланмасын, дип,
Чүгеп чишмәдән су алуларын...
Мөлдерәмә тулы чиләгенә
Кояшны да хәтта учлап салды...
Чишмә читендәге чуер ташка
Яшь кәләшнең шатлык яше тамды...

* * *

Илбасарны илләр басмый торса,
Чир-чор баса: кыза, өшәнә...
Милли арысланнар, милли филләр
Керәп йөдәтә гел төшенә...

* * *

*26 нчы апрель*

Изге бер әманәт итеп,
Догасына тиңләп,
Тукае туган көнендә
Шигырь укый милләт!..

* * *

(*Мәсәл*)

Койрыгын кысып, посып яткан көчекнең
Беркөн салпысына салам кыстырдылар.
Тартып-сузып ике башка үстерделәр,
Аннары соң – хуҗасына өстерделәр...

* * *

Кырлач буе яңгыр койды,
Күрмәгән ышанмас та...
Килде дә керде бу тойгы –
Күңелләр сискәнеп куйды:
Кешем, ниләр кылыр идең,
Кырлач килсә ыспаста?..

* * *

Человек – это звучит гордо!
*М.Горький*

Җир йөзендә сугыш булмый торса,
Чебен-черки күбәя, имеш...
Кешем, ни артыгың шул чебеннән,
Исемең горур яңгыраган килеш?..
Үз хәлеңә төшен дә, килеш!..

* * *

Керфегем төште кәгазьгә,
киселде язар сүзем;
сулкылдап елап җибәрдем,
яшьләнде төннең күзе.

* * *

Укыдым – ташка басылган, –
Мансуров мөһре басылган;
М.Әгъләмов эзләреннән
Йөргән, имеш, Мәхмүди...
Илдар Юзи үзе күргән –
Ышануың мәҗбүри...
Ышанырга телим дә бит,
Шигем дә туа тагын...
Һималай-тау түбәсеннән
Юзи – Әгъләм сукмагын
Эзләп тапсын ди, Мәхмүди?!
Яхшыга юрыйк барын!..

Мансуров – Зиннур Мансуров – «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире, М.Әгъләмов – шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов, Мәхмүди – язучы Заһид Мәхмүди, Илдар Юзи – шагыйрь Илдар Юзеев.

* * *

Ага да ага вакыт,
дәрья-су кебек...
Кеше гомере –
дәрья-суда бер күбек...

* * *

...О войне?
Окопная правда еще
не написана...

*Г.Бакланов*

Окоп дөреслеген язар өчен,
окопларда яту кирәк шул.
Окопларда ятып,
исән калганнар бик сирәк шул...

* * *

Бар да үтә,
Бар да китә.
Кала хәтер.
Кала кабер.

## ӘНКӘЙ

Карашыңны тоям һәр тарафта:
агып барган ап-ак болыттан да,
ак күбеккә баткан шомырттан да,
бармак имеп яткан оныктан да...

## ТОМАНДА

Талы да юк, яры да юк,
Агыйдел дә юк сыман:
бар җиһанда салкын тынлык,
бар җиһанда ак томан.

* * *

Тулган Ай серле елмая.
«Таныйсыңмы әллә?» – дим.
Төнозын бер керфек какмый,
Айга баккан бәндә мин.

* * *

Без кабызган утлар янып тора,
без төзегән йортлар балкып тора,
без омтылган оҗмах-тормыш кына
офык артларына качып тора...

* * *

Кайнар хисләремне
салкын карашыңа
манам да алам, манам да алам...
Барыбер янам...

* * *

Нур очына куныл,
урап кайтсам әгәр
киләчәктән,
сөенерме күңел?
Әллә көенерме
күрәчәктән?

* * *

Җир
галәм каршында
имтихан тота —
өлгергәнлеккә.

* * *

Ерак калмады шул инде язга,
изүләре ачык кышкы көннең.
...Һәм, мөлдерәп, очына тамчы төште
күңелемдә тулган боз сөңгенең.

* * *

Һәркемнең
тәнен — Җир,
җанын Ай
көтәдер...

* * *

Ник баса бу моң мине,
авыраеп баса моң?
Килә чыгып чабасым,
ертып төннең карасын.

* * *

Белмим
алда тагы ниләр күрәсемне.
Беләм
барысы өчен кыйммәт түләсемне.

* * *

Иңемдәге
ике фәрештәнең
берсе – нәфис,
берсе – нәфес.

* * *

Карама очында ярты Ай,
үләндә таң чыгы ялтырый...
Изелгән җиләкләр өстендә
онытылган кулъяулык зар елый...

* * *

Языласы җырлар языламаган,
табынасы ярлар табылмаган.
Үткәннәрдән гыйбрәт алынмаган,
киләчәккә күпер салынмаган.

* * *

Уң кабагым тарта,
сул кабагым тарта:
әллә шатлык арта,
әллә кайгым – артта?

## ШИКЛӘНҮЧЕГӘ

Чүплектән тапкан сөяген
кемдер талый дип белеп,
куып җибәрмәкче бер эт
үз күләгәсен, өреп.

## АВЫЛДА БЕР КИЧ

Җырлап үттеләр урамнан
түбән оч егетләре!..
Өреп чыктылар
дуамал
югары очның этләре...

## ШӨКЕР ИТӘМ

Әткәм-әнкәм гомер биргән,
үзләренекен өзеп.
И Раббым, шөкер итәм:
дүрт ягым да төп-төзек!

## ЯЗНЫ КӨТКӘНДӘ

Кыш күтәреп киде бүреген,
салыр бер көн, куяр элеп үк.
Күр, үзгәрә төсе бөренең–
тулып килә күзгә күренеп.

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Авыл саен бер исерек,
бер исәр, диләр иде.
Хәзер бары да исерек...
акыллысы ничәдер?..

## ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫНДА

Төннең Җиргә кайтасы бар,
Җанның Күккә китәсе.
Җир белән Күк арасында
Гомеркәйләр итәсе...

## ...ТОРА ДӨНЬЯ

Гаҗәпләнеп тора дөнья:
– Нишли татар, нишли? – дип,–
Бербөтен булу кирәктә
Берсен-берсе тешли,– дип...

## КӨЗДӘ БЕР МӘЛ

Коелган сап-сары яфраклар
пышылдап, серләшеп яталар...
– Бар иде тибрәлгән чаклар! – дип,
бер-берләрен юаталар...

## ТЫНЛЫК

Тынлык – могҗиза,
телим дисәң, син хәтта
уең агышын,
карашыңның тавышын
тыңлар идең тынлыкта...

* * *

Роза гөлем ачты чәчәкләрен,
Бүлмәм тулды алсу, моңсу нурга;
Юылды да бетте юшкыннары,–
Күңлем тулды нурлы, моңлы җырга.

## ШИГЪРИЯТ

Аерма татлы газабын,
Шигърият, колыңнан.
Сине эзләп килде җаным
Мең яктылык елыннан!

* * *

*Гамил Афзалга ияреп*

Җаны телəгəнгə – елан ите,
Күгəрченкəй сөте кемнəргə?
Ил казнасын талый эте-бете,
Хуҗасы үлəр-үлмəс көннəрдə...

## КЫШКЫ ТӨНДƏ

Шартлап ярылды бүрəнə,
күңел ник курка шунда?..
Əллə яшен яшьнəдеме
кырлач төн уртасында?..

## КӨЗ

Көз, көяз кызлар шикелле,
көн дə бер күлмəк кия.
Ни кисə, шулай сөйкемле,–
минə күз нидəн тия...

## ...НИ КАЛГАН?

Булган су тегермəне,
булган җил тегермəне –
аларын юган вакыт,
калган тел тегермəне...

## КОШ ТЕЛЕ

Кош теле җибәргән Әнкәй
күчтәнәчкә авылдан.
Каптым, тик йота алмадым,
куркып телсез калудан.

* * *

Торган җирең ничек, дисәң әгәр,–
Кайтыш ягын әйтү уңайсыз:
Туган җирдәгедәй күкләр зәңгәр,
Тик зәңгәр күк монда тургайсыз.

## КӨЗ СОҢЫ

Калмаган бер яфрак коясы,
калган бары карга оясы...
Утырып карт тирәк төбендә,
уйларымны калды җыясы...

## ИРТӘ ЯЗДА

Иртәләгән яз барыбер
бер хикмәтен күрсәтер.
Кырау суккан алмагачның
керфегендә күз яше...

## БЕР КАРАСАҢ

Бер карасаң, шәп бу дөнья,
бер карасаң – күңелсез.
Еларсың да, көләрсең дә,–
барысын да күрерсең,
барысына күнерсең...

* * *

Таныйм сине, гөлем, болындагы
бихисап күп гөлләр арасыннан;
янып торган йөзең мең адымнан:
– Монда кил! –
дип, чакырып ала сыман.

## ШИГЪРИЯТ

Читләштеләр күпләр, инде син ят.
Сан бирерлек, имеш, сының юк.
Тик мин һаман колың, Шигърият,–
Синнән башка сыеныр җылым юк!..

## ЕГЕРМЕНЧЕ ГАСЫР

Тагын дүрт адымнан
вакыт күз алдыннан
мәңгегә югалыр
егерменче гасыр –
тәмуг-ут йомгагы...

* * *

Буш бүлмәмдә сәгать һәм мин –
ялыктыргыч бертөрлелек:
үткәрәбез көнне, төнне,
бер урында бөтерелеп...

## СҮЗ СОҢЫ – НОКТА

Ни йөртә юлда кешене
әле анда, әле монда?
Форсат-җай эзләү эшеме,
Ил-йорты, килер төшеме?..
Сорауның чиге юк та,
әйтер сүз соңы – нокта...

## МИН – КӨЗГЕ ШИГЫРЬ

Мин – көзге шигырь...
араламагызчы:
көзге төскә кереп януымнан;
янып-ялкынланып азаккача,
алтын төскә кереп калуымнан!

* * *

Чүкеп-чүкеп бөгелмәгән,
чыңлаган корыч булдык.
Яуда җиңелү белмәгән,
сынмаган кылыч булдык!

## КӨЗГЕ КӨЙ

Көзге көй, юкә балыдай,
татлы да, мөлаем да;
Ничек җырламый түзим соң
моң сарган көз аенда?!

* * *

Случай – сам великий вор...

*И.В.Гёте*

...Төн – тотылмас карак:
Йомылдырып күзләрне,
урлый безнең гомерләрне...

## КӨЗГЕ ТӨС

Көз төсенә тиң куярлык
Кайсы төсне тапмак кирәк?
Вакыт үзе, хәйран калып,
Алтын көзгә башын игән.

* * *

Заманаы хурлый-хурлый,
аласын алды барыбер:
тау башына, урлый-урлый,
таш пулат салды барыбер.

* * *

Китәселәр китеп торсалар да,
карыйсы да килми ул якка;
Газаплардан гына торган дөнья
һаман саен үзенә тарта.

* * *

Балачактан иртә кояш чыга,
Балачактан һәр кич ул бата.
Шушы бөек ике күренештә
Җирдә яшәү мәгънәсе ята.

* * *

Кайда туып, кайда торасын
алдан кемнәр белсен, юрасын?
Фани дөнья, килү-китү дигән,
әй борылып аккан елга син,–
яшәү – гомер итү йоласы...

## СИННӘН БАШКА

Бу кичтә синнән башка сагыныр кешем юк,
Сагынудан ары һичбер сарылыр кешем юк.
Бу кичтә синнән башка табыныр кешем юк,
Табынырга сиңа тиңдәш табылыр кешем юк.

## БЕР

Булгәләп һәм кечерәйтеп
Булмый икән бер санын;
«Берәү генә» дигән саен,
Зурая, арта даны.

## БОЛЫТ

Болыт, гаеплиләр сине юкка.
Синдәй хезмәтче юк та:
җәен, каплап кояшны,
коткарасың пешүдән,
кышын исә — өшүдән.

* * *

Теләгәндерме берәрсе,
теткәләнсен, дип, җаны;
көтмәгәндер дә, күрәсең,
шулай түзем торасымны.
Югалтканнар гына белер
яшеренеп еласымны.

## АНЫ ГЫНА КҮЗЛИМ

Күркәмлекне, шундый гүзәллекне
табигать һич юкка бирмәгән;
белмим, кайчангача түзәрмендер,–
аны гына күзлим иртәдән.
Әлегәчә йөрим сиздермичә,
рәхмәтеңнән, Тәңрем, ташлама;
инде белмим ниләр эшләремне,–
язлар быел иртә башлана...

## ИЛҺАМ

Киреләнсә, килми,–
чакыр-чакырма син;
килгән чакта сизеп
калсаң – Акын ла син...

* * *

Күк чакыра кебек җанны,
күңел шуннан курка да.
Күп татыган бу җиһанда
калып булмас, кусалар.

## ҮЗЕМӘ

Җилгә сөйләмә сереңне,
җил – гайбәтче – чәчәр генә.
Гайбәт түгел, кырау тимәс
шайтан таяк чәчәгенә.

* * *

Гомер җыйган гөнаһлардан
арынасылар килә.
Юып элгән ак күлмәктәй,
сарыласылар килә.

* * *

Адашып кергән уйларым –
чит оя бәбкәседәй,
бәргәләнә-бәргәләнә
чыгып китәр җай эзләй...

## ҖӘЙ УРТАСЫ

Сандугачлар тынып калды,
өндә берни аңламый,–
урманымда җәй уртасы,–
кәккүк шуны аңламый,
бертуктаусыз алдалый...

* * *

Чалманарат – гомерем бишеге!
Егылып төшмәсен дип, чабуымнан
бәйләп үк куйган кендек әбисе...

## ...ДИДЕ АВЫЛ

Кыш чыкканчы, өч исерек
бар урманны кырып салды.
– Урман бетә,– диде авыл,
тик аһ-зардан узалмады...

* * *

Ташны таш бәреп ваталар,
Ташка таш бәреп ут чыга.
Таштан бар авыр хаталар.
Таш атма узгын юлчыга...

* * *

...учагымда
дөрләп яна
синең хактагы
уйларым,
күмергә калып.

## АЙСЫЛУГА

Ачыласы күпме
Йолдызлар бар күктә,
Сабыр гына көтә үз чиратын.
Ышан, көт, өметлән,
Ләкин һич сүндермә
Учагың – өметең –
чылатып!

## БЕЗ КЕМ?

... вакыт һәм киңлектә
хыялымы,
йә ихтыярымы
без
кемнеңдер?..

* * *

Кунак кына булган
бу җиһанда
мәңге һичкем калмый.
– Күңелемне юам,
Иман җыям:
Җан хакы да бар, дим.

## ИЛ БӘХЕТЕ

Һәркем
бәхетле тик шулчакта:
Илең булса ирекле,
Ил агаң игелекле;
Туган җиргә тиң-тигез
Торган җир булса газиз.

* * *

Тормыш дигән шушы алачыкта
чүки-чүки кеше сын аладыр;
Очкын чәчеп торган корыч булат
Чын кылыч булганчы сыналадыр.

* * *

Күз алдымда сабый «мин»легеңә
шакшы үкчә белән типтеләр.
Түзә алдың, сынатмадың, улым,
минем яшьләр әле дә кипмиләр.

* * *

Җигелеп дөнья йөгенә,
үр мендек, эч чыгарып;
мал да юк, дан да килмәде,
булдык көнлекче бары.

* * *

Ихтыяры да ул, эч сере дә,
күпләр көтеп алды шатланып,
изүләрен ертып бер эчсеннәр —
көн дә төшермиләр патшаны.

* * *

Гомер буе язган кызыл шигырь
Ак шигырьгә ничек күчсен хәзер?..

* * *

Ятып язган шигырьләрең
йоклыйсыны китерә.

* * *

Бу – минем шигъри бакчамда
өлгергән тәү җимешләрем;
өзеп алыгыз, кабыгыз
үрелеп буегыз җиткәнен.

* * *

Күкләр куйса киртә,
Күкрәп булмый һич тә,
Кояш байый гына,
Кояш чыкмый кичтән.

## БЕЛӘ ТОРЫП

Туган туганын рәнҗетә бик еш,
белә шул ул аның кичерәсен.
Кайчак читне якын итәбез,–
белмибез лә агу эчерәсен.

## ӨМЕТ

Ялгызлык – явыз чир,
телә гел бәгырьне.
Кызганма, кыйнасын, кыйнасын.
Көткәнем үткәннән
барыбер кадерле,
өметем – яшәвем кыйбласы.

## ШОМЫРТЫМ — БАЛАМ, ДИП ЯШӘГӘН АНАНЫҢ СҮЗЛӘРЕ

Ак чәчәккә күмелгәндә,
Ак бәхетләр вәгъдә иттең.
Җимешләрең өлгергәндә
Тәлгәш-тәлгәш кайгы сиптең.

## ӨМЕТСЕЗЛЕК

Кояшым сүнде, җылынам
чит-ятлар кояшында.
Көнем үлде, ә төннәрем —
үрмәкүч оясында...

## МӘҢГЕЛЕК СОРАУ

Гел яңаны эзләп табабызмы,
Табып югалттыкмы күптәннән?
Киләчәккә таба барабызмы,
Кайтып киләбезме үткәннән?

* * *

Күктән бәхет, дан иңмәде,
Йолдыз булып балкымадым.
Дан яки Вөҗдан дигәндә,
Сатмадым һәм сатылмадым.

* * *

Катлам-катлам кара болыт
Каплаганда күгемне,
Яшен булып яшьнәдем мин,
Яңгыр булып түгелдем.

* * *

Ятлар аш куйды – ачыктым,
су бирде – сусадым,
Җылы сүз атты – туңамын...

* * *

– Тәмле! – диден, иренең тигездең дә
тамып чыккан каен суына.
Чисталыгын суның шул мизгелдә
күчердең син елмаюыңа.

* * *

Килер көннәр
кайчан да бер
очраштырса безнең сукмакны,
шул мизгелдә
мин вакытны
торыр идем мәңге туктатып...

## КУРЧАК ХАКИМ

Курчак хаким – мең кат яман
юлбасардан,
илбасардан.
Тегеләре бер талый да китә.
Курчак хаким,
таланганны талый-талый,
форсить итә.

## КӨН УРТАСЫ

Җәйге урман. Көн уртасы.
Тынып калган тирә-як.
Кинәт, сискәндереп җанны,
Җиргә төште бер яфрак.

## ИЛҺАМ ҖЫРЫ

Илһам җыры –
Йомшак, җылы
Сабый куллары кебек!..

## ҖАН

Бүрәнәдә бер күбәләк,–
Урап кайткан кем җаны?
Бүрәнәсе белән бергә
Күтәргән ул Җир шарын.

* * *

Читләр кулы белән куз тоткан,
Читләр теле белән тоз йоткан.
Баса-баса арык аркаларга,
Вәзир булганлыгын оныткан.

* * *

Белсен, диеп, үз урынын,
Кул бирмәдең, җирәндеңме?..
Кыйммәт черки горурлыгым
Сатып алган дәрәҗәңнән.

* * *

Һич туймады нәфесе кан эчеп,
Әләк, чагу, бүген, кичәгесе.
Белә торып, ничек кеше дисең,
Син – дөньяның сукыр эчәгесе.

* * *

Көнне көнгә ялгыйм ничек,
Уртасында озын төн бар?
Кырлач гыйнвар төнендә
Явыз ялгызлык хөкемдар.

## И КҮҢЕЛ...

Әрнемә, рәнҗемә, и күңел,
«Беткән бу»,– димәсен берәрсе.
Дәвере болганчык, белмәссең,
Уткамы, сугамы керәсе...

Язмышларны язган без түгел,
Әрнемә, рәнҗемә, и күңел.
Безгәчә килгәннәр, киткәннәр,
Димәк, без дә мәңгелек түгел.

* * *

Ташны бәреп чыккан чишмә кебек,
Яшәү даулап тудың дөньяга.
Яхшыгамы гомерең, ямангамы
Багышларсың икән, и бала.

* * *

Син әле белмисең:
бик шапшак бу дөнья.
Иртәгә мин аны
чакырам дуэльгә...

* * *

Хыянәтне кичерә алмый йөрәк,
ачу-нәфрәт инде сүнсә дә,
акыл шуңа күптән күнсә дә,
гафу сорап тезем түнсә дә...

* * *

Кан көндәше – шагыйрьләрне
Һәр тиран үзенчә кырган:
Кайсы – өзгән чабып башын,
Кайсы – данда тончыктырган.

* * *

Зәңгәр күзләреңнең тирәнлеге –
диңгезнеке,
Киңлеге – күкләрмени!
Кабул итми күңел синсезлекне,–
ничекләр түзәрмендер.

* * *

Чәйгә генә тотар иде Әнкәй
Вәлкәй чишмәсенең суларын.
Дүрт ягында булдым бу дөньяның,
Белмим аннан татлы су барын.

* * *

Урманда көз,
Уйларда көз.
Мөлдерәмә моңсулык.
Бусагада гомер көзем,–
Ихтыярым, булчы нык!

* * *

Торган җирнең
Туган җиргә
тиң газиз түгеллеген
җиде ятлар арасында
җиде көндә үк белдем.

* * *

Бу дөньяның ачысын да,
төчесен дә татыдык.
Уелды мәңге хәтергә
гадәттән тыш катылык.

* * *

Чиктән ашып курыктыкмы,
күндекме «тугрылыкка».
– Шөкер,– диеп үтте гомер
мескенлектә, хурлыкта.

* * *

Сызып үтә көннәр, бер-бер артлы,
үтә өметләнгән сәгатьләр.
Үткән саен үкенүләр артты,–
табып кына җиткер сәбәпләр.

* * *

Бер бакча–
Дөньялык,–
Керү бар,
Чыгу бар,
Калу – юк...

* * *

Өметләр зур,
океаннар
кичәрбез кебек иде.
Юл чыктыкмы «Бисмилла»сыз,–
көймәбез комга тиде.

* * *

Аркалары белән әйләнеп яткан,
коелган тал яфраклары күл өстенә...
Офык читендә болытларга ут капкан:
әллә кояш баткан,
әллә таң аткан.
Бераздан шәфәкъ-кызыллык
югалыр эреп:
төнгәме,
көнгәме?

* * *

Киләләр дә китәләр тәлинкәләр,
Йә, әйт, ни кызыгын табалардыр?
Иртәгәсе көндә Рәсәй шаулый:
– Читләр безне шефка алалар,– дип.

* * *

Тигезсез яратылган дөньяда
Тигезлек даулап гомер уза.
Тигезлек бары теге дөньяда:
Хаким дә, сукбай да бер – тузан.

* * *

Адәм баласына ни җитми:
Сулар һава, эчәр сумы?
Шәрәме без бүген?
– Ирек җитми,– диде малай...
– Каты кул!..– диде бабай...

## АЧЛЫК

Ачлык кычкырып елый урамнарда,
Ачлык – козгын, ачлык – карчыга.
Ачлык түбәнсетә, тезләндерә,
Илтеп дошманыңның каршына.

## ГАЛИ ЗАТ

Философлар читтә торыр, хәйран калып,
Аракының зарарын ул аңлатканда.
Хәмер капкач, охшап кала бу «гали» зат
Ләгәнгә төшкән бер сары тараканга.

## ИР-АТ

Тимер куллар
тимер атлар
таптылар да уйлап,
мыскылланып,
мескенләнеп
калды җирдә ир-ат...

## КАРАВЫЛ

Кояш чыкканда
йоклап ятканнар
дучар яшәргә
гел ярлылыкта,–
ди иде картлар.

Иртәнге алты,
төш күреп йоклый
мең йортлы авыл...
Чаң сугып кычкыр:
– Ка-ра-а-вы-ыл!

* * *

Таллардан биек таулар бар,
Таулардан биек болытлар,
Болытлардан биек йолдызлар.
Йолдызлардан да биектә
«Әнкәй» дигән Бөек Йолдыз бар.

* * *

Яшәү – үлү арасы –
Күз һәм каш арасыдыр.
Язылганы язмышыма
Авыр таштыр,
Аның да карасыдыр.

* * *

Күзнең төсе төссез быел,
Төссез, болганчык судай.
Гомерләрнең күзен шулай
Итә күрмә, и Ходай!

* * *

Агыйделем, Чулман, Иделем–
Шаһиты Болгарым иленең.
Далада Кирмәнчек таулары –
Шаһиты үткәргән яуларның...

* * *

Килмешәкләр килеп, Ак Илемне–
Агыйделне киткәч караптып,
Туган җирдән аерып еракларга,
Язмыш безне кыйный-кыйный йөртә,
Дөнья буйлап сибеп, таратып...

## КЫЗЫЛ КАР ЯВАР МИКӘН?

Кыйбласызларга
кай яктан
чыкса да Кояш – барыбер;
(Аркаларын җылытырга
борылып яту да җитә.)
Уйларымны бутады гел
офык читендәге кызыл шәфәкъ:
явармы кызыл кар җиргә?..

## И САБЫЙ

Колагыңа
Иман сүзе
Пышылдадым,
И сабый...
Аңладыңмы,
Болай гына
Елмайдыңмы,
И сабый?!

## ӘБҮГАЛИСИНА

Башын торкан,
Аптыраштa
Әбүгалисина:
– Кая киткән
Мең ел элек
булган медицина?

* * *

Көзгә керәм. Агачларым
яфракларын коймый гына.
Көннән-көн ныграк уралам
көзнең сары толымына.

* * *

Гомерләрнең күзе түгел,
җәйге чагы,
дөнья йөге арбасына
бәйле чагы.
Үргә менеп, каерылып
бер карагач:
– Сөбханалла, иншалла! – дип
әйтер чагы.

* * *

Минем дә чаларды чәчләр,
Бар дөньясы шулай булгач...
Бер чиметем бәхетемә
Чиләкләп кайгы коелгач.

* * *

Алтынсыз яшәп була.
Хатын-кызсыз,
Алтын күзсез
Күңелсез...

* * *

Бердәнберем булмасаң да,
Берәгәйлем булдың.
Сикереп чыгып киртәләрне,
Күңелемә тулдың –
Гомерлегем булдың.

* * *

Бу мизгел –
Ташлап дөньяның
        ваклыкларын,
        юклыкларын,
Сине уйлаган чагым.

* * *

Акны – ак, дидек,
Караны – кара.
Хәләл хак бирдек,
Карап:
Дөнья малына
        һәм дүрт ягына...

* * *

Минем дә булды буранлап,
Давыллап алган чагым;
Күк карасын айкый-айкый,
Яшенләп яуган чагым.

* * *

Адаштырып хисләремне,
Елмаеп карамачы.
Инде белмим нишләремне,–
Ялгыштан аралачы.

* * *

Кырау да төшмәгән көз иде бит,
Каян килеп чыкты кар-буран?
Тупылларым яшел яфракларын
Калтыратып елыйлар сыман.

* * *

Итәк кисеп, җиңне ялгап кына
бөтен итеп булмый җиһанны...
Шыр дивана туган нарасыйда
бәргәләнеп елый кем җаны?..

* * *

Минем хыял –
Агыйделнең
Аръягында
Болындыр.
Бар теләгәнем –
Болындагы
Ак тояклы
Колындыр...

* * *

Томаландымыни хисләр –
Көлмим дә, еламыйм да...
Дөнья малы миңа нигә?
Бирмим дә, сорамыйм да!..

* * *

Күңелләр тулса хисләрдән,
Түгелү кирәк икән:
Җырлап булса да, елап булса да.
Исәннәргә күрешүләр
Ничек тә кирәк икән:
Якын торса да, ерак булса да.

* * *

Мәңге үтмәс төсле яшь чак,
Үтә дә китә икән –
Ташкын су кебек, аткан ук сыман.
Күзләренә кергәч гомер,
Кадерең бетә икән –
Йөзең көл сара, түрең – бусага.

## АҺ, ДИГӘНЧЕ

Җәяүләп кенә килгән җәй
Очып үтте аткан уктай.
Талларымны, аһ, дигәнче
Сары сарды, янган уттай.

## ИҢ АВЫР КӨН

Ничекләр генә соң җиңеләйтим,
җиңеләйтеп булмас хәлкәен...
Фани дөнья белән саубуллашып,
мәңгелеккә җыена Әнкәем...

## ТИШЕК ТУП ШИКЕЛЛЕ

...Төйнәлгән йодрык,
Сукмыйча, эленеп калды;
Тешләр бер-берсен чарлады;
Сынган каш астыннан
Нәфрәт очкыны атылды,
Шуннан –
кан сауган Йөрәк,
Суга баткан тишек
туп шикелле,
Авыраеп тулды...

* * *

Өзелде тамчы
Сөңге бозның күзеннән...
Раббым, бир түзем,–
Язга бары кул сузым;
Көзе, кышы түзелгән...

## 1994 ЕЛ

Шәүләләр йөриләр кебек
ишек артында,
тәрәз төбендә.
Ургып шик туа күңелгә.
... Календарьда
утыз җиденче ел
түгел дә...

* * *

Ятлар күз атты,
Төзәп, йөрәгеңә үк;
Ятлар сүз атты,
Төзәп, йөрәгеңә үк...
Үзең — йөрәгемә ук.

* * *

Җир, күк, йолдызлар—
Ноктасы чиксезлекнең...
Газизем, әнкәем,
Тиңләп шуларга,
Кечерәйтимме Сезне?!

* * *

Ерак тор, Мирза,
Нәфес колы ул заттан;
Дан, шөһрәт өчен,
Милләтен, динен саткан...
Пычагын тыгар арттан...

* * *

Карый кешелек
туар гасыр катына...
...Буразнада ат тора...

* * *

Бүләк итимме
гомеремнең яртысын?
Икеләнмим – алырсың...

* * *

Яшьләреңне шулай
агызмачы, и бала...
...Ярылып, эзе кала.

* * *

Ятагың салкын,
Кайда идең бу төнне?
Әйт, җылыттың син кемне?

* * *

Атлантлар киткән
төпкә, әллә күккәме?..
– Күккә,– диде Үрмәгөл.

* * *

Базар – мең ел зар,
бәяләр үскәненә...
...Кирәк гел өскә менә...

* * *

Агач корыса,
Оя кормый кошлар да...
Шуңамын пошаманда.

* * *

Үпкәләү дип уйламачы
вакыт-вакыт дәшмәвемне,
дәшми генә яшьнәвем, бел!

* * *

Кеше хәлен кеше белмәс,
Син белеп тор хәлләремне,
Тик күрсәтмә җәлләвеңне...

* * *

Кемнән кем туеп ялыккан –
вакыт күрсәтер ачык...
Килер көн, ташлап барысын
кем китәр кемнән качып?!

* * *

*Илдус Тархановка*

Ил күзе сиңа төбәлгән
лөгатьле сүз – эш көтеп...
Дөньяга таныт милләтне,
уятып әүвәл йокыдан,
савыктырып, өшкертеп...

* * *

Сәхнәдә коточкыч гаделлек:
Мөмкин – үзеңнән көлдерергә,
Мөмкин – көлдереп һәм елатып,
Төкәнмәс данга төренергә!..

* * *

*Зәнфирәгә*

Заманына карап туа
Әйтер сүз, җырлар җыры...
«Ни чәчсәң – шуны урырсың!» –
Фәлсәфи ягы шулдыр:
Исән чакта ниләр кылсаң,
Раббың каршысына басып,
Әйтәсең булыр туры!..

* * *

Һәр исемдә шигырь бар...
Шигырь – җисем бизмәне:
Кемдер – дөнья бизәге...
Кемдер – дөнья бизгәге...

# ТАКМАКЛАР

* * *

Илбасарлар үз кирмәнен
шартлатырлар әле бер...
Иблис үзен үтерде, – дип,
шаккатырлар әле бер...

* * *

Дуңгызын – аракысын,
Ашый-эчә милләтләр.
Рәсәй ничек таркалсын,
Уртак булгач нигъмәтләр?

* * *

Мәскәү – Казан арасы
төн озыны барасы...
Бару-кайту юлларында
йөкче татар баласы...

* * *

Чубайсны чәйни-чәйни
туймадылар барыбер...
Бур мәчене чүп базына
кумадылар барыбер...

* * *

Борис патша йөрәгенә
Ямау салгач бер татар,
Күр, ничек җитез элдерә,
Җитешеп булмый, каһәр!

* * *

Урыс генералларының
эше бик күп Чечняда...
Берсе китә, берсе кайта,
берсе комиссиядә...

* * *

Казанда казан асканнар
мир җыены ашына...
Гайре татар үзе җитәр
гайре татар башына...

* * *

Урысларның колхозлары
таралып беткән заман...
Татар, башкорт, чуаш, мари
ярышып эшли һаман...

* * *

Урысларның совхозлары
Сазлыкка баткан кереп.
Мари, чуаш, башкорт, татар
Җир актара, гөр килеп...

# АГЫЙДЕЛДӘ АК ПАРОХОД

*(Поэмалар)*



# ӘНКӘЙ

*Газиз Әнкәем Мөсәвәрә*
*Нурлыгали кызы Ибраһимованың*
*якты истәлегенә*

Кичер, Әнкәй,
Ничә кабат
Җыенып та,
Бер җыр да
Язалмадым
Синең хакта.
Сүзләремнән баскыч тезеп,
Үрелсәм биеклегеңә,
Кимчелек китермәм микән,
Әнкәм, бөеклегеңә?

## Бирешмә сагышларга

Юкәләргә карап,
Ниләр уйлыйсың син?
Сабырлар итик әле!
Бармакларың
Яргаланган,
Чәчләреңдә
Бер төк тә
Калмаган
Чалармаган.
Унбер балаң...
Узган көздә
Гүргә керде
Берсе аларның.
Күпме түктең
Күз яшьләрең;
Исәне дә,
Үлгәне дә
Хәтердә бит,
Мәңге яши...
Шуңадыр да,
Алар – тигез!..

Хәтерләрдән чыкмый –
Җанны телә,
Тырный-тырный
Бәгырьләрне...
...Алар унбер.
Ни юрасаң,
Шул килә дип,
Тибенгәндә
Карында ук,
Теләдең гел,
Өметләнеп,
Һәркайсына
Изгелекләр...
Ә чынлыкта
Никадәрле
Йөдәттеләр,
Йончыттылар
Алар сине?..
(Иң күп елатканы миндер?)

Күзләрең кайчандагыдан да моңсу бүген,
Нидән, нидән, Әнкәй?..
Зинһар, сагышларга бирешмә,
Ямансулау сиңа килешми!..

...Дәшми генә күзләремә карап тордың,
Иренең кыймылдады...
Елмайгандай булдың...
Күзләреңдә күпме сагыш
Көзге болытлардай авыр,
Катлам-катлам булып ага.
Йөзләреңдә буразналар
Төн чыкканчы тагын да күбәйгәннәр...
Кулларыңны күтәрдең дә
Маңгаема куйдың...

Кулларыңнан һаман
Сөт исе килә икән...
Кулларыңны йөзгә ягып,
Елыйсым килә, Әнкәй...
Юк, юк, һич кенә
Бирешмик ямансулауга,
Бүген, бүген кызың туган көн бит...
Кулларыңнан
Саныйк әле улларыңны!
Баш бармагың – өлкән улың,
Беренче җимешем, диеп,
Сөйгән идең күккә чөеп;
Үзең дә –
Үсмер генә,
Уйнап торган
Орчык идең.
Йөрәк парәң–
Синең өчен
Җанлы курчак...

Имән бармак –
Кыз көттегез:
Җиде айдан
Җитезләнеп
Туган улың –
Йомшак куян,
Эһ, дигәнче,
Барысын да
Узып китте.

Урта бармак–
Өметләнеп
Көткән бала–
Кыз түгел лә,
Ул да ул бит...

Өчтән ары,
Гел-гел шулай,
Булмас инде...
Кыз көттегез.
Исемсез бармак –
Өметегез.
Инде тагын,
Түп-түгәрәк айдай,
Сау-таза бер егетегез...

Дүрт ягында – дүрт ул!
Дүртесенә дүрт тел,
Дүрт көй кирәк.
Шулай икәнен
Белсә белер
Ана кеше!..

Чәнчә бармак...
Җәй уртасы,
Кояш чыкканда
Тулгак башланды,
Дөньяга килде
Ул Җан иясе!..

Күзең ачтың,
Тәрәзәдән
Көлеп карый
Тулган Ай:
– Кыз алып кайттың,
Килен,– дип,
Пышылдады бианай.

Күзләрең тагын йомылды,
Бәреп чыкты яшьләрең.

Шушы мизгел өчен гүя
Син утыз ел яшәдең.
Таң атканда
Тәүге кабат
Имездең нарасыең,
Көтә белгәч,
Ходай бирде,
Җитте бит сабырлыгың.
Сабырлыгыңны сынады
Тормыш ничәмә-ничә...
Сугыш, ятимлек, рәнҗетүләр.
Әллә, Әнкәй, яңартасың
Шуларны хәтереңдә,
Гомерләр кичә-кичә...
Зинһар өчен,
Сагышларга бирешмә,
Ямансулау сиңа килешми...

## Сугышны хәтерләп

Буран икән – күз ачкысыз,
Салкын икән – сөяк сынар.
Ир-атсыз калган авылда
Санап бетергесез толлар.

Күмер сорап, өйдән-өйгә
Кереп йөргән бала-чага,
Ач булса да, шайтан, чаба!
Син ятим, дип әйтеп кара.

Кизәк-тирес җылыткандыр
Бераз гына мичләр башын.
Мич башында ничәмә җан
Ятыр иде тәнен кашып.

Тәрәзләрдә – корымлы боз,
Койка исе пәрдәләрдә.
Тире-йон тетеп, төнозын
Кием тектек бәндәләргә.

Ир-атсыз калган авылны
Бүреләр басты төнен.
Китерәмсең күз алдына
Шул ерткычлар көтүен?
Ачка алҗыган малларны
Буып ташлап, сөйрәп тә,
Өреп чыккан этләрне дә
Калдырып шыр сөяккә,
Урам уртасында алар
«Кызыл туй» ясадылар...
Шул хакта ничә буынга
Хак сүзне язасы бар.

## Җаннарны Ай җыя...

Тонықланган күзләрен
Төбәгән дә бер ноктага,
Уйга талган;
Юлчы арбасыннан
Төшеп калган
 бер
Төенчек кебек,
Кечерәеп калган;
Бармаклары, бау шикелле,
Үрелгәннәр бер-берсенә...
– Ниләр уйлыйсың син,
Әнкәй?
Таныйсыңмы улыңны?
Бир әле кулыңны.

Бу бармаклар эрләгән җеп
Җир шарын ничә кат
Уратырга җитәр?!
– Җирдән Айга кадәр...
– Ә ни өчен Айга?
– Безнең барыр урын шул бит,
Җаннарны Ай җыя...

## Әнкәй тагын уйга чума

Толымнарың тубыгыңа тигән чагың,
Тәңкә-тәңкә чулпы тагып йөргән чагың,
Күзләреңне зәңгәр күккә тиңләр чагың
Уйлыйсыңмы әллә, Әнкәй, тып-тын калып?
Бишек сатып йөргән иде Касыйм бабай,
Бүләк итте сиңа берсен: «Зур үс, малай!»
...Күлмәк-ыштан үлчәп киткәч Сөннәт бабай,
Еламаган улым минем – син бит инде.

...Тупыллардан ява ак мамык,
Беренче кар яуган көнне
Атаң килде, атка атланып.
Ул да Айда инде...
Әнкәй?!

## Атаң лачын егет иде

Сугыш бетте.
Сагыш калды –
Өелеп калды ятимнәр...
Ир-атсыз
Авылга кайтты
Аяксыз да кулсыз ирләр...

Атаң батыр егет иде,
Протез иде аяклары,

Туйда сызгырып биеде,
Сындырып таякларын.

Аяклары юклыгын да
Кайберәүләр сизалмады,
Мина өзсә аякларын,
Канатларын өзалмады.

Өметләре, омтылышы,
Йөрәге шул-исән иде,
Аек акыл, лачынлыгы
Кайгыларны кисәр иде.

Бер төш кебек кенә хәзер...
И, гомерләр очкан уктай,
Гел төшемә керә, бәгырь,
Мин дә озакламам бугай.

– Әнкәй!..

– Таныйсыңмы?– дип сорыйсың,
Унберегез унбер якта–
Нәрсә уйлаганыгызны
Мин авылда сизеп ятам.
Берәрегез сырхауласа,
Авырый башлыйм үзем дә,
Кайгырсагыз – кайгыгызның
Ачылары күземдә.

Тоям әле, сизәм әле
Оныкларымның уйларын.
Шатлансагыз,
Елмаям да –
Таратам бар кайгыларым.

Унберегез унбер якта,
Гүр иясе шул берегез...
Барыгыз да тигез миңа,
Күңелемдә гел тере сез...

## Бабам энесенең малаеТәкый абыйга Әнкәмнең фатихасы

Кырлач диеп куркып тормастан,
Җиде чакрым җәяү юл атлап,
Хәл белергә монда килгәнсең
Туып-үскән җирем Кормаштан.

Йөгерә-атлап каршы чыкмадым,
Самавыр да үзем куймадым.
Минем хәлләр шулай дигәндәй,
Керфекләрем белән ымладым.

Син аңладың минем хәлемне,
Кулларыңа алып кулымны:
– Шөкер итик, апам, туганым,
Гомерләр узмады заяга,
Язганның барчасын кичердек.
Кирәк булган, димәк, безгә дә
Бу дөньяда яшәп алулар.
Җаннарыбыз булсын иманлы,
Тәңре мәрхәмәтле, бар ул, бер!..

– Соңгы дога, энем, фатиха,
Алты яшьтән калдым эткәйдән,
Фатихасын кемнәр сорасын,
Җиде ят җирләрдә калсын да...
Өй тутырып елый ятимнәр.
Сәвит талап алды ансын да,

Шыр ялангач калдык урамда,
Әткәң, эткәемнең энесе,
Алып килеп безне җылытты.
Рәнҗетелгән җиде ятимне
Ул итте дә үзенә, кыз итте.

Әнкәң –
Үсмер генә бала – яшь ана–
Абзыйдан да ныграк үз итте.
Ятимнәрнең күпмесе генә соң
Исән калды кара ул чорда.
Дошман балаларын туйдыра дип,
Абзыкайга күпме сүз булган?
Үксезләргә мондый шәфкатьлекне
Кыла фәкать изге җанлылар...
Балачакның ачы мизгелләре
Күңелемнән чыкмый калдылар.
Абзый төсе синдә дә бар, Тәкый,
Гадел дә син, сабыр, акыллы.
Туганымның хәлен белим, дип,
Җәяүләп килгәнсең Кормаштан.
Керфекләрең хәтта бозланган.
Җиз төсендәге ул чәчләрең
Чаларган икән шул, бүзләнгән.

Авылымның чишмә сукаен
Тигездең дә кипкән ирнемә,
Сусаган җаныма хәл керде...
...Абзыкайның бөтен игелеге
Күчкән сиңа – Тәкый энемә...
...Бу якларда чишмәләр калмады,
Торба суын эчә бу яклар.
Рәхмәт сиңа, Тәкый туганым,
Чишмә исән – үзе зур ядкарь.
Ничек яшәп ята Кормашлар?

Исәннәрме барча кордашлар?
– Гүр хуҗасы булды Мәрфуга?

– Кызыл яулык бәйләп, наган тагып,
Мал-туарын талап халыкның,
Шул Мәрфуга йөрде.
Мәчет манарасын ул кистерде,
Китапларын өеп яндырды.
Дошман, диеп, кулы эш тоткан
Ирләрне дә илдән ул сөрде.

Без дә –
жиде ятим сабый –
Шыр ялангач килеш,
Кеше нигезендә көн күрдек...

– Бәхиллек алалмый, җан тапшыралмый
Җәфаланды җиде ай.
Шулай да саклады карчыклар;
Җиде ай көнен һәм төнен
Мәрфуга елап ялварды:
– Бәхиллек бирегез, оныклар...
Бәхиллек бирегез!..

– И апа...
...Хәле яман андый кешенең.
– Вакытсыз гүргә кергәннәр,
Туган җирдән сөрелгәннәр,
Күпме алар?
Ничек алсын
Бәхиллеген һәммәсенең?

– Туган йортка кайткан иде
Минһаҗетдин Кәшбие.

Академик – табиб булган;
Бәхиллекне шул бирде...

Ахирәттә әле тагын
Ничек тотар җавабын?
Гыйбрәткәме, и Тәңрем,
Яраттың безнең җаннарны?!

Курыкмыйча кырыс кырлачтан,
Туганымның хәлен белим дип,
Җиде чакрым җәяү юл атлап,
Килеп җиттең бүген Кормаштан,
Керфекләреңә үк боз каткан.
Рәхмәт сиңа, изге туганым,
Татлы булды чишмә сулары,
Соңгы догам сезгә – фатиха,
Гел фатиха сиңа, туганым,
Һәм фатиха сезгә, фатиха,
Мең фатиха, кыз һәм улларым...

# КУЯН КҮЧТӘНӘЧЕ

## 1

Күз алдымда җуелмаслык сурәт:
бер менеп, бер төшеп буразнасын
басу буйлап Әнкәй кайтып килә –
иңдә – чалгы, кулда – кударбасы.

Иңсәсенә салган унлы чалгы,
тиеп-тиеп китә болытларга.
Итәгенә ябышып, мин атлыйм:
Калмаска тиешмен бер тотам да...

Иңсәсенә салган унлы чалгы –
бабакайның соңгы ядкаре.
«Корал эшләр, ир макталыр»,– диеп,
борынгыларның хак әйткәне.

Җиткереп чүкелгән унлы чалгы
солын* белгән Әнкәй кулында
кишәрлекләрне кырып, тезеп салды –
эш бетте – без кайту юлында...

Зәңгәр борчаклы ак күлмәгенә
ак алъяпкыч япкан, ап-актан,
ап-ак җилкән кебек йөзеп килә
кударбасын тартып еpактан.

Эш бетереп, Әнкәй кайтып килә,
көйли-көйли күңле көйләрен.
Башланмаган мең эш көтә өйдә,
ике аяксыз Әткәй биргәне...

* *Сол* – ысул.

Куларбада теш чыгарып яткан
энекәшнең тәпи очында
кузак-борчак – куян кучтәнәче,
Әткәйгә дип җыйдым учымда.

Әткәйгә дип, яз кузгалак җыйдым,
Җәй – бөрлегән, җиләк, чиясен...
– Куян кучтәнәчең тәмле, улым,
беләм һәрчак шулай диясен...

## 2

Җир астыннан бәреп чыктымы әллә,
күкләрдән соң әллә төштеме,
каршы чыгып басты «актив Мәрвә» –
тентемәкче, каһәр төшкере.

– Күрсәт,– диде,– кайда төенчегең,
кичә көндә алып кайткансыз...
Телсез калды Әнкәй, өнсез калды –
шуып төште арба япмасы...

Итәгеннән ычкындым да шулчак,
мин арбаны алып элдердем.
Табан асларымда янды учак,
белмим, ничек кенә өлгердем.

Билчәнгә дә бастым, кычытканга,
шайтан таягына таяндым.
Куларбаны йомычка шикелле,
очырттым көч алып каян мин?..

Җилкапканы җилләр ачып куйган,
кайтып кердем узып җилләрне.
Тын чыгармый яткан энем Рәшит
шунда гына елап җибәрде...

Протезларын салып куйган Әткәй...
тезләрендә атлап килде дә
алмаш-тилмәш безне күккә чөйде:
– Бөркетләрем минем! – диде дә...

3

Сугыштан соң туган балалар без,
әткәйләрнең тансык уллары.
Бераз гына күрдек ачлыгын да,
замананың каты кулларын.

Әмма, балачакның һәр мизгеле
Кабатланмас бәхет булган ул.
Җил капкалы Әткәм-Әнкәм нигезе
сыендырган, туендырган ул –
гел игелек белән тулган ул!

Кырык өч ел узган шул көннең дә
тик җылысын тоям, җилләрен...
Куларбасын тартып Әнкәй килә:
унлы чалгы баскан иңнәрен...

# КАБАТЛАНМАС МӘҢГЕ ДИГӘННӘРЕ

## 1

Сугыш – уен, сәнгать – җиңүчегә
Төкәнмәслек шөһрәт-мәртәбә.
Уенчыклар: хәнҗәр, сөңге, бомба,
Хәйлә, мәкер, үлем сәхнәдә.

Җаннар кыеп үлемсезлек алган
Күпме җәллад яши тарихта!
Ничек яшәмәсен, мең ел аша
без сокланып аңа карыйк та.

Башлар кисеп, манаралар тезгән
Аксак Тимер – бөек сәнгатькәр.
Кемгә явыз, кемгә бөек Иван
иманнарын хәтта үзгәрткән.

Бонапарт, Адольф, Джугашвили –
газраилдән туган җәлладләр.
Пол Пота, Грачев, Милошевич –
тарих өчен бар да сәнгатькәр.

Сугышканнар аршин җир өчен дә,
сугышканнар шоңкар өчен дә,
сугышканнар җария өчен дә,
ачу нәфрәт кайнап эчендә.

Дәүләтен көл, халкын кол иткән дә,
күңеленә үтмәс шом салган.
Исемнәре бөек ул затларның
кулы канлы, шөһрәте ялган...

## 2

Тарих сәхнәсендә тагын суеш:
тынып тормый шартлау, «урра»сы.
Түр сәхнәдә газраилгә бирнә –
Җеназасыз мәет бурасы.

Тарих сәхнәсендә тагын суеш:
кемгә табыш, кемгә югалтыш.
Козгын томшыгында саллы калҗа:
чукып алган сум ит – кул башы...

Тарих сәхнәсендә тагын суеш:
сәнгать була диме корбансыз...
Сәнгатькәрләр кылычларын кайрый:
бер орасын кат-кат ормассың...

## 3

Кабатланмас мәңге дисәләр дә,
гел кабатлап кына тордылар:
– Ватан өчен, изге орыш,– диеп,
бер гаепсез халык кырдылар.

Ватан өчен! –
бу салкын таш сүзгә
«Чатан» сүзе килә ятышлы...
Нәрсә соң ул Ватан?
Аналарның
бәгырь итен туптан атышмы?

Нәрсә соң ул Ватан?
Иманыңны
Фәхеш данга, малга сатышмы?
Каракошның томшыгында сум ит –
Кызыл туйдан кайтып барышы...

Каракошның томшыгында сум ит:
үзе туйган – күзе туймаган.
Ватан өчен ауган бер мең егет
Ничә мең туар җан тумаган?..

...Ватан өчен шәһид киткәннәрнең
фатихасын сораса Ватан,
кешелек һәм күкләр каршысында
тезем төшеп торалса Ватан,
Ана күз яшендә диңгез тозы –
йөзен чытмый йоталса Ватан,
– Кабатланмас мәңге,– дигәннәре,
Чынга ашар, бәлки, берзаман.

# ДӨНЬЯ СҮЗЕ – КӨН КҮЗЕ

Утыргычта капка төбендә
Авыл агайлары гәп кора.
Дөнья сүзе – сөйләп бетәрме,
Дәшми генә тыңлап утырам.

Дөнья сүзе – көн дә кирәк
әпикәй дә сөтле чәй...
Кыш чыгарлык утын-печән
хәстәрендә үтә җәй...

Дөнья сүзе – ямап, ялгап
тән капларлык өс кием,
язын-көзен, җәен-кышын
пар чабата – бер кием.

Көн дә бер сүз, көн дә бер көй –
көйли-көйли арыла...
Соңгы чиккә килеп җиткәч,
кемнәр килеп аралар?..

Кем дә килмәс, чакырсаң да,
гел ялгызың калырсың...
Дөнья сүзе – үз-үзеңне
куркуга нык салырсың...

Куркуга нык салырсың да,
көчсезләнеп калырсың,
вакланырсың – тиңләшергә
бөртек тары табырсың...

Юк, вакланма, бөтен кал Син,
гайрәтле кал, гайре кал.
Җир актарып, таш күчереп,
мая тупла, баеп ал!..

Дөнья сүзе – һаман җитми,
мал-мөлкәт, дип чабасың...
Җитәр иде, нәфесне юк
кечерәйтү чарасы...

Кемгә кирәк олы көрәк –
күтәрәсең, саласың...
Без йөгердек, без өлгердек,
без бит татар баласы...

Кемгә кирәк тимер терәк –
күк түбәсен терәсе?..
Без көрәдек, без терәдек –
бармы бездәй бирәрсе?..

Байлык куып, акча сугып,
Себерләргә җиттек без...
Дөнья йөге арбасына
үзебезне җиктек без...

Диңгезләре тубыктан ла,
диңгездән кем курыккан.
Тугыз баллы дулкыннарын
сугып ектык эш юктан...

...Таулар текә – менә-менә
терсәк-тезне канаттык.
Менеп җиткәч: «Күрегез»,– дип,
бар дөньяны караттык...

Утка кердек, суга кердек,
янмадык та батмадык...
Данның, малның хакын белдек,
сатылмадык, сатмадык...

«Атай малы – катай»,– диеп,
бот күтәреп ятмадык.
Уртак малны хәрәмләшеп
калын итеп якмадык...

Зимагурлар түгел дә без,
зимагур да бер очтан...
Зимагурлар баеп алгач,
он сибешкән, он очкан...

Безнең хакта чыккан җырлар –
барысы да безнеке.
Дөнья гизеп, «баеп» кайткач,
тыңлау сүзе – сезнеке...

Без – ярларны, ярлар безне
көтеп алды сагынып.
Көзләр китеп, язлар кайттык,
канатларны кагынып...

Рәсәй – иркен, кайда барсаң,
шунда көтеп алалар...
Кулга көрәк, кәйлә, балта,
иңгә – камыт салалар...

Дөнья – иркен, юллар озын,
барасы да барасы.
Туктап калма, алга ыргыл,
син бит татар баласы...

Дөнья сүзе – туктап калсаң,
тутыгырсың, түнәрсең...
Ялмап үтәр әҗәл җиле,
телең тешләп үләрсең...

Татар һәрчак һәм һәркайда
каралтылы, куралы.
Себерелгән ишегалды,
тыкырыгы, урамы...

Татар һәрчак мал-туарлы,
бәрәңгеле-бакчалы.
Сандыгында — кәфенлеге,
хәерлеге — акчалы...

Дөнья сүзе — эше дә бар,
ашы да бар кешенең...
Тик ятмасаң, җай бетәрме,
азмы дөнья тишеге?..

«Дөнья матур, дөнья киң»,— дип,
җырларын да җырладык...
Тарайганда, бергә сыйдык,
киңәйгәндә — сыймадык...

Дөнья сүзе — вакыт чаба,
кайсына бер җитәсе.
Бу дөньяны хет бер адым
узып алга китәсе...

Эшлә татар, ку дөньяны,
сүздән ботка пешмәсен
белдең,
инде бөтен ыру
баш күтәрми эшләсен.

# ТУРАЙГЫР

## I

Утызынчы ел,
июнь уртасы:
печәнгә төшәргә торганда,
чаң сугып халыкны җыйдылар
мәчетле-сәвитле урамга.

Җигүле атларга төялгән
чалгысы, сәнәге, тырмасы;
зур яуга чыгарга җыенган
авылны гаскәр дип торырсың.

Ары очтан бире очка олаулар
тезелеп киләләр мәйданга;
күзләрдә борчулы сораулар:
– Печәнгә соңардык болай да?

Кызу эш өстендә җыеннар
ешайды ник соңгы арада?
Печәнгә төшәргә торганда
ник җыю халыкны мәйданга?

Дугада ни сөйли кыңгырау? –
Җыела, җыела олаулар;
йөзләрдә борчулы мең сорау:
ник җыен җыйдылар оланнар?

Сәвит баскычына оланнар
тезелеп басканнар – тазалар;
бу җыен тагын кем башына?
Беленер – бул сабыр беразга.

– Җәмәгать, игътибар, җәмәгать,
тыңлагыз,– ди сәвит-Газизҗан;
каршыда райүзәк вәкиле,
һәм ике мылтыклы янында.

Райүзәк вәкиле Маловның
Кормашта икенче җыены;
Шәбезсу ярыннан чыкканда
тәүге кат авылны ул җыйды.

Куштылар атларны, җирләрне,
арбалар, чаналар, сабанны,–
колхозга берләште һәммәсе;
сөрелде һәр кулак саналган...

Комсомол ячейкасы
һәм изба-читальня
гөр килә Минһаҗ бай өендә,
Әбүзәр, Мәрфуга, Газизҗан
чиратлап куналар биредә.

Ячейка капкасы төбенә
бәйләнгән Маловның тураты;
теле юк, җаны бар малкайның,–
таныды каралты-кураны.

Таныды Кормашлар, таныды,
күрәләр Минһаҗ бай туратын.
Турайгыр тибенеп кешнәде,
хуҗасын чакырып, җан атып...

Хуҗасы юк инде – сөрелгән,
йортына ал әләм эленгән;
ә нигез бармы соң – ул үлгән,
һәм кызыл кәфенгә төренгән...

– Җәмәгать, игътибар, тыңлагыз,
игътибар,– ди сәвит-Газизҗан;
йөз йортлы авыл шым бу мәлдә,
тын калды мизгелгә бар җиһан.

Тын калган авылга вәкилнең
җирәнгеч тавышы ишетелде;
болытка сикерде Турайгыр,
бәйләгән тезгене өзелде.

Турайгыр кешнәде яңратып,
«Аһ!» итте мәйдан һәм тын калды;
кайтаваз кушылды айгырга,
бергәләп кешнәде йөз айгыр!..

Калтырап тордылар болытлар,
йөрәкләр калтырый, аһ, авыр;
сикереп олаулар өстеннән
болынга томрылды Турайгыр!

Һәм ярып авылны, һаваны,
пар мылтык тавышы яңрады...
Җир шары сискәнде – сизде шул
сөрлегеп Турайгыр ауганны.

Пар мылтык эшләде үз эшен–
каргалар, этләр дә юк булды.
Кормашлар баш иеп басканнар,
әйтерсең йөз пот таш муенда...

– Җәмәгать, игътибар, тыңлагыз,
куша ил һәм изге атабыз;
суд ясап мулланы, мөәзинне
бүген үк сөргенгә озатабыз...

## II

Чәчрәп чыкты әүвәл Мәрфуга,
төзәткәләп билдә наганын:
– Унар елга сөрик аларны,
аударыйк айлы манараны.
Сәвит-йорттан биек булып, ул
нишләп тора әле Кормашта?
Төзик дисәк яңа тормышны,
динне чабып өзик иң башта!..

Әбүзәрнең кыска әйтере:
– Шулай итик, хуплыйм,– диде ул.
Һәй, Газизҗан сүзгә бик оста,–
җиткермәгән җирен куймый шул...

...Райүзәктән килгән Маловның
Таләпләре төгәл үтәлде,–
мулла, мөәззин кулга алынды;
мал-туары кала җитәрлек.

Комсомоллар ярсып, шашынып,
манарага балта чаптылар;
ярымайга богау-бау салып,
атка бәйләп, түбән тарттылар...

Мулла, мөәззин берни дәшмәде,
бугазларда төер – таш иде.
Хәтта аркан тарткан атларның
күзләрендә канлы яшь иде...

Муеннарга аскан – таш иде,
җиргә тиеп игән – баш иде,
Турайгырның күзен чокыган
каракошлар бигрәк ач иде...

...Шәбезсуда язгы ташкында,
тугаенда печән җиттисә,
итәгеннән өстерәп, хәтер
утызынчы елны китерә...

Күз алдымда: мәчет – аумаган,
түбәсендә шул – ярымайдыр;
томырылып чапкан уңайдан
кешнәп үрә баса Турайгыр...
Кешнәп үрә баса Турайгыр!!!

*Актаныш*
*Февраль, 1996*

# ИЛ-МӘЙДАНДА ТӨШ ТҮГЕЛ

## 1

Җыен диләр иде элек
Бездә сабантуйларын.
Җыелдык һәр ел җыенга,
Хәзинәдәген алып.

Җыела идек авылга,
Чакырып хатлар язып;
Җыела идек елга бер,
Җаннардан җылы алып.

Җыела идек Суыксу,
Ямалы җыенына;
Җыела идек, карамый
Юл йөрү кыенына.

Җыела идек җыенга
Кузбасстан да, Донбасстан.
Җыела идек, җыелмый
Түзәр чара калмастан.

Җыела идек авылга,
Бүләк, күчтәнәч белән;
Күршеләр чәйгә дәшәләр,–
Җылы сөт, җылы күмәч!..

## 2

Хәтердә нык тота авыл –
Кем кайткан, кем кайтмаган;
Телдән телгә күчә хәбәр:
– Кайтмаган – санламаган...

– Кайтырлык хәл тапмаган...
– Кайтам, диеп алдаган...
– Кайтыр иде, чакырып,
Туганы хат язмаган...

Һәрчак барлап тора авыл:
– Бу кем улы, кем кызы?..
Елга бер кайтмый калмады,
Һәркем ерак юл узып...

Сабан туен җыен диеп,
Бик хак әйткәннәрдер ул!
Елга бер җыелмый торып,
Туганлык бит онтылыр.

Җыенга кайткан кунакны
Аштан-ашка йөрттеләр;
Гадәт түгел, әхлак шулай–
Кайткан, димәк, ил күргән!

«Кунак булсаң – тыйнак бул»га
Имчәктән үк төшенгән;
Күчтәнәчен һәм бүләген
Чыгара ул түшеннән.

Сораганны гына сөйләр,
Үзе күбрәк сорашыр;
Искә төшереп, елашырлар,
Ятимлекне... юа ашын...

3

...Сугыш соңы җыенында
Аяксызлар,кулсызлар,–
Биеделәр, җырладылар,
Көрәштеләр дә шулар!

Сукыр Хәниф гармун тарта,
Бии аяксыз Мирза.
Өзәңгедә – имән такта,
Гаяз җиңде узышта!

Аяксыз-кулсыз ирләргә
Канатлар үскән иде;
Ярым-йорты тәннәрендә
Йөрәкләре исән иде!

Сабантуй сабантуй инде,–
Шыр-шәрә сугыш түгел.
Сугыш булмаса да үзе,
Гүпче уен эш түгел.

Сабантуйда сынатмаска
Кардәш-ыру каршында
Тиеш ир-ат – ярты гәүдә,
Бөтенлеге – җанында!

Сабан туе сугыш түгел,
Әмма уен эш түгел,–
Өч йөз алтмыш бишкә бер көн
Ил-мәйданда төш түгел!..

4

Басу капкасы – җилкапка,
Ачучы-ябучысы;
Түбәсенә менеп баскан
Биш яшьлек ятимә кыз!

Чебиләп беткән тәпие,
Олы юлда карашы.
Аның үзендә сабантуй,–
Өмет-чынлык алышы?!

Офык читендә бер шәүлә
Чайкала – куак микән?
Әллә соң Сабан туена
Соңарган кунак микән?

Чайкалуы аның инде
Аяк-кулы юккадыр;
Күз алдында үз Әткәсен
Ул гел шулай тоткандыр...

Башкаларның эткәләре
Сукыр, чулак, аяксыз...
...Мактап яшел бәбкәләрен,
Биеп куйды ата каз.

– Бәбкәнең дә Әткәсе бар,
Минем генә юк Әткәм?..
– Басу капкасы җилкапка,
Ачып куйдым – кайт, Әткәм!

...Басу капкасы күптән юк,
Хәтер исән – җил исә...
Хәбәрсез югалган Әткәм
Аксап кайтып килер кебек,
Сабантуйлар җитте исә...

Әхлак микән, гадәт микән,–
Һәр ел кайтам җыенга.
Чалманарат җыенына
Бөтен авыл җыелган.

Танышларым бар да монда,
Ашыгалар – тамаша!
Күктә тургайлар болыты–
Карасаң, күз камаша.

Тургайлар, сез – балачакның
Канатлы хәтереме?
Хәбәрсез югалганнарның
Җаннары әллә сезме?

5

Сабан туе – халкым туе,
Һич тә уен эш түгел;
Өч йөз алтмыш бишкә – бер көн!
Ил-мәйданда төш түгел!..

...Тургайлы күк, рәшә уйный,
Олы юлда – бер шәүлә–
Киләме, китеп барамы
Хәтергә җәяү генә?..

*Актаныш*
*1994*

# БЕЗ БАБАЙСЫЗ ҮСТЕК

Авыр көрәш, бөек еллар өчен
Кирәк булган минем тууым.

*Һ. Такташ*

## 1

Ничә буын үсте
Бабайларны күрми.
Буразнада үтте
Малайлыксыз гомер.

Кайдан килгән ул көч?
Кайдан килгән ул үч?
Миллион каберләр,
Миллион ятимнәр.

Данлы заман, диләр,
Шаулы заман, диләр.
Зарлы заман булган,
Канлы заман булган.

Авыр еллар булган,
Каты көрәш булган.
Өйләрдән көл калган,
Күңелдә шом калган.

Көрәш изге, диләр,
Кайда изгелеге?
Кайда минем бабам,
Кайда изге нигез?

Агыйделгә кара,–
Бәдрәф суы ага.
Үләксәләр ята,
Таллары юк ярда.

Бразнага кара,–
Хәлсезләнеп тора,
Сабантуйларында
Ал бирмәгән туры.

Үткәннәргә кара,–
Ничә буын шулай;
Ятим, гарип, ярлы,
Йөрәк сыкрап елый.

## 2

Ир уртасы бабам.
Ике аты булган,
Каралты-курасы,
Кулы алтын булган.
Ул сөйләгән туры,
Хәрәмгә тимәгән;
Әбкәм – хурлар хуры –
Башканы сөймәгән.
Сабан туйларында
Ир уртасы бабам
Күпме чиккән сөлге,
Күпме тәкә алган.
Таңнан таңга кадәр
Ул буразна ярган,
Кышын урман кисеп,
Бурап өйләр салган.
Көзен урак урган,–
Амбар тулы ашлык;
Эшле, ашлы булган,
Ач тормаган халык.

3

Кем каргышы тиде?
Нигә каза килде?
Илдә талаш, суеш.
Тоташ янгын иде.
Ак әләмнәр үтте,
Кызыл әләмләр;
Сәнәкләр үтте! —
Калды хәрабәләр.
Кем каргышы тиде? —
Ике ел корылык.
Кара күмер җирдә,
Ник шытсын бер орлык?!

4

Алып баһадирдай
Ир уртасы бабам
Калган шыр ялангач,
Соңгы кат талангач.
Ир уртасы бабам,
Таланып сөрелгәч,
Җиде ятим сабый
Сабанга җигелгәч,
Иген иккән халык
Ачлыктан шешенгәч,
Мәчет манарасын
Аударып төшергәч...
Дөньялыкта — тәмуг?
Ахырзаманмы бу?
Каян килгән бу көч,
Каян килгән бу үч?

Сыйнфый көрәш булды,
Изге көрәш булды;

Җиргә каберлекләр
Һәм ятимнәр тулды.

Югын табып булмый,
Барын булмый бүлеп.
Кем каргышы тиде,
Нидән бу вәхшилек?

Алда нинди көрәш?
Мин мәйданга чыгам!
Без имансыз үстек,
Ярлыкагыл, Ходам!

# АГЫЙДЕЛДӘ АК ПАРОХОД

Ятимлектә үсәргә, үз тамагын үзе туйдыру өчен пароходта җырлап җәйләргә, сәләмә киемнәрен җилфердәтеп ятимнәр йортында кышларга мәҗбүр булган, соңрак Казанга күчеп, бөтен татар халкының сөекле җырчысы булып танылган Әлфия Афзаловага багышлана.

## Актаныш — пароход

Ак пароход көтеп алдым,
бөдрә талга сөялеп.
Юлга алдым җырларымны,
китим әле төялеп.

Бу якларда елавымны
күрим бары төшләрдә.
Туган җирдә яшәү насыйп
бәхетле кешеләргә.

Агып киткән инеш-су да,
алып киткән көмеш су.
Язмышлардан узмыш юк ла,
язмышыңа килеш соң...

Аргы очның коесына
батып калды чиләгем.
Юлга дәшә, җырга дәшә
«күрәчәгем» дигәнем.

Яна йөрәк — күрәчәккә
тартыла да талпына.
Ак пароход алып бара
ак томаннар артына.

Пароходның куласасы
аллы-артлы йөридер:

– Барам – бармыйм,
барам – бармыйм,–
юри шуны көйлидер.

Агыйделнең бормаланып
агуларын күр әле;
әйләнә таллары ярда,
балтырганы, күрәне...
Әйләнә-бии кибәннәр,
чүгеп-чүгеп – чүмәлә;
әрәмә үзе бер сәхнә –
тамашасын күр әнә!
Туйдан кайтып киләмени,
кыяфәтен күр әле:
камышларга кереп бара
җырлый-җырлый бүдәнә.
Әйләнә икән ярлары,
ярда таллар әйләнә;
Әйләнә бөтен Җир шары,–
башкаем да әйләнә.
Җыр әйләнә күңелемдә,–
канатлары – ап-ачык.
Җыр канаты – минем канат,
канатымнан ник качыйм?!

Җырга сусаган җаннарның
сусавын ник басмаска?
Пароход куласасы да:
– Җырла, җырла,– ди ләса.

Кара бөрлегән җыйдым ла,
кызыл бөрлегән җыйдым.
«Бөрлегәнем, бөрлегәнем,
бөрлегәнем»,– дип җырлыйм.

Кәккүк тавышын санадым,
сөялеп лә киртәгә,
кәккүк дустым әйткән иде
юл чыгасын иртәгә.

Алмагачның ботагында
сайрый сары сандугач,
сандугачтан ник көнләшим,
мин үзем дә карлыгач.

Күзләрем дә кара гына,
кашларым да чем-кара;
күңелемдә бер кара юк,
җырымны тыңлап кара.

Җырымны тыңлап кара син –
әҗәл даруларымны.
Сиңа гына бүләк итәм
сулыш алуларымны.

Чиләкләрем мөлдерәмә лә,
суы чайкала инде;
сиңа дигән җырларым да
кала, һай, кала инде!

Еракларда җыр микән ул,
томан микән агара,–
дулкыннар шунда чаба да,
җырга кереп югала.

Күңелемдәге дулкыннар
Иделнекеннән көчле.
Диңгезнекеннән көчле дә,
күкләргә ашар төсле!

Күкләргә ашар төсле дә,
сиңа кул сузар төсле.
Салават күпере аша
җырларым узар төсле.

Таныш миңа шәмәхә моң,
кушыла чия-кызыл;
яшел, зәңгәр, сарысына
кушылып җырла, кызый!

Салават күперендәге
төсләр хәтле тавыш бар.
Әрәмәдә – Әргәнештә
аннан да күп тавышлар!

Ятим диеп тормадылар,
җырлаттылар туктаусыз.
Хәтерләмим җырларымның
калганнарын хуплаусыз.

Җырым бер телем ипи дә,
бер такта чәй дә булды,
котып җилле кыш та булды,
чүлдәге җәй дә булды...

Иске бишмәт иске түгел –
Америка җибәргән:
– Актанышта бер ятим бар –
кисен әле, дигәннәр!

Киям әле, сәер үзе–
бу дәрәҗәдә бөлү:
ач-ялангач көенчә дә
җырлау, бию һәм... көлү?!

Әҗәкүл – Казан арасы –
ике тәүлек барасы;
куласа кисәтә кебек:
– Адашырсың, бала, син...

Пароходның яңакларын
үбә Идел дулкыны.
Кая илтеп, кайда йөртер
ятимлекнең упкыны?!
Утырыплар дулкыннарга,
әллә кире китимме?
Эһ, дигәнче Актанышка
кайтып кына җитимме?

## Пароход – Актаныш – Әлем

Кайтуын ул кайтырсың ла,
көтеп торучың булса.
Еларсың да, җырларсың да,
күңелкәйләрең тулса...

Кирмәнчек тавы ком гына,
ком булса да гөл үскән.
Күңелем тулы моң гына,–
мин шул әнкәсез үскән...

Актаныш – Әлем арасы–
тау менәсе-барасы.
Язмышыма язылгандыр
караның да карасы.

Ат юлы – алты чакырым,
атлыйм җәяү, ялгызым,
Җәяүләп чыккан буран да
бара икән, җыр суза!

Ертылып беткән бишмәтнең
итәгеннән җыр тарта,
тишек киез итекләрем
үземә җыр тыңлата.

Җыр шыгырдый – карга бассаң,
чана тартсаң – җыр чыга;
кое чыгыры җырына
кушыл да чыда гына.

Ачлык җырлый, күзләр җырлый –
җыр дәвамы күз яшьле.
Җырсыз булсаң, тук булсаң да
матур булмас ул яшәү.

Кырлач көен, ыспас көен,
челлә көен тыңларга,
мин күнеккән дүрт яшемнән
җилгә кушылып җырларга.

Укытучым-остазларым
шулар дисәм, алдамыйм;
иң югары ноталарны
җилгә кушылып алдым мин...

Әргәнештә сандугачның,
Ташлыкомда тургайның,
Атавында карлыгачның
җыруларын тыңладым!

Сагынам дип әйталаммы,
и каһәрләнгән җирем?
Әнкәемне кара гүргә
суырып алган җирем?..

Актаныш – Әлем арасы,–
барасы да, барасы,
аркадан җил этеп бара,
бармый гына кара син!

Яңа Әлемдә ятимнәр
йортын ишетеп беләм.
Күрәчәк, кара бер төндә,
китерде шунда терәп.
Ихата-кура дигәне
ягылып беткән күптән.
Салам түбәле ике өй
ак юрган япкан күктән.
Кыяр-кыймас ишек кактым.
– Керегез,– диде кемдер.
Укытучым – Сәйдә апа –
күченеп килгән көздән.
Үзенең ике сабые,
эше-ашы бер очтан
булыр диеп, килгән наный;
күрәчәк шулай кушкан...

Салам түбәле ике өй,
«детдом» шул була икән:
идәне дә, түшәме дә
гел салам гына икән.
Салдыкларын сарыкларның
көн дә җыеп кайталар;
җылынырга өметләнеп,
шуны ягып яталар.
Дөрләп китә көлтә-көлтә,
бермәл балкыш сызыла,–
кара сызык булып сүнә,
бөтен дөнья баз була.
Суык үтә һәр тән аша...

Кыш үтә дә яз җитә.
Яланаяклы ягыма
торналар кайтып җитә.

Торна тавышыннан шомлы
тавыш барын беләмсең?
Дертләп куя авылларның
черек салам түбәсе.

Яңа Әлемдә яңа сүзен
әйтсә әйтер дивана.
Яңа ямау салган капчык –
яңа җыйган җуага!
Яңа ямау салган итәк –
кычытканы өр-яңа!
Кукы, кузгалак, балтырган –
алары да чын яңа!..

## Актаныш – Казан

– Борыл! – диеп, ач ятимлек
арттан чаба, чакыра...
Борылмамдыр,
җырлар җырым
Казаннарга чакыра!
Борылмамдыр,
монда дуслар,
якыннарым булса да,
монда елап калса да...

Пристаньга озатып килгән
җырдашларым, каласыз;
каласыз инде, каласыз,
мин калалмыйм – чарасыз...

Скрипкаң, Мәсгут абый,
моңлы инде бигрәк!

Мәсгут абый берни дәшми,–
өздереп уйный бирә.
«Тәфтиләү»не, «Зөбәрҗәт»не,
«Асылъяр»ны берочтан,–
җырлата да, елата да,
бигрәк оста, чукынган!

Мәсгут абый, җаныкаем,
– Аерылабыз,– дисеңме?..
Кушылып җырлап җибәрче,
җырладылар дисеннәр!

Җырның нуры – кояш нуры,–
җаным шуны белә бит.
Үзең дә бик шәп беләсең,
әйдә, җырлап җибәрик!

Агыйделдә туып-үскән,
шунда пешкән җиләк мин;
Замана ятим итсә дә,
кем өчендер кирәк мин!

Бу заманны хурлыйсылар,
зурлыйсылар алда әле.
Мин заманны узып җырлыйм:
– Килер көнем ал да гөл...

Җырларымда Актанышка
мин әйләнеп кайтырмын.
Әргәнештә, алсуланып,
җыр-таң булып атармын!

– Сандугач кайткан! – диярләр
кызлар, кер чайкаганда.
Әргәнештә өр-яңа җыр
тугайны айкаганда.

Кибән куйган ир-егетләр
туктап нидер уйларлар,
тыңларлар да, кибәннәрен
җырдай коеп куярлар.

Җылы печән, җырлы печән
ашарлар сыерлары.
Җырлы булыр, моңлы булыр
табыннары, сыйлары!

Пароходның куласасы
аллы-артлы йөридер:
«Барам – бармыйм,
барам – бармыйм»,–
юри шуны көйлидер.

Пароходның яңакларын
үбеп кала дулкыннар,–
туган яктан аерылу
җырын җырлый ич алар.

Кузгалаклы балачагым,
тузганаклы балачак,
энкәйләрсез балачагым,
экият тулы балачак,
моң-сагышлы балачагым,
җырлы-көйле балачак
елап монда калачак.
Бала җаным, бала акылым –
гомерлеккә калачагым –
үзем белән барачак.
Җырларымда яначак!!!

*Актаныш – Нөркә*
*1996*

# САБАНТУЙ

...Татар көпшәк халык түгел,
йолкырга, тарткаларга...

*М.Шәймиев*

## 1

Сабантуй – туган халкымның
Тиңдәшсез тантанасы!
Кешелеккә яшьтәш бәйрәм,
Әйтегез, кайда бар соң!

Ядкаре бөек Болгарның
Хаҗитархан, Урданың.
Сарматларда, Каганатта
Сабантуйлар булган ул!

Сабан туе орыш түгел,
Ярыш, алыш – сынатма.
Мәйданнарга сөлге тотып
Чыгып баскан ир-атка
Төбәлгән ил-йорт карашы,
Алымы ни, ысулы.
Аксакаллар хөкем итәр,
Хаклык булмас кысулы...

Җитезләрнең житезе кем,
Матурлардан кем матур?
Тапкырларның тапкыры кем,
Батырлардан кем батыр?

Барлау кирәк, санлау кирәк,
Данлау кирәк аларны.
Батырлары булса гына
Халык гомере дәвамлы.

## 2

Билләргә ята ак сөлге.
Имәндәй нык егетләр,
Иңнәрендә ил-йорт йөге,
Алып батыр кебекләр.

Кызлар бии, калфаклары
Ука белән чиккәнме,
Әллә инде кызыл туйлар
Итәр чаклар житкәнме?

Кызлар бии, биесеннәр,
Биеп туймас чаклары.
Сабантуйда бии хәтта
Ярсу чабыш атлары...

Аргамаклар – ак күбектә,
Очып үтә араны.
Тояклары чыңлавында
Моңы Кыпчак-даланың...

Чәчән суза, саз сызыла,
Курай, торба, думбыра...
Уралыннан, Сарытаудан
Урап килгән моң гына.

Моң – гасырлар аръягыннан,
Шанлы еллар багыннан...
Шөкер – милләтем бердәнбер
Иманына табынган...
Кыйбласы бер, иманы бер,
Теле бөтен, бер генә.
Шул милләтне бүлгәләргә
Җөрьәт итәр кем генә?

3

Сабантуйлы халык бер ул,
Белсәң дә, белмәсәң дә!
Меңьеллардан килгән берлек
Тармаңгай кемсәләргә
Тынгы бирмидер халыкның
Гайрәте, олпатлыгы...
Мәйданга чык — исбатла соң
Ниятеңнең хаклыгын...

Аерып кара халыкны
Кәсебе, һөнәреннән...
Бозлык чорыннан бер булып
Яшәгән көннәреннән.

Аерып кара жырыннан,
Чулпылары чыңыннан...
Риваяте, дастаннары,
Бүгенгесе — чынынннан.

Аерып кара Жаекны,
Агыйделне Уралдан...
Чулман, Идел, Иртыш, Нократ
Бердәм халык, туганнар
Көн иткән кыры, ярында...
Урманы, даласында...
Аерып кара халыкны...
Мең яшьлек каласыннан?..

Кемгә ни житми, байлыкмы,
Туганынмы тарсына?..
Чикләнмәгән форсат бирә
Сабан туе барсына.

Кирәк ыру, кавем булсын,
Кирәксә иңсен күктән...

Чык мәйданга – дан алырсың
Бүләккә – сөлге көтә!

Бердәнбер хаклык урыны,
Хак бизмәне шул чиктә.
Кавемеңне бөек итеп,
Күрәсең килсә бик тә,
Сан белән түгел, сын белән
Яула мәйданга чыгып.
Сабан туе сынауларның
Иң гаделе, иң чыны!

Узышта ал, алышта бил
Бирмәгән халык кына.
Сабантуйлы – мәйданлы ил,
Мәйдансыз – сарык кына.
Мәйдансыз бүленеп калса,
Бер бүре чыгар буып,
Ыру кавемгә таркалса,
Куян таркатыр куып...

Юк, көпшәк халык түгел без,
Йолкырга, тарткаларга.
Юл куймабыз, белеп торсын
Дус, ятлар, башкалар да.

Таш атканга да аш куйган,
Кичерә белгән халык.
Юаш, – диеп, ялгыш уйда
Булса кемдер, – беркатлы...

Кичерү мөмкин ялгышны,
Кардәш, дуслык хакына.
Ялган, яла, хыянәтне
Кылса кемдер халкыма,
Көтмәсен һичбер ярлыкау
бүген һәм килерендә...

Гомер иткән һәр көн сынау
И алып, билең бирмә!

Гомер иткән һәркөн сынау
Галәм, дөнья каршында...
Аргамаклар ак күбектә
Ал бирмичә ярсыган...
Гомер иткән һәркөн сынау
Үр менгәндә, милләтем,
Бердәмлегең, бөтенлегең
Кыйммәтләрдән кыйммәтле!!!

Гомер иткән һәр көн сынау
Җитлегү, олпатлыкка.
Сабан туе мәйданында
Милләтем сынау тота!

Аксакаллар хөкем итә,
Күз уңында һәр алым.
Ак сөлгеңдәй ак юл сиңа
Алыплы, моңлы халкым!

*Тальятти, Сургут–Казан*
*14.06–17.11.02*

# ЭЧТӘЛЕК


Нечкә хисләр, көчле хисләр! *Мансур Вәли-Барҗылы* . . . . . . . . . . . . 5

**Идел-Йорт**

Идел-Йорт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Батырларын барлап тора халкым. . . . . . . . . . . . . . . . 9
Карчыга бит ике башлы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Каршылыйк. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Ак илем. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Тукай – иман. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Булды, булды... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Гыйбрәт ал, падишаһым. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Август ни дә, октябрь ни... . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Без исән! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Тәңре ничек йөртә?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
И туган тел. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Бөек күкнең күз алдында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Тәрәзәмә кагылма, җил. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Буламыни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Ай тотылган төндә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Ни күрер кызларым, улларым?. . . . . . . . . . . . . . . . 26
Мәскәүләрдән Казан күренә, диләр . . . . . . . . . . . . . 28
Кем ул?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кешегә ни булган?. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Коммунизм финишы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Керфек какмый төн уздырам... . . . . . . . . . . . . . . . 32
Үткән дә киткән гомер.... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Сорамачы, якташ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
«Бар ул, бар... » . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Маңкорттыр без...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Замана. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Өлкәннәр сүзе. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Бүген. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41

«Ил карагы...» . . . . . 42
Туганыңнан тарсынма . . . . . 43
Тарих тора . . . . . 44
Алыпсыз халыклар бар икән . . . . . 45
Кем иле? . . . . . 46
Җил – аваз еллар багыннан . . . . . 47

## Киек Каз Юлында

«Ук алмаслык арада...» . . . . . 50
Ир-ат исеме аласым бар . . . . . 51
Куркамын калудан каралып . . . . . 52
Агымсу шикелле . . . . . 53
Үземә . . . . . 54
Күзләргә кердисәм . . . . . 55
Илһамият, рәхмәт сиңа . . . . . 56
Сабыйлык гөнаһы . . . . . 57
И авылдашлар! . . . . . 58
И җаным! . . . . . 58
1995 ел челләсе . . . . . 59
Танышыма . . . . . 60
Эштән чыккан татар кызына . . . . . 61
Җанны юу кирәк . . . . . 62
Карап тора тулган ай . . . . . 63
«Уйлар...» . . . . . 64
Чорында бердәнбер була... . . . . . 65
«Күкнең түбе...» . . . . . 66
...Казан. Свердлов урамы... . . . . . 67
Ялган сүз . . . . . 68
Талкынды җир . . . . . 69
Ахыргы көн . . . . . 70
Егылдык та тордык... . . . . . 71
Төн . . . . . 72
Көн белән Төн . . . . . 73
...диде акыл . . . . . 75
Замандашка . . . . . 77
Җавап . . . . . 78
...димәгез!.. . . . . . 80
Күздә бер мә. . . . . . 82
Кырлачның соңгы көнендә . . . . . 83
Язның тәүге көннәре . . . . . 84
Яздан җәйгә күчкәндә . . . . . 85
Барыбер якты бу дөнья . . . . . 86

### Сагыш китабы


Сагыш . . . 88
Сагыш китабы . . . 89
Бу яшәү көедер . . . 91
Каурый болытта тибрәлә бер тәймә . . . 92
Тыңлыйк әле тын гына . . . 93
Изге сукмак . . . 95
Димәк... 96
Шагыйрь янган . . . 97
Киек Каз Юлы . . . 98
Сискәнеп тартылды хәтер . . . 99
Хәтер . . . 100
Бер сүз җитә . . . 101
Йөзләремдә көз төсе . . . 102
Белми ул, алдый... . . . 103
Уйларым . . . 103
Беркем дә дәшмәде... . . . 104
Күз күтәп алганым . . . 105
Тәрәзәмдә август төне . . . 106


### Сине эзләп килде җаным


Уйланып йөргән идем . . . 110
Юлга чыксам . . . 111
Серлелек . . . 112
Сөю калыр . . . 113
«...Көзге кояш кебек...» . . . 114
Күккә ут ягып төнозын . . . 114
Кадер тауларында кар-буран . . . 115
Яшәр өчен . . . 116
Өн бу, өн . . . 116
Кил әле . . . 117
Таптым да югалттым . . . 118
Нишләрмен?.. . . . 119
«Телим...» . . . 120
Умырзая . . . 121
Син туган бу төндә . . . 122
Очып кына кайтыр идем . . . 123
Син минеке дә, түгел дә . . . 124
«Берек»,– диде каенанам . . . 124
Кошлар киткәндә . . . 125

Ышанырсың микән . . . . . . . . . . 125
Агыйдел сылуына . . . . . . . . . . 127
Язгы мизгелләр . . . . . . . . . . 128
Бездән бирнә – Турайгыр . . . . . . . . . . 129
Горурлык . . . . . . . . . . 131
Сез. . . . . . . . . . . 132
«Арын арык уйларыңнан...» . . . . . . . . . . 133
Сиңа кайтыр юлым . . . . . . . . . . 134
Ят түгел әрнүләрем . . . . . . . . . . 135
Һәркемнең үз көе . . . . . . . . . . 136
Агыйделдә ал таң ата . . . . . . . . . . 137
Гомер йөзеп чыгылган . . . . . . . . . . 138
Көнләмә . . . . . . . . . . 139
Ярымай тирәк очында... . . . . . . . . . . 140

## Багышлаулар

Хәсән Туфанның йөз еллыгына . . . . . . . . . . 142
Дулкыннар йөгерә каршыма . . . . . . . . . . 143
Ул китте, китеп барышы... . . . . . . . . . . 144
Теткәләнгән йөрәк белән... . . . . . . . . . . 145
Ак әби . . . . . . . . . . 146
Карурманга кергән идек . . . . . . . . . . 147
Җырла, Салават! . . . . . . . . . . 148
Җырың иңгән шушы төндә . . . . . . . . . . 150
Ул гаҗәеп бүген . . . . . . . . . . 151
Сарды сары сагыш . . . . . . . . . . 152
Гел елмаеп тормаса да дөнья... . . . . . . . . . . 153
Улым Гаделгә . . . . . . . . . . 154
Җиде . . . . . . . . . . 154
Кызыма . . . . . . . . . . 155
Мин җырлыйм . . . . . . . . . . 156
Сез һәм алар . . . . . . . . . . 158
Куркаклардан куркам . . . . . . . . . . 159
«Тантана артыннан тантана...» . . . . . . . . . . 161
Нигә бер уйнамаска . . . . . . . . . . 162

## Газәлләр

«Кышның китәсе килмиме...» . . . . . . . . . . 166
«Уйчан йөзем борчулы... . . . . . . . . . . 166
«Һәр ташуда ун...» . . . . . . . . . . 167

«Тулган айда күрдем...» . . . . . . . . . . 168
«Дөнья гел алыш-бирештә...» . . . . . . . . . . 169
«Кызлы йортның...» . . . . . . . . . . 170
«Күзгә күз багып...» . . . . . . . . . . 171
«Көн уртасы...» . . . . . . . . . . 172
«Әйтче кардәш...» . . . . . . . . . . 173
«Тыңла, ничек сыктый...» . . . . . . . . . . 174
«Бәләкәй булсаң бул...» . . . . . . . . . . 175
«Карыйм да бу дөньяның...» . . . . . . . . . . 176

## Кош теле

Кыска шигырьләр . . . . . . . . . . 178
Такмаклар . . . . . . . . . . 245

## Агыйделдә ак пароход

*(Поэмалар)*

Әнкәй . . . . . . . . . . 248
Куян күчтәнәче . . . . . . . . . . 260
Кабатланмас мәңге дигәннәре . . . . . . . . . . 263
Дөнья сүзе — көн күзе . . . . . . . . . . 266
Турайгыр . . . . . . . . . . 270
Ил-мәйданда төш түгел . . . . . . . . . . 275
Без бабайсыз үстек . . . . . . . . . . 280
Агыйделдә ак пароход . . . . . . . . . . 284
Сабантуй . . . . . . . . . . 294

Литературно-художественное издание

*Мухаммат Мирза*
*(Ибрагимов Илфак Мирзамухамматович)*

НА МЛЕЧНОМ ПУТИ

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Р.В.Сабирҗанов, С.М.Мифтахова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 9.01.2003. Форматы $70\times108^1/_{32}$.
Гарнитурасы «Мусл». Шартлы басма табагы 13,3+фор.0,17.
Шартлы буяу-оттиск 14,35. Нәшер-хисап табагы 10,11+фор.0,29.
Тиражы 2000. Заказ Я-3.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.